Илдар Сафин

# Юлбатым

# Ямбулатым

*Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы*
*Юлбат, Тенеки, Йосыф-Алан,*
*Калатау авыллары тарихыннан сәхифәләр*

Казан
"Сүз"
2014

ББК 26,89
УДК 908
С12

Әлеге китап Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының субсидиясе хисабына нәшер ителде.

**Сафин Илдар**
С12 Юлбатым-Ямбулатым. Саба муниципаль районы Юлбат, Тенеки, Йосыф-Алан, Калатау авыллары тарихыннан сәхифәләр. Казан: “Сүз” нәшрияты, 2014. – 320 б.

Бу китап Юлбат авыл җирлегенә кергән авылларыбыз тарихына багышлана. Ул мәктәп музее, Татарстан Республикасы Милли архивы материалларына, халык хәтерендә сакланган истәлекләргә нигезләнеп язылды. Китап өлкән буын кешеләренә, мәктәп укучыларына, гомумән, киләчәктә төбәгебезнең үткәне белән кызыксынучыларга адреслана.

ISBN 978-5-98356-257-8
© Сафин Илдар, 2014

# *Халык тарихы авылдан башлана*

Авыл тарихы – ул кешеләр, анда яшәүчеләр тарихы. Һәркемгә дә үзенең туган җире газиз һәм кадерле була. Бу китапның авторы Сафин Илдар Фатхулла улы өчен дә ул шулай, әлбәттә. Автор китапны  үз төбәге авыллары кешеләре белән әңгәмәләр корып, мәктәп музеенда укучылары белән үзе туплаган материаллардан файдаланып, архивларда эзләнеп, күп чыганакларны өйрәнеп язган.

Юлбат авылының барлыкка килү вакыты, атамасы турында сүз барганда, автор Татарстан милли архивындагы чыганакларга, метрикаларга таянып яза. 1834, 1850 елгы Ревизия сказкаларына, 1940-1942 елгы хуҗалык кенәгәсенә нигезләнеп, төрле елларда үз авылларында ничә хуҗалык (двор) булганлыгын, күпме кеше яшәгәнлеген күрсәтә. 1883 елгы статистик экспедиция күрсәткечләре буенча авылның социаль-иктисади хәлен, авылның картасын төзү өчен язып алынган 1881 елгы Именной список буенча Ямбулат авылында хуҗалыкларның урнашу тәртибен бирә.

Тарихи чыганакларга таянып, автор үз авылларының баштагы татарча исеме Юлбулат булуын, ә русча документларда Янбулатово (Ямбулатово) дип йөртелүен раслый.

Илдар Фатхуллович 1917 елгы инкыйлабка кадәрге, аннан соңгы тормыш вакыйгаларына, шушы җирлеккә кергән авылларда Совет хакимияте урнашу, колхозлар төзелү  чорын тасвирлый. Китапта шулай ук Бөек Ватан сугышы елларындагы, аннан соңгы тормыш авырлыклары ачык сурәтләнә. Автор үз авылларындагы мәгариф үсеше, рухи-дини тормыш турында бай мәгълүмат бирә, авылларының уңган-булган кешеләре турында горурлык хисләре белән яза. “Юлбатлылар кайда гына эшләсә дә, сынатмый”, – ди ул.

Фоторәсемнәр, һәр китапны баета торган иллюстратив материал булу белән бергә, ышанычлы документаль чыганак та булып тора. Алар вакыйгада катнашучыларны урынга һәм вакытына бәйләп теркәлгән дәлилләр. Китап өчен сайлап алынган 200дән артык фоторәсем урынлы кулланылган.

Китап аңлаешлы телдә язылган, авылдашларына, өлкән буын кешеләренә, мәктәп укучыларына, гомумән, тарих белән кызыксынучыларга адресланган.

Россия федерациясенең мактаулы гомумбелем бирү хезмәткәре Сафин Илдар Фатхулла улы, Совет Армиясе сафларында хезмәт итеп кайтканнан соң, 1982 елда Казан Дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультетының көндезге бүлеген, ә 1992 елда читтән торып В.И.Ульянов-Ленин исемендәге Казан Дәүләт университетының тарих факультетын тәмамлый. Югары категорияле

тарих укытучысы. 2006 елда Өстенлекле милли проект кысаларында үткәрелгән “Россия федерациясенең иң яхшы укытучысы” конкурсында катнашып, грант алды, ә 2013 елда шул ук проект кысаларында Татарстан Республикасының иң яхшы укытучылары конкурсы җиңүчесе булды.


Үз төбәге тарихын йөрәнү, материаллар туплау эше белән 30 елдан артык шөгыльләнә. Шуның нәтиҗәсе буларак, 1995 елда бай эчтәлекле “Туган якны өйрәнү музее” булдырды. Аны экспонатлар, тарихи чыганаклар һәм видеоязмалар белән баету өстендә даими эшли. Саба районы мәктәпләрендә иң беренче булып мәктәп тормышы, туган як, авыллар тарихына багышланган видеоязмалар төшерә, аларны дәресләрдә һәм класстан тыш чараларда куллана башлады. Казан шәһәрендә тарихи темаларга үткәрелгән күпсанлы конференцияләрдә чыгыш ясап, ул бу өлкәдә үзенең эш тәҗрибәсе белән уртаклаша, аның чыгышлары уннан артык җыентыкта басылды.

Китапны бастырып чыгару өчен автор финанс мөмкинлекләрен дә үзе тапты. Китапның проекты, Татарстан Икътисад министрлыгы үткәргән конкурста җиңеп чыгып, субсидиягә лаек булды.

Илдар кебек туган ягы авыллары елъязмасын мәңгеләштерүче, туган җирен ихластан хөрмәтле белүчеләр булганда, киләчәгебез өметле. Авылның китаплы булуы – гасырлар тарихының бер битендә мәңгелек урын алу ул.

***А.Ә.Борһанов,***
*Казан (Идел буе) Федераль университеты профессоры,*
*Татарстанның Атказанган фән эшлеклесе.*

## *Кереш*



Туган авылның үткәне кемнәрне генә кызыксындырмый икән? Элегрәк буыннар, миңа калса, балалары белән күбрәк аралашкан, үзенең җиде буын бабалары, аларның яшәеше, кәсебе турында җентекләп сөйләгән, авылның үткәне турында үзенчәлекле вакыйгаларны ул-кызына җиткергән.

Ә бүген ата-ана белән бала арасындагы мөнәсәбәтләр башкача: һәркем үз эшендә. Дистә, йөз еллар элек булган вакыйгаларны белүчеләр дә инде бүген исән түгел. Ә үткәннәрне белергә кирәк. Азмы-күпме халык хәтерендә сакланып калганнарны кәгазьгә төшерсәк, киләчәктә аны укучылар, авылның үткәне белән кызыксынучылар, мөгаен, булыр.

Шундый өмет белән бу эшкә алындык. Максатыбыз нинди дә булса ачыш ясау түгел, ә авыл тарихы буенча халык хәтерендә булганнарны киләчәк буыннарга җиткерү. Нинди җирлектә эш башладык, "таяну ноктабыз" ни иде? Билгеле, халык хәтерендә калганнар. Аларны 1982 елда сигезьеллык мәктәп ачылгач туплый башладык. Шул елларда пионервожатый булып эшләгән Шакирҗанова Фәһимә Гаптелфәтовна җитәкчелегендә Бөек Ватан сугышы ветераннары, тыл хезмәтчәннәре тормышы, комсомол тарихы буенча истәлекләр барланды. 1992 елдан, үзем тарих фәнен укыта башлагач, музей ачу идеясе белән бу эш системага салынып, тагын да активрак алып барылды. 1995 елда, мәктәп музее ачылгач, класс җитәкчеләре үз укучылары белән бергә эзләнү эшләре алып бардылар, тапкан материалларны, зәвыклы итеп туплап, музейга тапшырдылар. Алда санап үткән чаралар бик вакытлы башкарылды, чөнки ул елларда сугыш ветераннарының күпчелеге исән иде әле, тыл ветераннары, өлкән буын хәтерендә үткәннәр нык саклана иде.

Истәлекләрдән башка халыкның тормыш-көнкүреше, сугыш чорына кагылышлы экспонатлар җыелды. Музейда экспонатлар туплауда әти-әниләрнең теләктәшлеге безгә зур ярдәмче булды. Балалары мәктәптә укыган барлык әти-әниләргә зур рәхмәтебезне җиткерәбез.

Музейга материаллар туплауда зур ярдәмчеләребез – музейның кирәклеген аңлаучы, аның эше белән һәрдаим кызыксынып торучы Ракова Саҗидә Мирзовна, Галиев Наил Тимергалиевичлар булдылар. Алар сугыш чоры, колхоз, комсомол

тарихы буенча парторг булып эшләгән чорда үзләрендә тупланган истәлекләрне музейга тапшырдылар. Алга китеп булса да әйтик, Наил Тимергалиевич бу китапны язганда да алып кайткан архив документларын анализлауда ярдәм итте, авылның үткәне буенча үзенең белгәннәре белән уртаклашты.

Мәктәп тарихы бүлеген язуда 1991-2010 елларда тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булып эшләгән Шәмсетдинова Мәгефия Камалетдиновна туплап мәктәп музеена тапшырган материаллар кулланылды.

Бу китапны дөньяга чыгаруда тормыш иптәшем Сафина Рәмзия Габделбәр кызының өлеше бик зур булды. Ул урта мәктәп эшчәнлеге турында язды, кульъязманы компьютерда җыюны башкарды.

Авыл җирлеге Советы каршында оешкан коммерцияле булмаган "Надежда" фонды директоры Хәлилова Зәмфәрия Мөбәрәкҗан кызы финанс документларын эшләүгә җаваплы карады.

Юлбат авыл җирлеге башлыгы Шәмсиев Талип Рәшит улы авылның китаплы булу идеясен хуплап алды һәм эш барышы белән кызыксынып торды.

Казанда яшәүче авылдашыбыз Низамиев Габделхәй Низами улы колхоз тормышы, авылга кагылышлы истәлекләре белән уртаклашты, безнең белән һәрдаим элемтәдә булды.

Сабада яшәүче, төбәк тарихын өйрәнүче Гомәров Равил абый безнең авылга кагылышлы үзендә булган документ күчермәләрен бирде.

Читтә яшәүче авылдашлар һәм авыл белән бәйле булмаган башка кешеләр, китап чыгару мәшәкатьләре белән йөргәнне белгәч, теләктәшлек күрсәттеләр. Шундыйлардан Казан шәһәрендә яшәүче Айгөл Хәкимуллинага эшлекле киңәшләре, тәкъдимнәре өчен без бик рәхмәтле.

Шулай итеп, бу китап – бик күп кешеләрнең хезмәте нәтиҗәсе, берничә дистә ел тупланган материалның чагылышы.

Мәгълүматларны китап формасында туплау эшенә керешкәч, Татарстан Милли архивында авылыбыз тарихына кагылышлы шактый материал табылды, күп кешеләр белән очрашып сөйләшенде.

Авыл тарихы турында бөртекләп җыйган материалларны китап итеп чыгаруны үземнең бурычым итеп саныйм, чөнки дистә еллар дәвамында саклланган язма истәлекләр саргая, туза бара, куллану өчен уңайсыз, берничә бүлек булып тупланган материаллар бербөтен булып күз алдына килеп басмый. Авылыбыз музеенда тупланган әлеге елъязмаларны китап рәвешендә туплап саклаган очракта гына тарихыбызны киләчәк буынга тапшырып булачак.

Китап башта Юлбат авылына гына багышланыр дип уйланылган иде. Ләкин Юлбат, Тенеки, Йосыф-Алан, Калатау авыллары колхозлашу чорлары, озак еллар бер колхоз булып яшәү, Бөек Ватан сугышы еллары авырлыклары, мәктәп тормышы аша бик тыгыз бәйләнгән, шунлыктан, китап "Юлбатым-Ямбулатым" дип аталса да, күрше авылларның тарихи сәхифәләренә дә бераз тукталдык. Ул авыллар халкы безне дөрес аңласыннар иде: бер китап кысаларында дүрт авылны бертигез яктырту мөмкин түгел, чөнки бер авыл тарихы үзе генә дә берничә китап булырлык.

Китап өчен фоторәсемнәр мәктәп музеендагы стендлардан, альбомнардан алынды. Авылдашларыбыз да гаилә альбомында булган кызыклы фотолар белән бик теләп уртаклаштылар. Төбәгебезнең 1960-1970 еллардагы һәвәскәр фотографы Ленц Хөсәеновның, профессиональ фотографлар Микаил Заһидуллин, Нурхан Дәүләтовларның, “Саба таңнары” газетасының директоры-баш мөхәррире Рөстәм Исмәгыйлов төшергән авыл күренешләре фотолары кулланылды.

Китапның тышлыгын, форзац өлешләрен эшләгәндә Ләйсән Сафина проекты файдаланылды.

## *Авыл тарихына караган кайбер кыскача мәгълүматлар*

1834 ел – халык исәбен алу (8-ая “Ревизская сказка”) үткәрелә, Ямбулатта 53 хуҗалык була.

1850 ел – халык исәбен алу (9-ая “Ревизская сказка”) үткәрелә, Ямбулатта 57 хуҗалык.

1859 ел – Ямбулатта 67 хуҗалык, 225 ир-ат, 226 хатын-кыз, 1 мәчет.

1865 елдан башлап Ямбулат авылының мәчет метрикалары Татарстан Милли архивында саклана.

1867 елда мәчет яна. 1880 елның 15 маенда янган мәчет урынына яңасын төзү өчен хөкүмәттән рөхсәт алына.

1881 ел – авылның йортлары урнашу картасын төзү өчен хуҗалыклар урнашу тәртибе язып алына (именный список).

1890 елларда Тенекидә мәчет салына, 1907 елда Комар кешеләре ремонтлыйлар (Хәмидулла Хуҗиәхмәтов язмалары буенча)

1890 еллардан 1918 елга кадәр Тенеки, Бигәнәй – Мәртен, Туктар халкы арасында урман төпләп чистартылган җир өчен дәгъва барган.

1918 ел – авылда җир яңача бүленә.

1921 ел – Мөхәммәтшакир хәзрәт Баһманов вафат була. Юлбат зиратында җирләнгән.

1924 елда Юлбат авылына Балык Бистәсе районы Котлы Бөкәш авылыннан 1879 нчы елгы Мөхәммәдша углы Мөхәммәтшакир хәзрәт килә. 1961 елда 81 яшендә вафат була. Юлбат зиратында җирләнгән.

1921 елда хәзерге Каенлык урамында зур янгын була.

1924 ел – авылга укытучы булып Иманкулова Газизә килә.

1926 елның көзе – Югары Шытсу авылыннан 2 гаилә (Гаффаров Хуҗа һәм Садриев Тимер гаиләләре ) Калатауга күченә.

1927 елның язы – Югары Шытсу авылыннан тагын 10-12 хуҗалык күченә.

1927 ел – Калатауда коммуна (ТОЗ) оеша.

1930 ел – Юлбаттан беренче район Советы депутаты Хаҗиев Таҗиәхмәт Хаҗиәхмәт улы сайлана.

7 апрель, 1931 ел архив документларында Юлбатта колхоз төзелгән көн буларак теркәлгән.

1932 елда колхоз һәм аерым хуҗалыклар көче белән Кәримулла абыйлар тыкрыгы турында (Рахимуллин Рамил) инеш аша агач күпер салына. (Ул 1947 елның 3 апрелендә китә.)

1932 ел – Төхбәт бай өен күчереп, авылда беренче мәктәп салына.

1933 ел – Тенекидә кирпеч заводы төзелә.

1934 ел – укытучы Чутаева Шәмсия тырыш хезмәте өчен Татарстанның алдынгы укытучыларының I съездына делегат итеп сайлана.

1934 елның 1 декабренә колхозга керүчеләр саны:

Юлбат – 141 гаилә,

Тенеки – 123 гаилә,

Йосыф-Алан – 48 гаилә.

1934-35 еллар – Нахальный урамында йортлар төзелә башлый.

1937 ел – "Коммунар", "Саратов" комбайннары кайта. Аларны тәгәрмәчле тракторлар тартып йөргән.

1937 ел – Чутаева Шәмсия Юлбат авылына укытырга килә.

1939 ел – Юлбат мәчетенең манарасы киселә.

1941 ел, 23 июнь – Һадиев Барый, Таһиров Галим иң беренчеләрдән булып Бөек Ватан сугышына китәләр (Хаҗиева Рәшидә көндәлегеннән).

1941 ел, 26 июнь – Рахимуллин Гатау, Гыйлаҗиев Хәй, Сабиров Хәсән, Шәйхетдинов Хәмит сугышка китәләр (Хаҗиева Рәшидә көндәлегеннән).

1946 ел. Хуҗин Раиф авылга беренче мотоцикл алып кайта (немец трофей мотоциклы).

1946 ел – авыл Советына радиоприемник алына, шул радиоприемниктан чыбык сузып, Низамиев Габделхәй, Зыятдинов Ризатдин, Абдуллин Гыйният хуҗалыкларына тоташтырыла.

1947 ел, 3 апрель – язгы ташу суы белән 1932 елда салынган агач күпер китә. Икенче көнне бүрек киеп йөрерлек суык була (Заһретдинов Гыльметдин сөйләгәннәрдән).

1948 ел – мәктәпкә укытырга Гаянова Сафия килә.

1948 елның май аенда Юлбатта беренче тапкыр тавышлы кино күрсәтелә. Киномеханик – Сатыш авылы егете Габделәхәтов Габделбәр. Соңгы тапкыр Юлбат клубында кино 2004 елда күрсәтелә. Киномеханик – 11 класс укучысы, Габделәхәтов Габделбәрнең оныгы Сафин Радик Илдар улы.

1950 ел – Юлбатта Факия апа өендә (хәзер Халиков Илшатлар урыны) медпункт ачыла.

1952 ел – Мифтахетдин бабай Шәһри Болгарны зиярәт кылган.

1953 ел – түбәндәге колхозлар берләшә:

Юлбат "Ворошилов",

Тенеки "Яңа юл",

Йосыф-Алан "Магнит"

Берләшкән колхозга Ворошилов исеме бирелә.

1954 ел – колхозга "ГАЗ-51" машинасы кайта.

1955 ел – мәктәпкә Шляпина Сәлимә укытучы итеп билгеләнә.

1956 ел – Ворошилов исемендәге колхозның исеме "Искра" колхозы итеп үзгәртелә.

1956 еллар – Сафин Насыйбулла авылда беренче велосипед ала.

1958 ел – МТСлар бетерелә, техника колхозларга сатып бирелә. Шул елны “Искра” колхозына 5 трактор, 5 комбайн тракторчылары, комбайнчылары белән кайта.

1958 ел – Тенекидә китапханә ачыла.

1960-1961 еллар – Ильич лампалары кабына. Электрлашу Юлбат белән Тенекидә – 1960, Йосыф – Аланда 1961 елда төгәлләнә.

1960 ел – Юлбатка Ракова Саҗидә парторг булып килә һәм мәктәпкә рус теле укытучысы итеп билгеләнә.

1961 ел – 2000 башка исәпләнгән чеби торагы төзелә.

1961 ел – табигый таштан техника ремонтлау өчен мастерской салына. 2013 елда сүтелде.

1962 ел – Тенекидә агач күпер салына (баганалары таш, таш фундаментта).

1966 ел – колхозчылар хезмәтенә акчалата түләү кертелә.

1965-1966 елларда авылда беренче телевизорны Низамиев Габделхай ала, аннан соң колхоз идарәсенә куела, соңрак Гайфуллин Вәлимөхәммәт, Сафиуллин Хәй хуҗалыклары ала.

1966 ел, октябрь – клуб тирәсе (хәзер мәчет) комсомол-яшьләр тарафыннан рәшәткәләп алына.

1967 ел, ноябрь – Бөек Ватан сугышында һәлак булучылар истәлегенә обелиск ачыла.

1970 ел – колхозда 5 йөк автомашинасы, 6 комбайн, 11 трактор була.

1971 ел – КПСС өлкә комитеты бюросы, ТАССР Министрлар Советы карары белән “Искра” колхозына “Игенчелектә югары культуралы хуҗалык” исеме бирелә һәм Диплом белән бүләкләнә.

1972 ел – СССР төзелүнең 50 еллыгына багышлап оештырылган Бөтенсоюз социалистик ярышта иң югары нәтиҗәләргә ирешкән өчен “Искра” колхозы КПСС Үзәк Комитеты, СССР Югары Советы Президиумы һәм СССР Министрлар Советы карары белән Юбилей Почет билгесе белән бүләкләнә.

1972-1973 еллар – Юлбаттан олы юлга дамба салына.

1974-1975 еллар. Юлбатта яңа башлангыч мәктәп салына.

1975 ел – авыл уртасыннан ага торган инеш суы аша зур таш күпер салына.

1976 ел – заманча ремонт мастерское төзелеп бетеп файдалануга тапшырыла.

1978 ел – китапханә Тенекидән Юлбатка күчерелә.

1979 ел – башлангыч мәктәпкә укытырга Мәртен сигезьеллык мәктәбендә математика укыткан Хаҗиева Фәния Нургали кызы кайта.

1980 ел – Тенеки белән Юлбат арасында 200 башлык сыер торагы эшләнә башлый.

1982 ел – Юлбатта сигезьеллык мәктәп ачыла.

1982 ел, 3 сентябрь – Юлбатта зур янгын була. Аның нәтиҗәсендә урамның бер ягыннан хәзер Бадикова Земфира яшәгән урыннан алып Исламов Рузитлар яшәгән урын кереп, икенче яктан Галиев Шамилләрдән алып Сәләхов Рифатларга кадәр, 20 хуҗалык бөтенләй янып бетә. 5 хуҗалык өлешчә яна.

1986 елның башында колхозда 19 автомашина, 26 трактор, 19 комбайн (“Нива”, “Колос”), 5 бульдозер, 2 автобус була.

1986 ел – колхозда тракторист-машинист таныклыгы булган 60 механизатор эшли.

1986 ел – яңа культура йорты ачыла.

1987 ел – Бөек Ватан сугышында һәлак булучылар истәлегенә куелган обелиск реставрацияләнә, өске өлешенә солдат сыны куела.

1989 елның 1 сентябрендә Юлбат авылында типовой проект белән эшләнгән ике катлы мәктәп бинасы файдалануга тапшырыла. Сигезьеллык мәктәп урта мәктәп итеп үзгәртелә.

Авылдан чыккан беренче хаҗга баручы кеше – Фәтхуллин Габделхәй Габдрәүф улы (туксанынчы елларда хаҗ кыла).

1993 елның 11 ноябре – Йосыф-Алан башлангыч мәктәбендә төнлә янгын чыгып, мәктәп тулысынча янып бетә.

Юлбатта 1993 елда элеккеге мәчет нигезендә яңа мәчеткә фундамент салына. Ул 1996 елның 31 декабрендә ачыла.

1993 ел – Юлбат мәктәбенә район мәктәпләреннән иң беренче булып видеокамера алына. Видеомагнитофон, телевизор алынып, видеокабинет җиһазлана. Кабинет җитәкчесе, аны булдыруда башлап йөрүче – тарих укытучысы Сафин Илдар Фатхулла улы.

1994 ел, март – “Искра” колхозы “Искра” күмәк предприятиесе” итеп үзгәртелә.

1994 ел – Юлбат урта мәктәбе укучылары беренче тапкыр Шәһри Болгарга экскурсиягә бардылар. Оештыручы – тарих укытучысы Сафин Илдар Фатхулла улы.

1995 елның 1 марты – Юлбат авылы 538 нче мәхәллә буларак теркәлә.

1995 ел, 9 Май – Җиңүнең 50 еллыгына мәктәптә “Туган як“ музее ачылды. 1995 ел – Юлбат мәчетенең 1939 елда төшерелгән ае мәктәп музеена тапшырылды.

1997 ел, 30 декабрь. Авылда беренче газ горелкасы Сәләхов Әхтәри йортында кабына. Аннан соң Галиев Шамил, Хәсәнов Равилләр хуҗалыгына газ кертелде.

1998 ел – Юлбат – Саба дамбасы асфальтланды. Калай түбәле ашлык склады төзелде. Мастерской каршындагы ферма эшләнеп бетеп, файдалануга тапшырылды.

2002 ел, 2 февраль – районда “Яңарыш авазлары”конкурсы кысаларында күмәк хуҗалык көне үткәрелде.

2003 ел, 1 апрель – “Искра” күмәк предприятиесе “Юлбат“ крестьян-фермер хуҗалыгы итеп үзгәртелде.

2003 ел, 3 октябрь – Тенекидә яңа күпер ачылды.

2003 ел, 17 октябрь – мәдәният йорты бинасына җирле үзидарә Советы кертелде.

2006 ел – Йосыф-Алан авылында башлангыч мәктәп өчен яңа бина сафка басты.

2007 елның январь ае – “Юлбат” крестьян-фермер хуҗалыгы “җаваплылыгы чикләнгән “Юлбат” авыл хуҗалыгы предприятиесе җәмгыяте” итеп үзгәртелә.

2008 ел – Тенекидә башлангыч мәктәп ябылды.

2009 – Тенеки мәктәбе бинасы, халык көче белән ремонтланып, мәчет буларак, халыкка кайтарылды.

2010 ел – Юлбат балалар бакчасы урта мәктәп остаханәсенең ир балалар шөгыльләнгән кабинетына күчерелде.

2011 елның май аенда мәктәптәге барлык укытучы һәм тәрбиячеләргә персональ ноутбук бирелде.

Мәктәпкә 3 интерактив такта, 4 проектор кайтты.

2012 ел – балалар бакчасын киңәйтү максатыннан, мәктәп остаханәсенең кыз балалар өчен булган ике бүлмәсе балалар бакчасы өчен алынды. Остаханә тулысынча мәктәп бинасына күчте.

2013 ел, 28 июнь – 9 класс укучысы Кәримова Гүзәл Сабада Универсиада утын кабызу эстафетасында катнашты.

2013 ел, 26 август – халыкта “Чирмеш зираты” дип йөртелгән урынга агач утыртылды.

2013 ел – Йосыф-Алан башлангыч мәктәбе ябылды, аның бинасында балалар бакчасы эшли башлады. Бу елда анда 6 бала йөрде.

2014 ел – Бөек Ватан сугышында һәлак булучылар истәлегенә яңа обелиск куелды.

## Юлбат авылы атамасы, авылның барлыкка килү вакыты риваятьләрдә һәм тарихи документларда

Юлбат, Тенеки, Йосыф-Алан, Калатау авыллары безнең көннәрдә заманча төзелешле, матди яктан нык авыллардан саналалар. Һәркайсының ерак гасырларга киткән тарихы бар. Бу тарихның башлангычы бүгенге чорга өзек-өзек мәгълүматлар булып кына яңгырап ишетелә кебек.

Туган ягыбызның үткәненә сәяхәткә кайдан чыгарга соң?

Табигый буларак, һәр авылның исемен атауга, аның мәгънәсен ачыклау теләге уяна. Кайдан килгән бу атама, нәрсәгә нигезләнгән, ни аңлата?

Юлбат авылының килеп чыгышы һәм аның атамасына ачыклык кертү өчен риваятьләргә һәм тарихи чыганакларга мөрәҗәгать иттек.

Риваятьләрнең берсендә сөйләнгәнчә, безнең якларда иң беренче чирмешләр (мари) яшәгән. Бу турыда хәзерге вакытта да Чирмеш чишмәсе дип аталучы чишмә һәм сакланып калган чирмеш зираты урыны сөйли. Авылга нигез салучы беренче кеше Ямбулат (Янбулат) исемле була. Мамадыш өязенә авылны теркәтергә баргач, “Ямбулат” дигән сүзне рус кешесе Юлбат дип язып куйган. Әнә шуннан соң авылыбыз Юлбат дип йөртелә башлый. (Бу риваятьне Юлбатта туып-үскән һәм 1872-1959 елларда яшәгән Нуриәхмәтов Хаҗиәхмәт сөйләп калдырган.)

Ә татарлар безнең якларга кайчан килеп утырган соң? Иван Грозный Казан ханлыгын җимергәннән соң, руслардан качкан татарлар безнең авылга күчеп утырган, дигән фикер яши.

1919 елда туган Мәрдәнов Хәбибрахман абый сөйләве буенча, “Юлбат” атамасының килеп чыгышы башкачарак аңлатыла. Җөри ягыннан килеп, тау битләп Сатыш, Юлбат авыллары аша үтүче лашманчылар (урман кисүчеләр) юлы булган (аның эзләре хәзер дә билгеле). Юл, безнең зиратның аскы өлешен кисеп чыгып, Карачтау аша Караклар юлына барып чыга, аннан Әби патша юлына барып тоташа. Зират тау итәгенә урнашкан, хәзер дә аннан берничә чишмә чыга. Бу урыннан үткәндә, юлчылар, юл бата, юл бата, дип әйтә торган булганнар. Шуннан авылга “Юлбат” исеме бирелгән.

Бу фикерне Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Гали Ильясов та әйткән иде. Аның әтисенең, Юлбатта туып 14 яшькәчә шунда яшәп, соңыннан читтә гомер иткән Миңлегали абыйның әйтүе буенча, гаиләләрендә авыл тарихы язылган тире тышлы калын дәфтәр булган, кызганычка, ул янгынга эләгеп юкка чыккан. Ул вакытта Миңлегали абый яшүсмер малай гына булганлыктан, китапның эчтәлеген бик аз хәтерли. Шулай да үз нәселе кешеләренең Юлбатка ничек килеп чыгуы турындагы риваятьне китаптан укыганын яхшы белә иде. Аның исендә калганнар буенча, аларның ерак бабалары, Әлмәт ягыннан килеп (мөгаен, лашман юлыннан килгәннәрдер), чишмәле тау итәгеннән үткәндә, юл бата, барып булмый, монда гына калабыз, дип, хәзерге Юлбат урынында төпләнеп калганнар.


№ 429 КВИТАНЦІЯ на 2р. 47к.

Казанской Губернской Земской Управы.

1909 года Января 31 дня получено и записано по общему кассовому приходному журналу въ ст. подъ № 471 отъ Абдралима Абдулгазизова, д. Ямбулатовой, Сатышевской вол. Мамадышскаго у. за плугъ

два руб. сорокъ семь коп.

Кассиръ

Бухгалтеръ

Сука налогы түләгән өчен бирелгән квитанция. Авылның исеме Ямбулат. 1906 ел.


Сохрани извещение для пред'явления при всяком обращении в агентство.

Р.С.Ф.С.Р.

ГОСУДАРСТВЕННОЕ СТРАХОВАНИЕ

Срок взноса оклада 15/II 192 г.

СТРАХОВОЕ ИЗВЕЩЕНИЕ

При невзносе страховки в срок начисляется ПЕНЯ

№ 5 / 5312 по поселенному списку

Граждан Хайбуллин Ахмет. Селения Ямбулатово

Уезда (Округа, Кантона) Мамад. Волости (Района) Сабинская

| Ваше имущество застраховано по обязательному окладному страхованию | | | | Может быть застраховано дополнительно | | ОТМЕТКА ОБ УПЛАТЕ |
|---|---|---|---|---|---|---|
| СТРОЕНИЯ | Оценка в руб. | Застраховано в руб. | Начислено | В сумме | Причитается платежа | УПЛАЧЕНО |
| ЖИЛЫЕ 1. Дом (изба, хата) | | | | | | Недоимки |
| 2. | | | | | | Оклада 3 рубля |
| 3. | | | | | | Пени |
| НАДВОРНЫЕ 4. Двор (навес, забор, ворота) | | | | | М. П. | Принял |
| 5. | | | | | | 3/II 1928 / 192 г. 2043 |
| 6. | | | | | | УПЛАЧЕНО |
| 7. Сарай | 320 р. | 225 | | | | Недоимки |
| 8. | | | | | | Оклада 3 р 18 |
| ВНЕ ДВОРА 9. Амбар | | | | | М. П. | Пеня 3 |
| 10. Баня | | | | | | Принял |
| 11. Овин (рига) | | | Сумма | | | 7/II 1928 г. |
| 12. | | | Руб. К. | | Руб. К. | УПЛАЧЕНО |
| ИТОГО 1. По постройкам от огня | | | 2 | | | Недоимки |
| 2. Посевы от градобития | 5,8 дес. | 77 | 77 | 77 | 17 | Оклада |
| 3. Кр. рог. скот (От падежа) | 1 гол. | 25 | 18 | 10 | 6 | Пени |
| 4. Лошади | 1 гол. | 40 | 27 | 40 | | Принял |
| 5. Движимое имущество | | | | | | / 192 г. |
| 6. | | | | | | |

Оклада

Татполиграфа. Заказ № 968

Хәйбуллин Әхмәтҗан исеменә бирелгән извещение. Авылның исеме Ямбулат. 1928 ел.

Авыл атамасының килеп чыгышы турында фаразларның тагын берсен карап китик. Юлбат авылында гомер кичергән (хәзерге көндә вафат) Гыйлемсара апа Мифтахова сөйләгәннәр буенча, улы Мифтахов Хәнәфия язып алып калган аны. "Минем иремнең әтисе Мифтахетдин бик кызыксынучан, эзләнүчән кеше иде. Якын-тирә авылларның атамалары турында миңа ул менә ниләр сөйләде: "Авыллар оешкач, кайберләренә атама табу мәсьәләсе килеп туган. Шушы авыллар аша агучы елга буйлап йомычка агызып җибәргәннәр. Шул йомычканың торышына карап авылларга исем бирергә уйлаганннар. Иң беренче ул Килдебәк авылы аша үтәргә тиеш булган. Ләкин йомычка күренмәгән. Килдебәклеләр: "Килде, бәк. Күренмәде ул йомычка", – дип сөйләнеп йөргән, диләр. Килдебәк атамасы шуннан килеп чыккан, имеш. Туктар авылы турысында йомычка бик озак тукталып торган, шунлыктан әлеге авылга Туктар, дигәннәр. Ә безнең Юлбат авылы турысында йомычка бөтенләй үк батып калган. Шунлыктан әлеге авылны Юлбат дип атаганнар, имеш. Авыл атамалары хакында башка риваятьләр дә бар. Кайсы дөрес икәнен әйтә алмыйм", – дигән Мифтахетдин бабай.

Билгеле, риваятьләрнең кайсында хаклык күбрәк булуын бүгенге көндә ачыклау мөмкин эш түгелдер. Ничек кенә булмасын, Юлбат авылының ике исем белән – Ямбулат һәм Юлбат – аталып йөрүе тарихи документларда расланган. Ямбулат атамасы борынгырак булырга тиеш. Юлбат атамасы авылга кайчан бирелгән, дигән сорауга тарихи документлардан җавап эзләп карадык. 1906 елда Казан губернасы Земская Управа тарафыннан Абдрахим Абделгазизовка сука налогы түләгән өчен бирелгән квитанциядә безнең авыл "Мамадыш өязе, Сатыш волосте, Ямбулатово авылы" дип язылган. 1928 елда Хәйбуллин Әхмәтҗан исеменә бирелгән страховое извещениедә Мамадыш өязе, Саба волосте, Ямбулатово авылы дип язылган.

Бу сорауга җавап эзләп, өлкәннәрнең истәлекләренә мөрәҗәгать итик. Халык хәтере могҗизага тиң бит ул: ниләр генә сакланмый аның сандыгында.

Истәлекләрдән юлларны Ракова Сажидә апаның көндәлек битләреннән үзгәртмичә китерәбез.

23.11.89. 1906 елгы Габделхәй абый: "Безнең авыл элек "Юлбулат" исемле булган, Иван Грозныйдан качып, Казаннан татарлар күчеп килгән, башлап килүче Юлбулат исемле кеше булса кирәк", – ди. Әле мин белгәндә Каравыл өе янындагы тактага (хәзерге Галиев Фәнисләр урынында) "Юлбулат авылы" дип язып куелган иде, ди. Саба волосте төзелгәч, "Юлбат" дип йөри башладылар, дип хәтерли.

1900 елгы Ихсан бабай авылда адрес яза алучы Мифтахетдин абзыйның да конвертка "Юлбулатове" дип язуын әйтә.

Ә Мифтахетдин абзый хәтерләвенчә, 1917 елга кадәр "Ямбулатово" дип адрес язганнар. Революциядән соң авыл Юлбат дип атала башлый, дигән ул.



Айрат Заһидуллинның нәсел җепләре әтисе Җиһангир ягыннан Юлбатка барып тоташа


Татарстан җөмһүрияте милли китапханәсенең кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире Заһидуллин Айрат Җиһангир улы фикеренчә, авыл татарча Юлбулат дип аталган. Моны Татарстан милли архивындагы метрикәләр раслый. 1865 елгы метрикәдә гарәп хәрефләре белән шулай язылган, ә русча тышлыгына Янбулат дип күрсәтелгән. 1866 елдан соңгы Метрикәләрдә авыл муллалары гарәп графикасында "Юлбат" дип язганнар, ә русча тышлыклар Янбулат исеме белән бирелү дәвам иткән. Бәлки, авылга беренче килеп утырган кеше Юлбулат исемле булгандыр. Ул очракта "Юлбат" атамасы – "Юлбулат"ның кыскартылма варианты булырга мөмкин. Ә русча документ тутыручылар таныш түгел телдәге сүзне Янбулат (кайбер чыганакларда Ямбулат) дип язып куйгандыр. Авылның баштагы исеме Юлбулат булуын раслап, 1865 елгы Метрикәнең күчермәсеннән өзек китерәбез. Кириллицага Айрат Заһидуллин күчерде.

| 3 нче җөзъэ вафат улан кемсәнәләр хакында | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| № | № | җенесе, исеме | ай | | | | Сәбәбе | Урыны |
| 1 | – | ир Хәсәнетдин | февраль | 13 | 65 | яшендә | борран зәхмәте вафат булды | Мамадыш өязе Юлбулатта дәфен улынды |
| 2 | – | ир Гатаулла | март | 14 | 38 | яшендә | ютәл зәхмәте илә вафат булды | Мамадыш өязе Юлбулат авылында дәфен улынды |
| – | 1 | кыз Садыйкабану | июнь | 12 | 3,5 | айлык көнлек | зияндан зәхмәте илә вафат булды | Мамадыш өязе Юлбулат авылында дәфен улынды |
| – | 2 | кыз Сәрвиҗамал | июнь | 16 | 3,8 | айлык көнлек | зияндан зәхмәте илә вафат булды | Мамадыш өязе Юлбулат авылында дәфен улынды |


| 2 нче җөзъэ 2 нче фасыл талак вакыйгъ улан кемсәнәләр хакында вә хәлегъ | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Казан губернасы Мамадыш өязе Сатыш волосте Юлбулат авылының Мифтәхетдин Галикәйугылыхатыны Хөрбану Габделвәли кызын хәлегъ кылды. | 15 сентябрьдә | Мәхәббәт юклыктан | Мәҗлестә хазир шаһидләре мелла Бәһман мелла Исхак угылы, Төхфәтулла Габдулла угылы | Юлбулат авылында указной мелла Һибәтулла Габделваһаб угылы ошбу хәлегънамәне язды |

| 2 нче җөзъэ әүвәлге фасыл никях уланлар хакында | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Казан губернасы Мамадыш өязеСатышволостеЮлбулат авылының Мәхфүзә Әхмәд кызы 26 яшендә шулук волость Сатыш авылының Гыйбадулла Гатиятулла угылына никяхландырылды. Кияү 25 яшендә. 2-се дә бакирә. | 25 нче февральдә | Кыз тарафыннан бер тугъма агасы Динмөхәммәд Әхмәд угылы вәли вәкил булды. Кияү тарафыннан атасы Гатиятулла Нәзир угылы вәли вәкил булды. Зәүҗәен ризалыкларының шаһидлары Мөхәммәдсафа Әмирхан угылы, Сиражетдин Бикчәнтай угылы. | Мәһәре мөсәмми 3 йөз сум, хазирдә йөз ....... сум бирелде. |
| 2. | Казан губернасы Мамадыш өязе Сатыш волосте Юлбулат авылының Хөрбану Габделвәли кызын шулук авылның Мифтәхетдин Галикәй угылына 26 яшендә никяхландырылды. Кияү 24 яшендә. Кыз тол. Кияү бакирә. | 12 нче июльдә | Кыз тарафыннан атасы Габделвәли Заһир угылы вәли вәкил булды. Кияү тарафыннан атасы Галикәй Хөсәен угылы вәли вәкил булды. Зәүҗәеннең ризалыкларының шаһидлары Бикмөхәммәд Заһир угылы, ....улла Фәтехулла угылы. | Мәһәре мөсәмми йөз сум, хазирдә 2 тәнкә. |
| 3. | Казан губернасы Мамадыш өязе Сатыш волосте Юлбулат авылының Хубҗамал Әхтәм кызы 28 яшендә шулук авылның Мөхетдин Хәсән угылына никяхландырылды. Кияү 38 яшендә. Кияү тол. Кыз бакирә. | 30 нчы августта | Кыз тарафыннан энесе Мөхәммәдшаһ Әхтәм угылы вәли вәкил булды. Кияү булгучы Мөхетдин Хөснетдин угылы мәҗлестә үзе хазир булып алды. | Мәһәр ....... |
| Юлбулат авылында соборный имам учитель Һибәтулла Габделвәһаб угылы кулым куйдым. | | | | |

| Җөзъэ әүвәл вөҗүдә киләнләр хакында<br>иркыз | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| - | 1 | кыз бала Бибигафифә | 4 нче гыйнвар | атасы зирагатьче Җарулла Гайфулла угылы, анасы Асылбикә | Казан губернасы Мамадыш өязе Юлбулат авылында туды |
| - | 2 | кыз бала Мөфәррихә | 9 нчы гыйнвар | атасы зирагатьче Сөнгатулла мелла Һибәтулла угылы, анасы Бибифәтихә | Казан губернасы Мамадыш өязе Юлбулат авылында туды |
| 1 | - | ир бала Сәйфетдин | 2 нче февраль | атасы зирагатьче Гыйльман Шәмсетдин угылы, анасы Шәмсеҗиһан | Казан губернасы Мамадыш өязе Юлбулат авылында туды |
| - | 3 | кыз бала Сәрвиҗамал | 4 нче февраль | атасы зирагатьче Әхмәди Әхтәм угылы, анасы Шәмсеҗиһан | Казан губернасы Мамадыш өязе Юлбулат авылында туды |
| 2 | - | ир бала Нигмәтулла | 14 нче февраль | атасы зирагатьче Һибәтулла Гобәйдулла угылы, анасы Хәнифә | Казан губернасы Мамадыш өязе Юлбулат авылында туды |
| 3 | - | ир бала Ибниямин | 23 нче февраль | атасы зирагатьче Хәсән Бикмөхәммәд угылы, анасы Шәфикаҗамал | Казан губернасы Мамадыш өязе Юлбулат авылында туды |
| - | 4 | кыз бала Сыйдкабану | 24 нче февраль | атасы зирагатьче Сәгыйт Габделвәли угылы, анасы Фәрһизбану | Казан губернасы Мамадыш өязе Юлбулат авылында туды |
| - | 5 | кыз бала Латыйфә | 25 нче март | атасы зирагатьче Гайнетдин Хисаметдин угылы, анасы Мәфтүхә | Казан губернасы Мамадыш өязе Юлбулат авылында туды |
| 4 | - | ир бала Мөхәммәд-шакир | 6 нчы апрель | атасы зирагатьче Әхмәдшаһ Габид угылы, анасы Шәмселкамәр | Казан губернасы Мамадыш өязе Юлбулат авылында туды |
| - | 6 | кыз бала Бибиәсма | 21 нче майда | атасы зирагатьче Мифтахетдин Хәсәнетдин угылы, анасы Әшрәф | Казан губернасы Мамадыш өязе Юлбулат авылында туды |
| - | 7 | кыз бала Васфиҗамал | 26 нчы июнь | атасы зирагатьче Тыйб Әййүб угылы, анасы Шәрифә | Казан губернасы Мамадыш өязе Юлбулат авылында туды |
| - | 8 | кыз бала Хөсниҗамал | 25 нче июль | атасы зирагатьче Гали Бикбау угылы, анасы Гарифә | Казан губернасы Мамадыш өязе Юлбулат авылында туды |
| - | 9 | кыз бала Фатыйма | 27 нче июль | атасы зирагатьче Мөхәммәдсафа Бикмөхәммәд угылы, анасы Фәхриҗамал | Казан губернасы Мамадыш өязе Юлбулат авылында туды |
| - | 10 | кыз бала Гафиябану | 24 нче декабрь-дә | атасы зирагатьче Гатиятулла Фәтхулла угылы, анасы Шәмсебану | Казан губернасы Мамадыш өязе Юлбулат авылында туды |



1865 елгы Метрикәнең русча тышлыгы



Метрикәнең гарәп хәрефләре белән язылган
эчке бите

Димәк, югарыда санап кителгән истәлекләргә һәм 1865 елгы Метрикәгә нигезләнеп, авылның баштагы татарча исеме Юлбулат булуын ышанып әйтә алабыз. Ә русча язылган тарихи чыганакларда авыл “Ямбулатова” (1887), “Янбулатова” (1834), “Ямбулатово” (1891), “Ямбулатово Юлбанъ” (1897), “Ямбулатово (Юлбат)” (1907), “Ямбулатово Юлбанъ” (1908) исемнәре белән бирелә. Исемнәрдән күренгәнчә, русча документларда авыл ике исем белән – Ямбулат һәм Юлбат – йөртелгән.

Төгәл кайсы елдан Юлбат дип йөртелә башлавын һәм авылга кайчан нигез салынуын документлар нигезендә ачыклап булмады.

Кайбер фаразлар буенча, почта хезмәтендә безнең авылны Теләче районындагы Ямбулат авылы белән бутау очраклары булган. Ләкин, тарихи чыганаклардан күренгәнчә, Теләче районындагы Ямбулат авылы “Ямбулатова Пустошь, Кукча” дип йөртелгән. И.А.Износковның 1884 елда чыккан “Труды четвертаго археологического съезда въ России” китабында бу авыл турында болай язылган: Ямбулатова Пустошь, Кукча. Д. при впадении рч. Кукчы въ Мешу, отъ г. 64 в…, жит. тат. (85 м. 87 ж.) основание дер. относятъ къ концу XV ст.

Юлбат авылы әлеге чыганакта болай бирелгән: Ямбулатова. Д. при рч. Сабинкъ, отъ гор. 72 в.., жит. тат. (294 м. 278 ж) Названия, как этой, так и предыдущей деревни, даны по имени первого поселенца.

Бу мәгълүматтан кү-ренгәнчә, Теләче районындагы Ямбулат Күкчә елгасы Мишәгә койган урында, Юлбат-Саба елгасы буенда урнашкан.

Бу урында Гомәр Саттаровның “Мәктәптә оно-мастика” дигән китабына таянып аңлатма биреп китү урынлы булыр. Ул Саба (Сабинка) дип атала торган ике инеш булуын әйтә. Алар икесе хәзер дә янәшә агалар, диелә.

Бу елгалар турында 1884 елда чыккан “Труды статистической экспедиции, снаряженной въ 1883 году Казанским губернскимъ земствомъ” хезмәтендә болай бирелгән: “Рѣчка Саба беретъ свое начало близь деревни Сабабашъ и впадает въ Большую Мешу близь деревень Акуль и Казанча – Бигеней. Съ севера на юг посрединъ его протекает небольшой ручей (называемый тоже Сабою), впадающий въ рѣчку Сабу несколько ниже средины ея течения. На этом ручье лежать три деревни: двѣ изъ этихъ деревень – самыя большия деревня района: Сатышево и Сабы Богатые.” Ике чыганакта да Ямбулат (Юлбат) авылы Саба елгасы буенда урнашкан, дип әйтелә. Бәлки, Казкаш атамасы елгага соңрак бирелгәндер?

М.Хәсәнов редакциясендә чыккан Татар энциклопедия сүзлегендә (Казан, 1999) әлеге елга Казкаш исеме белән бирелә: “Юлбат, село в Сабинском районе, на р. Казкаш (прав. приток р. Меша) в 6 км от с. Богатые Сабы. В 1989 – 453 жит (татары). На 1997 – 454 тат. ср. школа. Полеводчество, скот-во. Осн. в 16 веке”.

“Татарлар килгәнче бу авылда чирмешләр (марилар) яшәгән. “Дәрә” җыю шулардан калган. (1960 елда да җыялар иде әле.) Юлбатта аргы як тауга Зәйнуллиннар турыннан елга кырыйлап менсәң, чирмеш зираты түмгәкләре бар иде әле”, – дип яза Саҗидә апа үзенең көндәлегендә. Хәзер ул урында табигый ташлар гына ята. Тенеки зираты читендә дә (Юлбат ягы) чирмеш зираты урыны

бар. 2011 елның октябрь аенда Гыйззетдинов Нуретдин (1935 елгы) абый белән ике авылның да чирмеш зираты урынын барып карадык, фотога төшердек. Зират урынын аңа Ихсан бабай (1900 елгы) күрсәткән булган. (*Сафин И.Ф. искәрмәсе.*)

Кызганыч, Юлбатның чирмеш зираты урыны да 2013 елның 26 августында үзгәреш кичерде: бу урынга агач утыртылды. Киләчәктә бу җирдә агачлар шаулар, халык гөмбә, җиләк җыяр (бу урыннар хәзер дә җир җиләгенә искиткеч бай иде). Кайчандыр бу урында чирмеш зираты булуы турында искә дә алучы булмас, чөнки зираттагы кабер өстенә куелган табигый ташлар агач арасыннан элеккечә күренеп тормас инде.

Авылның килеп чыгышы, исеме турында риваятьләр шулайрак сөйли. Хәзер инде тарихи документларга мөрәҗәгать итеп, Юлбат авылының барлыкка килү вакытын ачыкларга тырышып карыйк.

Авыл тарихы буенча материаллар эзләгәндә, халык санын алу документларын һәм мәчет метрикаларын карадык. Иң беренче нинди документларда телгә алына соң безнең авыл? Татарстан Милли архивында 1719-1724, 1748, 1768 еллардагы халык санын алу документлары саклана. Алар электрон вариантта Мәскәүдән кайтартылган. 1719 елгы Беренче “Ревизская сказка”да Сабы (Вершина Сабы), Казанчи Шитцы, Нижние Шитцы, Большая Меша, Средняя Меша, П.Мамалаево һәм башка кайбер авыллар бар, ләкин безнең Ямбулат, Тенеки, Мәртен, Туктар авыллары юк. 1748, 1768 еллардагы “Ревизская сказка”да шулай ук безнең авыл турында мәгълүматлар юк. 1798 елгы Мамадыш өязе картасында Ямбулат авылы күрсәтелгән. Бәлки, Санкт-Петербург, Мәскәү, Уфа һәм башка шәһәр архивларында бардыр, без алар белән хәбәрләшә алмадык.



Чирмеш зираты урыны. Унда Нуретдин Гыйззетдинов

Казан архивларында безнең авыл турында беренче мәгълүмат 1834 елдан башлана. 1834 елгы сигезенче “Ревизская сказка” (тысяча восемьсот тридать четвертого года апреля восьмого дня, Казанской губернии Мамадышеского уезда Староикшурминской волости деревни Янбулатовой о состоящих мужеска и женска пола ясашных татар) буенча Ямбулатта 193 ир-ат (шулардан 3 се – 2 унтер офицер һәм 1 мастеровой – ясактан азат ителгән), 130 хатын-кыз, барлыгы 53 гаилә күрсәтелгән.

1850 елгы “Ревизская сказка” буенча, Янбулат авылында 214 ир-ат, 170 хатын-кыз. Гаиләләр – 57. Шуны да искәртеп үтәргә кирәк, “Сказка”ларның соңгы битендә исемлекнең авыл җыенында 3 тапкыр укылуы әйтелгән, кул куйган, печать баскан кешеләрнең фамилияләре күрсәтелгән (“Ревизская сказка”лар күчермәсе кушымтада биреләчәк).

Хәзер авылда халык санын өйрәнер өчен төп чыганак булып торган “Ревизская сказка”лар турында бераз аңлатма биреп китик.

Русьта налог җыю өчен әледән-әле халык исәбе алынып торган. Беренче халык исәбе алыну елы булып 1245 ел исәпләнә, гәрчә аңа кадәр дә исәпкә алу үткәрелсә дә. 1718 елда Петр Беренче указы белән налог җыюга үзгәрешләр кертелә. Налоглар элеккечә бары тик ир-атлардан гына җыелачак, ләкин моңа кадәр булганча двордан түгел, ә гаилә башлыгы булган ир кешедән. (Бу закон чыкканчы, ата-ана өйләнгән улларын үз ишегалдына башка чыгарган һәм, бер двор булгач, ике гаилә яшәсә дә, бер двор өчен генә налог түләгән). Петр патша указыннан соң үткәрелгән халык санын алу документлары “Ревизская сказка” дип йөртелә башлый. Ни өчен шулай аталган? Халык санын кемнәр алган?



Юлбат зиратындагы 1815 елгы кабер ташы. Мулла Баязит Биккенә угылына куелган

Шәһәрләрдә – шәһәр башлыклары, дәүләт крестьяннары яшәгән авылларда – старосталар, крепостной крестьяннар яшәгән авылларда алпавытлар үзләре халык санын алу үткәргән. Перепись нәтиҗәләре соңыннан бик яхшылап тикшерелгән, ягъни ревизия үткәрелгән. “Ревизская” сүзе шуны аңлата. Бу дөреслекне тикшерү налогларны тиешенчә җыйнау өчен кирәк булган, чөнки крестьяннар өчен налогны алпавыт үзе түләгән, димәк, ул крестьяннар санын киметеп күрсәтергә дә мөмкин булган. Тикшерүгә өч елга кадәр вакыт киткән. “Сказка” сүзе список дигәнне белдерә. 1718-1858 елларда барлыгы ун “Ревизская сказка” үткәрелгән (1719, 1742, 1762, 1782, 1795, 1811, 1816, 1836, 1851, 1858 елларда). 1961 елда, крепостное право бетерелгәннән соң, халык санын алу ревизская сказка формасында үткәрелмәгән һәм алай аталмаган да.

**Юлбат һәм Тенеки авыллары зиратларындагы кабер ташлары**



*Алгы ягында:*
1) Кәфә бил-мәүт вә әгъзан
2) ошбу кабердә әл-мөтә-
ваффа мәрхүм
3) Илъяс Ишнияз угылы
4) вафат 45 яшендә
*Үлчәмнәре:* 66×60×8 (см)



Агачтан ясап куелган кабер өсте истәлеге.
*Алгы ягында:*
1) Күлли мән галәйһа фанә
2) ошбу кабер иясе мәрхүм
3) Мөбәракша Тимербай
угылы
4) вафат һиҗри сәнә 1357
25 нче
5) зөлхиҗҗә милад 1939
6) 14/II 67 яшендә
*Үлчәмнәре:* 67×40×12 (см)



Тенеки авылы зираты читендәге аерым агач коймалы каберлек; ташы, авыл кешеләре сөйләвенчә, 1920-1930 нчы елларда куелган.
*Алгы ягында:*
1) Лә иләһә иллә Аллаһы
Мөхәммәд
2) рәсүлуллаһе
3) бу кабердә
4) Мөхәммәтҗан җәмәгате
5) ... ...
*Үлчәмнәре:* 48×33×4 (см)



*Алгы ягында:*
1) Һәза мәркадь
2) мәрхүм
3) Мөхәммәдвәли Илъяс
угылы
4) вафат 1904 елда
5) 15 мартда
6) рабби әгъфирә би хөрмәти
7) әл-фатиха



*Арткы ягында:*
1) Бисмиллаһи
2) әр-рахмани рәхим
3) фәәгъләмү әннәһү лә
4) иләһә иллә Аллаһы
Мөхәммәд
5) рәсүлуллаһе

*Уң ягында:*
1) мәдфүн
2) 29
3) яшендә

*Сул ягында:*
1) Күлли нәфсин
заикател-мәүт

*Үлчәмнәре:*
62×30×20 (см)

Тагын шуны әйтеп үтәргә кирәк, ике “Ревизская сказка” арасында үлүчеләр, теге яки бу сәбәп белән налогтан азат ителергә тиешлеләр (солдатка китү, үлү, социаль статусы үзгәрү) булса да, ясак түләү киләсе “Сказка”га кадәр дәвам иткән.

“Ревизская сказка”да гаилә членнарының туган елы, гаилә башлыгына мөнәсәбәте, нинди катлауднан булуы күрсәтелгән. Налогтан азат ителгән катлаулар “Сказка”га язылмаган. Андыйларга дворяннар, дин әһелләре, отставкадагы солдатлар, солдат хезмәтендәгеләр, драгуннар, дәүләт чиновниклары, 1 нче гильдия купецлар, разночинецлар кергән. Хатын-кызлар, балалар исемлеккә язылганнар, ә налог түләүчеләр исемлегенә (сводный список) кертелмәгәннәр.

1881 елның сентябрь аенда ясак (налог) җыючыларның эшен җиңеләйтү максатыннан авылның планын төзү өчен  Ямбулат авылының “Именной списогы” языла. Ул исемлек авылда йортларның урнашу тәртибендә төзелгән. Исемлек буенча, авылда 91 йорт теркәлгән, ясак түләүче 107 кеше күрсәтелгән. Бу документлар  Республиканың Милли архивында саклана. (Именной список күчермәсе белән бераз соңрак таныша аласыз.)

Алда саналган өч документтан күренгәнчә, авылда халык саны еллар үткән саен арта барган, авыл зурайган.

Документлардан саннар китерүне дәвам итәбез. “Казанская губерния список населенных мѣст по свѣдѣниям 1859 г. Изданъ Центральным статистическим комитетом министерства внутренних дел”. Редактор А.Артемьев. Санкт-Петербург, 1866.  Бу документта авыл турында түбәндәгеләр язылган:

*д. Янбулатова,  казенные крестьяне  при ръ. Сабинкъ. число дворов 67, число жителей 225 (муж), 226 (жен), мечеть 1.*

Халык санын чагыштыру өчен:

Шушы ук чыганакта күрше Сатыш авылы турында болай дип язылган:

*Казанская губерния, уезд Мамадышеский.-стань 1. На Зюринскомъ торговомъ трактъ. По правому сторону этого тракта Бурунча-Сатышево. по ръ. Сабинкъ. число дворовъ 225. 718 (муж), 701 (жен). Мечеть 1. Училище.*

Төрле елларда Юлбат авылында ничә хуҗалык (двор) булганлыгы, күпме кеше яшәгәнлеге турында язып үтик,  күрше-тирә авыллар белән дә чагыштырыйк.

| | 1858 елгы халык санын алу | | | | 1883 елгы подворовый перепись | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Авыллар | Двор | Халык саны | Ир-ат | Хатын-кыз | Двор | Халык саны |
| Ямбулат | 55 | 441 | 222 | 219 | 100 | 528 |
| По речькъ Уръ (Тенеки) | 71 | 558 | 318 | 268 | 119 | 614 |
| Сатышево | 114 | 1398 | 714 | 684 | 279 | 1547 |
| Маметова Пустошь (Байлар Сабасы) | 213 | 1606 | 829 | 777 | 254 | 1491 |

Саннардан күренгәнчә, Тенеки ул вакытта Юлбаттан зуррак булган. 1883 елгы халык санын алу буенча Ямбулатта 100 хуҗалыкта 283 кеше, По речъкъ Уръда 119 хуҗалыкта 328 кеше яшәгән. Димәк, 25 ел эчендә, 1858-1883 еллар аралыгында, Ямбулатта хуҗалыклар саны 25кә, По рчкъ Уръда 48 гә арткан. Ул вакытта Тенекидә хуҗалыклар саны, Юлбат белән чагыштырганда, 19га артык булган. Сатышта хуҗалыклар, Байлар Сабасына караганда, 25кә артык, халык саны да күбрәк булган. Күрәсең, шунлыктан волость Сатыш исеме белән аталган (1924 елдан Саба волосте), кайбер документларда Сатыш районы дип язылган. Шул ук 1883 елгы перепись буенча, Сатыш волостена 14 авыл кергән. Исемнәрен, документта бирелгәнчә, рус телендә китерәбез:

Районъ Сатышевский
Гажинская Пустошъ
По рчъкъ Казнишъ (Кильдебяково)
По рчъкъ Уръ (Тенекей)
Ташла-Илга
Маметова Пустошь
Средние Сабы (Шайтанъ-Ключъ)
Старые Сабы
Ямбулатово
Сатышево
Чапки-Сабы
Юмгалакъ
Чулпычъ
Большой Шинаръ
Новый Шинаръ

*Искәрмә:* Гажинская Пустошь – Сабабаш, Маметова Пустошь – Байлар Сабасы, Ташла-Илга – Мәртен, Новый Шинаръ – Сабай, Ямбулат – Юлбат, Старые Сабы – Туктар авыллары.

Шуны да искәртеп китәргә кирәк, безнең Юлбат авылы төрле елларда дүрт волостька кергән: Елыш, Иске Икшермә, Сатыш, Саба.

## 1883 елгы статистик экспедиция күрсәткечләре буенча авылның социаль-икътисади хәле

1883 елгы халык санын алу вакытында җир исәбе алу, терлек санын исәпләү дә үткәрелгән. Мәгълүматлар 1884 елда басылган "Труды статистической экспедиции" хезмәтендә таблицалар формасында гомумиләштереп бирелгән. Искәртеп үтәбез: перепись вакытында хуҗалыкларның экономик хәлен җентекләп өйрәнү Мамадыш өязеннән бары тик ике районда (документта район дип язылган) гына үткәрелгән: Сатышевский һәм Старо-Юминский районнарында. Алда аталган хезмәттән җир турындагы мәгълүматларны кыскартып китерәбез:

| Авыл-лар | Хуҗа-лыклар (двор) саны | Барлык җир (дисә-тинә) | 1 җанга туры килә (дисәти-нә) | Җирле хуҗалык-лар саны | Җирсез хуҗалык-лар саны | Җирен үзе эшкәр-тә | Бер өлешен арендага бирә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Ямбулат | 100 | 628 | 3 | 98 | 2 | 82 | 4 |
| По ръчкъ Уръ | 119 | 692 | 3 | 114 | 5 | 109 | 44 |

*Искәрмә*: дисәтинә – 1,092 гектарга тигез.

Шул ук перепись буенча, Ямбулатта 100 хуҗалыкка 99 ат, 103 мөгезле эре терлек, 18 колын, 76 кәҗә, 426 сарык малы булган. По ръчкъ Уръда 119 хуҗалыкка 90 ат, 78 мөгезле эре терлек, 10 колын, 35 кәҗә, 324 сарык малы теркәлгән. Сатышта 279 хуҗалыкка 238 ат, 139 мөгезле эре терлек, 22 колын, 129 кәҗә, 842 сарык булган. Маметова Пустошьта 254 хуҗалыкта 225 ат, 185 мөгезле эре терлек, 19 колын, 132 кәҗә, 658 сарык теркәлгән.

Өч һәм аннан күбрәк атлы хуҗалыклар Ямбулатта – 2, По ръчкъ Уръда – 1, Сатышта – 8, Маметова Пустошьта 9 күрсәтелгән. 2 атлылар Ямбулатта 20, По ръчкъ Уръда – 9, Сатышта – 32, Маметова Пустошьта 34 булган. Шул ук вакытта 100 хуҗалыклы Ямбулатта бөтенләй атсызлар – 26, По ръчкъ Уръда – 9, Сатышта – 32, Маметова Пустошьта 34 булган. Крестьянның матди хәле йортында аты булу-булмауга бик нык бәйле булган бу чорда авылларда халыкның тормыш хәлен күзалларга китерелгән мәгълүматлар бераз булса да ярдәм итәр, бәлки. Сыерсыз хуҗалыклар Ямбулатта – 31, По ръчкъ Уръда – 57, Сатышта – 153, Маметова Пустошьта – 104 күрсәтелгән. Бернинди малсыз хуҗалыклар Ямбулатта – 16, По ръчкъ Уръда – 20, Сатышта – 49, Маметова Пустошьта 28 теркәлгән.

Әлеге перепись вакытында крестьяннарның яшәгән йортлары, ихатада (двор) булган хуҗалык корылмалары да бик төгәл исәпкә алынган. Мәсәлән, 100 хуҗалыклы Ямбулат авылында 116 торак йорт (жилыхъ избъ) булган. Таблицадан күренгәнчә, 21 хуҗалыкта (дворда) 2 шәр йорт, ә 5 дворда торак йортлар бөтенләй булмаган (“жилых изб нет” дип язылган). 116 йортның 35е такта түбәле, 81е салам түбәле булган. Искәртеп үтәбез, сүз бары тик торак йортларның түбәләре турында гына бара, башка төрле каралтылар бу саннарга керми.

По ръчкъ Уръда 119 дворда 142 торак йорт. Шуларның 79ы такта, 63е салам түбәле. Сатыш волостена кергән 14 авылдан бары тик Тенекидә генә ике катлы 3 йорт булуы күрсәтелгән, калган авыллардагы йортлар берәр этажлы.

Ничек көн күргән безнең халык, нинди кәсепләре булган? Перепись материалларында бу сорауларга да җавап бар. Сатыш волосте авылларында кайбер һөнәрләрнең аз булуы күзгә ташлана. Мәсәлән, бары тик ике авылда гына (Байлар Сабасы һәм Сатыш) берәр тимерче, ике авылда (Байлар Сабасында 3, Сатышта 2) тегермәнче, бер авылда гына (Юлбатта 2 кеше) пыялачы, ике авылда берәр мичче (Килдебәк һәм Сатыш) булганлыгы теркәлгән. Киңрәк таралган һөнәрләрдән

Ямбулатта 19 көнлекче, 33 тегүче, 4 итекче, 2 пыяла куючы, 2 такта яручы; По ръчкъ Уръда 5 тегүче, 29 көмешче, 34 бакырчы (медники), 1 такта яручы булган. Көтүчеләр, аучылар, тегүчеләр һәр авылда диярлек булган.

Нәрсә белән сәүдә иткән соң Сатыш волосте халкы? Ит белән Байлар Сабасында гына (2 хуҗалык), ат һәм башка терлек белән Байлар Сабасында (2 хуҗалык), Сатышта (1 хуҗалык), Йомгалакта (1 хуҗалык), икмәк белән Килдебәктә (3 хуҗалык), Тенекидә (1 хуҗалык), Мәртендә (1 хуҗалык), металл белән бары тик Байлар Сабасында гына бер хуҗалык шөгыльләнгән. Юлбатта ситсы белән ике хуҗалык, төрле товарлар белән өч хуҗалык сәүдә итүе әйтелгән.

Сатыш волостенда сәүдә турында җентекләбрәк язып китик. Шул ук 1883 елда үткәрелгән перепись материалларыннан күренгәнчә, барлык сәүдә 3 категориягә бүлеп каралган: 1) район эчендә товар алышу; 2) башка җирләргә барып үз товарыңны сату; 3) башка җирдәге продуктны алып кайтып сату.

Беренче категориягә урман белән сәүдә итү кертелгән. Бу эш белән волостьта барлыгы 119 кеше шөгыльләнгән. Бер яки ике аты булган крестьян гына агач сату белән шөгыльләнә алган. Алар үзләре кискән агачны да, атсыз крестьяннарның делянкаларыннан сатып алынган агачны да базарга алып барып сатканнар.

Икенче категориягә кызыл мал белән сәүдә кертелгән. Ситсы сату белән волостьта 11 кеше шөгыльләнгән, шулардан тугызы – иң байлары – ерак җирләрдә сәүдә итә алган: икесе – Петропавловск һәм Кыргыз далаларында, берсе – Златоуст өязендә, берсе – Самара губернасында, берсе – Кама аръягында, дүртесе – Мәкәрҗә, Ирбит, Минзәлә, Мамадыш өязе һ.б. ярминкәләрдә. Бу сәүдәгәрләрнең районга акча кертүе әйтелгән. Сәүдәгәрләрнең үзләре әйтүе буенча, 500-4000 сум доход алулары күрсәтелгән.

Өченче категория – ит белән сату итүчеләр. Алар барлыгы ике. Бу төр сәүдә кыш көне генә барган. Ике сәүдәгәр дә Вятка губернасының Малмыж өязенә көн саен барып 20-30 сумга берәр ат алып кайтып суйганнар һәм Теләче базарына алып барып сатканнар. Итнең бәясе 16-18 сум, тиресе 4 сум булган.

Сатыш волостенда крепостной крестьяннар булмаган, бары тик дәүләт крестьяннары гына булган. Алар һәр дисәтинә җир өчен уртача 1 сум 21 тиен салым түләп торганнар. Түләүләрнең суммасы төрле авылда төрлечә: 83 тиеннән алып 1 сум 62 тиенгә кадәр булган.

Моннан тыш община расходларына акча җыелган. Аның күләме шулай ук һәр дисәтинә җирдән чыгып билгеләнгән. Югарыда аталган документта түбәндәге община расходлары күрсәтелгән:

1) Старостага түләү – елга 10-20 сум. Кайвакытта бу вазифаны чиратлап бушка да башкарганнар.

2) Содержание въезжей квартиры – елга 10-20 сум. Шулай ук бу квартираны тоту чиратлап та башкарылган.

3) Налоглар җыюда эшләү – 15-50 сум.


4) Каравылчыларга түләү – 15-40 сум.

5) Сыер һәм сарык көтүчеләренә бер җәйгә 15-50 сум һәм ашау мир өстеннән. Атларны күп очракта чиратлап көткәннәр.

6) Болардан башка да вак чыгымнар булган, аларны община белән күтәргәннәр. Мәсәлән, күперләрне төзәтеп тору, янгынга каршы көрәш өчен инструментлар алу, иганәчелек.

Иганәчелек буенча акчалар рекрутларны озатуга, ятимнәрне община тәрбиясенә алуга тотылырга мөмкин булган.

## *1881 елда Ямбулат авылындагы хуҗалыкларның урнашу тәртибе (авылның картасын төзү өчен язып алынган именной список)*



Именной списокның беренче бите. 1881 ел

Милли архивта районның кайбер авылларының йортлары урнашу күрсәтелгән карталары да бар. Мондый карталар ясак җыючыларның эшләрен җиңеләйтү өчен төзелгән. Кызганыч, Ямбулат-Юлбатның андый картасы төзелми калган, бәлки, төзелеп тә, югалгандыр. Шунысы билгеле, карта төзү өчен хуҗалыклар урнашу тәртибе язылган исемлек алынган була. Без ул исемлекнең күчермәсен архивтан алып кайттык.

*Искәрмә:* исемлек рус кешесе тарафыннан һәм бик аңлаешсыз почерк белән язылганлыктан, аны авыл кешеләрен, аларның бабаларын белгән кеше генә бераз чамалап укый ала. Бу исемлекне Галиев Наил Тимергали улы укып, язып бирде. Исемлек башта русчага, безнең тарафтан татарчага тәрҗемә ителгәнлектән,

төгәлсезлекләр булырга мөмкин. Кайбер исемнәр русча язылган килеш тә калдырылды. Исемлекне анализлап, ул вакыттагы авылның чиген, алдагы буын бабайларны белергә була, шунлыктан аны тулысынча китерәбез.

| № | Фамилиясе, исеме | Туган елы (булганнарның) |
|---|---|---|
| 1 | Шаһимәрдән Талиев | |
| 2 | Гыйззәтулла Гобәйдуллин | |
| 3 | Хәмидулла Гобәйдуллин | |
| 4 | Вәлиулла Кәримуллин | |
| 5 | Муса Бикташев | |
| 6 | Ярмөхәммәт Бикмөхәммәтов | 1827 |
| 7 | Нурмөхәммәт Бикмөхәммәтов | 1840 |
| 8 | Җәләли Мөхәммәтрәхимов | 1832 |
| 9 | Сиражи Мөхәммәтрәхимов | 1824 |
| 10 | Мостафа Биктимеров | |
| 11 | Йосып Биктимеров | |
| 12 | Гайса Биктимеров | |
| 13 | Гатиятулла Фатхуллин | 1828 |
| 14 | ....... Набитов | |
| 15 | Мәҗит Габитов | |
| 16 | Сәгыйт Габитов | |
| 17 | Шаһиәхмәт Искәндәров | 1811 |
| 18 | Бәдретдин Таҗетдинов | |
| 19 | Баһаветдин Таҗетдинов | |
| 20 | Дәүләтша Бөкминов | |
| 21 | Сафабик Мөхәммәтов | |
| 22 | Ситдыйк Таҗиев | |
| 23 | Фоат Әюпов | |
| 24 | Шәмсетдин Әминов | |
| 25 | ........ | |
| 26 | Вәлиәхмәт Усманов | |
| 27 | Гали Бикташев | 1805 |
| 28 | Вәли Яппаров | |

| | | |
|---|---|---|
| 29 | Галләм Аптушев | |
| 30 | Иркәбай Гобәйдуллин | |
| 31 | Каһир Галиев | |
| 32 | Абдрахман Абдиев | |
| 33 | Әхмәдулла Хәмзин | |
| 34 | Гыйләҗетдин Нәҗмиев | |
| 35 | Хөсәен Бикмөхәммәтов | |
| 36 | Исхак Бикмөхәммәтов | |
| 37 | Насыйбулла Хаиров | |
| 38 | Ярулла Гайфуллин | 1834 |
| 39 | Тимербай Корбангалиев | |
| 40 | Сираҗетдин Бикчәнтәев | 1824 |
| 41 | Йосып Габитов | |
| 42 | Вәлиша Әхтәмов | 1847 |
| 43 | Мөхәммәтша Әхтәмов | 1843 |
| 44 | Төхбәтулла Таҗетдинов | |
| 45 | Гатаулла Ганиәхмәдиев | |
| 46 | Общественный дом | |
| 47 | Ильяс Ишниязов | |
| 48 | Төхбәтулла Садретдинов | |
| 49 | Гайнулла Фәхретдинов | |
| 50 | Фәттах Мөхетдинов | |
| 51 | Сибгатулла Төхбәтуллин | |
| 52 | Мөхетдин Хөснетдинов | |
| 53 | Кәримулла Хисаметдинов | |
| 54 | Гыйльман Шәмсетдинов | |
| 55 | Галимулла Фәхретдинов | |
| 56 | Гариф Гаффаров | |
| 57 | ........ | |
| 58 | Фәрзетдин Сәгъдиев | |
| 59 | Динмөхәммәд Динмөхәммәдов | |

| | | |
|---|---|---|
| 60 | Даут Галиев | |
| 61 | Исмәгыйль Габбасов | |
| 62 | Хәйбулла Аптикиев | |
| 63 | Хасанбик? Мөхәммәдов | |
| 64 | Гайса Усманов | 1843 |
| 65 | Гобәйдулла Фәхретдинов | |
| 66 | Бәшир Таһиров | |
| 67 | Мәхмүди Исмагыйлов | |
| 68 | Әлмөхәммәт Бикмөхәммәтов | |
| 69 | Халик Сәетов | |
| 70 | Абдрахман Мифтахетдинов | |
| 71 | Закир Баһманов | |
| 72 | Җәләли Биганкиев | 1843 |
| 73 | Рәхмәтулла Гайфуллин | |
| 74 | Мөхәммәдияр Бикмөхәммәтов | |
| 75 | Гайфулла Галиев | |
| 76 | Сагыйт Сәетов | |
| 77 | Хәмит Дәүлиев | |
| 78 | Насыйбулла Фәхретдинов | |
| 79 | ........ Таҗиев | |
| 80 | Шафигулла Гайфуллин | |
| 81 | Галиәхмәт Бикмөхәммәтов | |
| 82 | Сәхаби Камилов | |
| 83 | Гыймади Мәхмудов | 1818 |
| 84 | Шакир Баһманов | |
| 85 | Каһарман Галиәкбәров | 1842 |
| 86 | Динмөхәммәт Әхмәтов | 1834 |
| 87 | Баттал Галиев | |
| 88 | Хәмидулла Гобәйдуллин | |
| 89 | Хайбулла Гайфуллин | |

| | | |
|---|---|---|
| 90 | Газинур Галиев | |
| 91 | Сәмигулла Рәхмәтуллин | |
| 92 | Тимербай Сәмигуллин | |
| 93 | Ибәтулла Ваһапов | |
| 94 | Гыйлаҗи Гаффаров | |
| 95 | Ильяс Бикташев | 1843 |
| 96 | Әхтәм Искәндәров | 1807 |
| 97 | Әхмәди Әхтәмов | 1830 |
| 98 | Ибрай Галиев | 1829 |
| 99 | Хәйбулла Биктимеров | 1829 |
| 100 | Динмөхәммәт Бикколов | |
| 101 | Вилдан Ишмөхәммәтов | |
| 102 | Зәйнулла Габидуллин | |
| 103 | Мөтыйгулла Хәйбуллин | |
| 104 | Гайнетдин Сәлимҗанов | 1828 |
| 105 | Галләметдин Мөхәммәтҗанов | 1843 |
| 106 | Кәлимулла Фатхуллин | 1834 |
| 107 | Бигамет Галиев | |

Әлеге исемлектән күренгәнчә, күпчелек крестьяннар өйләнеп гаилә корган улларын үз ихаталарына башка чыгарганнар. Мәсәлән, Забир Бикколовның (1740-1819) биш малае үз янәшәсенә башка чыккан. Аптелман Адылевның (1745-1821) дүрт малае (Биктимер, Биккол, Бикбау, Бикташ); Бикенинның өч малае (Баязит, Рәхмәтулла, Бакир); Бикчуринның өч малае (Нигъмәт, Фатхулла, Сәмигулла). Ике яки өч малае башка чыккан тагын шактый хуҗалыклар бар. 1834 елгы сан алу елыннан артка күчеп (ул елгы исемлектә 53 хуҗалык), бу башка чыккан малайлар әле тумаган 1760-1790 елларга кайтып, авылда булган хуҗалыкларны санап карасак, авыл 15-18 хуҗалыктан гына торган дип уйларга нигез бар.

1850 елда узган перепись (“Ревизская сказка”) буенча авылда 57 хуҗалык теркәлгән. Авыл бу чорда үзәктә оешып утырып, көньяк чите хәзерге (2014 ел) Хафизов Нурмый, Дәүләтшина Рәшидәләр ихаталары тирәсендә була. 1860-1880 елларда авыл Югары очка таба – Тенеки авылы ягына үсә. Өйләнеп башка чыгучылар хуҗалыкны шунда коралар.

1880 елларда авыл көньякка таба үсә башлый. Авыл кырыена Әбдтелмән нәселеннән Гайнетдин һәм Галләметдин (Низаминың әтисе, хәзер бу урында Низамиев Рафаэль яши) башка чыгып йорт коралар. 1880-1910 елларда авыл Сөрән

елгасына кадәр үсә. 1910-1925 елларда елганың теге ягына күчеп утыру башлана. 1920-1930 елларда Нахальный урамы барлыкка килә. (Ул урам турында аерым язылды).

Халык телендә “Аскы урам” дип йөртелә торган, хәзерге Озерная урамы 1926 еллар тирәсендә генә барлыкка килгән дип фаразлана. Ул урамга беренче булып Кәбиров Васыйлның бабасы Әхмәтҗанов Кәбир йорт салган булырга тиеш.

Авыл оешканчы монда яшәгән чирмеш, ар халкы белән, бәлки, кушылу да булгандыр. 1834 елгы “Ревизская сказка”да татар-мөселманнарга хас булмаган Адылев, Аптикиев, Марадымов фамилияләре очрый. Бәлки, русча язылганга шулайдыр.

Галләм бабайның (Зәйнәп апа һәм Гыйлемхан абыйларның әтиләре) 1950 елларда сөйләгәннәрен хәтерләүче кешеләр әйтүенчә, авылда исемнәре “-етдин” гә беткән кешеләр – чирмеш нәселеннән, “-улла” га беткән кешеләр – татар нәселеннән.

Хәзерге вакытта авылда берничә зур нәселне күзәтергә була.

Хәйбулланыкылар – Тау Иле (Тат. Ходящево) авылыннан килгәннәр (Ихсан бабай әйтүе буенча). Ихсанның әтисе Ислам – Хәйбулла малае.

Әбделмәннекеләр – Сәрдәдән килгән нәсел. Батталныкылар, Баһманныкылар, Ишниязныкылар, Бикмөхәммәтнекеләр, Сафаныкылар дип йөртелгән нәселләр бар.

Хәзер югарыда телгә алынган волость, өяз сүзләренә бераз аңлатма биреп китик.

## Административ бүленеш

Төбәкләрнең административ бүленеше ике гасыр дәвамында элеккеге ханнар заманындагыча, берникадәр үзгәрешләр белән, сакланып килгән. Казан ханлыгы руслар басып алганчы төп биш өлкәгә: Арча, Җөри, Алат, Гәреч (Галич) һәм Нугай даругаларына бүленгән. Мондый даругаларга бүленеш 1770 нче елларга кадәр сакланган. “Даруга” сузе борынгы монгол теленнән кергән. Башлангыч мәгънәсе өлкә, төбәк һәм аның идарәчесе дигәнне белдергән бу сүз рус теленә “юл” мәгънәсенләге “дорога” буларак кереп калган. XVIII гасырда “даруга” сүзе русларның “юл” дигәне белән тәңгәлләштереп, татарча документларда һәм башка төр язмаларда “юл” буларак (мәсәлән, Җөри юлының фәлән авылы дип) кулланылган.

XVII гасырда Россиядәге җирле идарә органнары акрынлап үзгәреш кичерә, булачак губерналарның башлангычы рәвешендә өязләр оештырыла. Өяз – йөз дигән сүздән. Өязләр үз эчләрендә даруга, волость һәм станнарга бүленгән. Ләкин бу бүленеш тотрыклы булмаган.

Екатерина IIнең губерналар турында 1775 елгы фәрманы нигезендә Россиядә административ-территориаль бүленеш 1779-1985 елларда яңа рәвештә үзгәртелеп корыла. Императрицаның 1781 елның 28 сентябрь боерыгы буенча Казан губер-

насы һәм шул елларда бүтән губерналар оештырылган. 1781-1983 елларда өязләр арасындагы чикләр билгеләү буенча махсус комиссия эшләгән.

Өязләр үз эчләрендә волостьларга бүленгәннәр. Волостьның башлыгы старшина дип аталган. Волость сүзе – элеккеге төрки телдәге административ-территориаль берәмлекне белдергән "олыс" сузеннән алынган. (Тарихтан билгеле булганча, Алтын Урда чорындагы ханнарның зур территориаль нәсел биләмәләре "олыс" дип аталган. Алтын Урда үзе дә "Җүчи олысы" дип йөртелгән).

1837 елгы административ реформа нигезендә, дәүләт крестьяннары яшәгән авылларда авыл җәмгыяте (общество) гамәлгә кертелгән. Ул исә волость җыенына, ә волость җыены Дәүләт милке палатасына, 1866 елдан земство идарәләренә буйсынган. Авыл җәмгыяте – 1917 елга кадәр Россиядә иң түбән (башлангыч) иҗтимагый-административ берәмлек. Бер авыл җәмгыятенә уртак биләмәләрдән файдаланган берничә авыл яисә бер генә авыл кергән. Авыл җәмгыяте җыеннарында ачык тавыш бирү юлы белән староста, салымнар җыючы, писарь, урман һәм авыл каравылчылары сайланган. 1917 елдан яңача административ берәмлек – Советлар оештырылгач та, элекке авыл җыеннары егерменче еллар ахырына кадәр үз көчен саклап килгән. Авыл җәмгыятьләрен 1927-1929 еллардагы махсус карарлар белән генә авыл Советларына буйсындырганнар.

## 1917 елгы инкыйлабка кадәрге авыл тормышыннан кайбер хатирәләр

Юлбат авылыннан Беренче бөтендөнья сугышында катнашучылардан Нигъмәтҗанов Галимҗан, Якупов Гарифулла билгеле.

Нигъмәтҗанов Галимҗан (Галимҗанов Назыйфның бабасы) Сербия территориясендә яраланган. Аның Мәскәүдә госпитальдә дәваланганда төшкән фотосы сакланган. Галимҗан сугыштан кайткач Юлбатта яшәгән.



Нигъмәтҗанов Галимҗан (уңнан икенче)

Якупов Гарифулла (Сафин Илдарның әнисенең бертуган абыйсы) сугыштан кайтканда юлда тиф авыруы эләктергән. Поездден төшкәч, аны Симет авылы кешесе ат белән китереп куйган. Шул авырудан савыга алмыйча, Гарифулла абый вафат булган.

Авылда төп нәселләр булып Әбделмәннекеләр һәм

Хәйбулланыкылар саналган. Һәр ике нәсел кешеләренең җир башына куя торган тамгалары булган. Әбделмәннекеләрнең җир тамгасы әмдә тамга (авышрак итеп язылган И хәрефенә охшаган), Хәйбулланыкыларның – югары баштан бер җәбе аз гына бөтерелгән сәнәк тамга булган.

Хатын-кызларга җир бирелмәгәнлектән, гаиләдә кыз балалар күп туган очракта тормыш алып бару авыр булган. Мәсәлән, Галимулла бабайның (Галимуллин Рәфкатьнең әтисе) истәлекләренә караганда, ул бала вакытта әтисе 3 имана җире белән 11 җанны туйдырган. Ярым ач, ялангач яшәдек, дип искә алган ул.

Җире аз кешеләр Дәүли дигән байдан урман төпләргә җир алып та караганнар. Бер дисәтинә урман төпләгән кеше шул җиргә 2 ел үзе чәчә, аннары җир – байныкы. Ә төпләгән елында җир 3-4 арбадан ары ашлык бирмәгән.

Авылда телдән-телгә сөйләнеп килгән, җир бүлү белән бәйле тагын бер вакыйга халык хәтерендә саклана. Ихсан бабай берничә кыз туганыннан соң җир бүленгән елда, ләкин җир бүлгәннән соң берничә көн үткәч туган. Билгеле, Ислам абыйның өметләнеп көтеп алган Ихсан исемле малае туу хөрмәтенә җир яңадан бүленмәгән. Шулай итеп, Ихсанның атасы бер имана җире белән 6 җан туйдыруны дәвам иткән. Ихсан үсеп җитеп солдатка алынган, гражданнар сугышында катнашкан. Еллар тынычсызлыгы аркасында 18 ел рәттән җир өләшенми торган. Ихсан гражданнар сугышыннан кайткач кына, Совет законы нигезендә, беренче тапкыр җир алган.

Революция давыллары Юлбат авылына да яңалык, шатлыклы хәбәрләр китерә. Яңа законнарның тормышка ашуы көрәш белән бергә бара. Шиһабетдин Шәрәфиевны, хатын-кызларга да җир бүләргә кирәк, дигәне өчен генә дә кара фикерле кешеләр бик каты кыйныйлар, җир бүлүне тоткарламакчы булалар. Гражданнар сугышыннан кайткан солдатлар үзләренең ни өчен сугышып йөрүләрен, Совет дәүләтенең Җир турындагы декретын халыкка аңлатканнан соң гына җир яңача бүленә.

Без бала вакытларда, уеннан кайтып ашарга утыргач, әвен сугып кайттыгызмы әллә, дип көләләр иде әниләр. Ул вакытта “әвен сугу”ның ничек булганын аңлатучы булмаган, ә без, балалыгыбыз белән, сорауны кирәксенмәгәнбез. Бу китапка материаллар җыйганда без әвен сугу турында истәлекләргә юлыктык. Галимулла (югарыда телгә алынды, Рәфкать абыйның әтисе) һәм Шәмсетдиннең (Сәйфуллин Мансурның әнисе Шәфига ягыннан бабасы) яшүсмер вакытта хәллерәк кешеләргә көнлеккә әвен сугарга йөрүләрен сөйләүче истәлекләр ул. Әвен – сугарга әзерләп көлтәгә бәйләнгән ашлыкны киптерү өчен төзелгән корылма. 300-400 көлтәдән торган бер әвенне сугып, җилгәреп, икенчесен куеп



Якупов Гарифулла

кайтып киткән өчен кеше башына 5 тиен хезмәт хакы түләгәннәр. Бер әвенне 4-5 кеше суга торган булган. Көнгә бер мәртәбә чәй, бер тапкыр аш ашауга ялланганнар. Соңга табарак бер әвенне суккан өчен 10 тиен түли башлаганнар.

## Юлбат авылында колхоз төзелү

1929 елда солы симәнәсен авыл буенча җыеп бер келәткә салалар. Сабадан суыру машинасы китертеп суыралар. 1930 елда солыны кире тараталар.

1930 ел, 29 октябрь. Авыл активы җыелышы үткәрелә. Анда 7 кешенең үз теләге белән колхозга керүе турында карар чыгарыла. Менә алар: Гомәров Гаффар, Дәүләтшин Гани, Мөхәммәтҗанов Һади, Исламов Тимер, Галләмов Низами, Хуҗин Хаҗи, Шәйхетдинов Баһау.

1931 елда колхозга 17 хуҗалык керә, соңрак тагын 14 хуҗалык аларга кушылып, бер бригада төзелә. Бригадир булып 1 сентябрьгә кадәр Дәүләтшин Гани эшли. Ул счетоводлыкка укырга киткәч, бригадир булып Зәйнуллин Гыйззетдин билгеләнә. Колхоз Ворошилов исемен йөртә.

1932 елда колхозда ике бригада була (председатель Галләмов Низами), 70 хуҗалык колхозга керә. 1933-35 елларда бригадалар саны дүрткә җитә (председатель Гомәров Гаффар). Колхозлашу нигездә тәмамлана.

Армиядә хезмәт иткән вакытта Гыйлаҗиев Габделхай һәм Мотыйков Мәҗит колхозга член итеп алуны сорап хат язалар һәм, 1930 елда армиядән кайткач, колхозның актив членнары булып китәләр. Бөтен эш ат көче белән башкарылган. Язгы сабан 1-1,5 айга сузылган. Иң яхшы бер пар ат 2 га җир сөрә алган.

Шул елларда эшләгән бригадирлар:

I бригада (Юлбат) – Гайфуллин Билал

II бригада (Юлбат) – Мөхәммәтҗанов Мәүлетҗан

III бригада (Тенеки) – Баһавиев Сәүбән

IV бригада (Йосыф-Алан) – Габделхаев Самат.

***Татарстан Милли архивында сакланган колхозның беренче отчеты күчермәсенең татарчага тәрҗемәсен тәкъдим итәбез.***

**1931 елның 31 декабренә кадәр колхозның еллык отчеты. (Юлбат авылы)**

Исеме: Ворошилов

Колхоз оешкан: 7 апрель, 1931 ел.

Машина-трактор станциясе килешү нигезендә хезмәт күрсәтә.

Колхозда нинди товарлыклы ферма оештырылган – үрдәк.

Колхозның составы:

1) Колхоз гаиләләре белән кергән кешеләр һәм ялгызаклардан (одиночки) тора. 1932 елның 1 январена – 68.

2) 1932 елның 1 январена колхозчылар саны: 242.

Шулардан 76сы – ирләр, 76сы – хатын-кызлар, 12 яшьтән өлкән үсмерләр – 14.

Барлык эшкә яраклы кеше – 166.

1931 елда эшләнгән (человек\месяц) – 23,18.

1932 ел башына кадрлар белән тәэмин ителеш:

Кадрлар – 18, трактористлар – 4, работников учета – 1, детсад – 1.

Җир эшкәртү:

Иртә пар сөрелгән – 10 га;

Элекке пар җирләренә 1932 ел уңышы өчен чәчелгән уҗым – 5 га;

Тирес белән ашланган – 5 га;

Известьланган – 7 га;

Кар тотылган: 38 (план), 22 (фактта),

Барысы – 65 (план), 42 (фактта).

1932 елның 1 январена җирдән файдалану (га):

Сөрү җирләре – 47 га;

Печәнлек – 5,5 га;

Барлык җир – 52,5 га.

Терлекчелек.

1931 ел дәвамында булган терлек саны:

4 яшьтән өлкән булган атлар – 41

2-4 яшьлек атлар – 2

Суелган – 2

Барлык атлар – 43

Шул исәптән 2 яшь һәм аннан өлкәнрәк – 41

1932 елның 1 январена күмәкләштерелгән терлек:

4 яшьтән өлкәнрәк атлар – 39

2-4 яшьлек атлар – 2

Суелган – 2

Барлык ат саны – 41

Шул исәптән эшкә яраклы 2 яшьлек һәм аннан өлкәнрәк – 35

Үгезләр (эшләмәүче) – 1

Товарлыклы-кошчылык фермасы

Оештыру вакыты: 1931 елның 17 октябре,

Үрдәк – 255 (1931 ел, ноябрь)

323 (1932 ел, 1 январь)

1932 елның 1 январена инвентарь:

Сука: бер төрәнле – 2; ике һәм аннан күп – 14; ургыч (жатки самосброски) лобогрейки – 1; ат тырмалары (конные грабли) – 38; молотилка с конным приводом – 1; зерноочистители: сортировка – 1, веялки – 12; сепараторы – 3.

1932 елның 1 январена төзелешләр:

Ат конюшние – 2 (41 атлык)

Кош-корт өчен торак – 2 (560 башка)


№ 15

SSSR ÇEXK tarafnnan raslanьp, SSSR gosplanьp blən kilşterlde.
Согласовано с НКЗ СССР и утверждено Госпланом СССР.

Kolxoznьŋ jllьq otcotь
ГОДОВОЙ ОТЧЕТ КОЛХОЗА

1931 jlnьŋ с 1/I-31 dan 31/XII-31 ilga dən 1931 jlnьn 31 dekəbrenə qadər.
1931 года по 31 декабря 1931 года.

Kolxoznьŋ isme
1. Наименование колхоза Varagilof (?)

Ustaf formasь (kommuna, a.-x. artele, cirne ərgələp eşləy Tovarişst.) (szarqa)
2. Уставная форма (коммуна, с.-х. артель, т-во СОЗ) (подчеркнуть)

Adresь: əlkə (kraj) rajon
3. Адрес: область (край) Yaba район

a. sovetь aul
с. совет julbat селение

Kolxoz qaican ojştьrldь
4. Когда колхоз организовался 7/IV-31 ilda

Maşina-traktor stansasь tarafnnan kolxozqa dogovor təzy tərtibndə xzmət kyrsəteləwe (itelə, juq) (szarqa)
5. Обслуживается ли колхоз в порядке договора машинно-тракторной станцией (да, нет) (подчеркнуть)

Kolxoz sofxozdan proizvodstvo jardəme blən fajdalandьmь (fajdal., juq) (szarqa)
6. Пользовался ли колхоз производственной помощью совхоза (да, нет) (подчеркнуть)

Kolxozda nindi tovarlьq fermalar ojştьrldь
7. Какие товарные фермы организованы в колхозе: 1) ytelək

2) 3)

| | SORAULAR / ВОПРОСЫ | | | SORAULAR / ВОПРОСЫ | | ÇƏYAPLAR / ОТВЕТЫ |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 8 | На 1/I 1931 г. / 1931 j. 1/I-na | Kolxozda bulqan xucalqlar (semja-lələr, jalqzlar) / В колхозе состоит хозяйств (семей и одиночек) — Kolxoznьŋ sostafь / Состав колхоза | Xzmətkə jaraqlьlarnьŋ 1931 г. … / Число человеко-дней … | Qrcьlьq eşlərndə / В полеводстве | 24 | 7074 |
| 9 | На 1/I 1932 г. / 1932 j. 1/I-na | | | Bolncьlьq eşlərndə / В луговодстве | 25 | - |
| 10 | Kolxozda torucьlarn. 1932 j. 1/I qa bulqan qomumi sanь / Общая численность населения колхоза на 1/I 1932 г. | | | Baqcacьlьq həm vinogratlьq eşl. / В садоводстве и виноградарстве | 26 | - |
| 11 | Irlər / Мужчин | 16 jəştən olьraq zurlar / Взрослых старше 16 л. — Xzmətkə jaraqlьlarnьŋ 1932 j. 1/I sanь / Число трудоспособных на 1/I 1932 г. | | Xəjvan asrauc eşl. / В животноводстве | 27 | - |
| 12 | Xat.-qzlar / Женщин | | | Remont mast. həm jard. pretpr. eşl. / В ремонтных мастерских и подсобных предприятиях | 28 | 118 |
| 13 | 12 jəştən olьraq jəş ysmrlər / Подростков старше 12 лет | | | Təzy eşlərndə / На строительных работах | 29 | - |
| 14 | Eşkə jaraqlьlarnьŋ barlьqь / Всего трудоспособных (гр. 11+12+13 gr.) | | | Kolxozn. adm.-xuç. eşl. / На администрат.-хозяйств. работах колхоза | 30 | - |
| 15 | 1931 jlda kolxozda bulqan barlьq eşkə jaraqlьlarnьŋ kşe-ajlarьnьŋ sanь / Число человеко-месяцев пребывания всех трудоспособных в колхозе в течение 1931 г. | Xzmət zapasь həm … | | Başqa eşlərdə / На прочих работах | 31 | 2552 |
| 16 | 1932 j. 1/I cittə eşləyce kolxozcьlarnьŋ sanь / Число колхозн., находящихся … | Citt… / Отх… | | Kolxozda cşləgən ecen isəplengən beten xzmət kennər … | 32 | 31… |

170

Ворошилов исемендәге колхозның (Юлбат авылы) иң беренче отчетының титул бите (1931 ел)

Мәктәп һәм клуб – 2 (110 урынлы)
1931 ел.
Бәрәңге – 2 га, тулай җыем – 80;
Киндер (конопля) 1 га;
Җитен (лен) 2 га.
1932 ел уңышы өчен уҗым чәчелде:
Дөге – 136,43 га;
Бодай – 23.
Арпа – 12.
1931 ел.
Бал – 31 кг. Дәүләткә сатылган 54,25 сумлык
Балавыз – 3 кг, 4 сум 20 тиен.
1931 елга кергән доход (сумнарда):
Кырчылыктан – 647,35;
Умартачылыктан – 58,45
Авыл хуҗалыгының башка тармакларыннан – 84,50
Һәм башкалардан – …..
Барлык доход – 1328,73.
1931 елда доход бүленеше:
Авыл хуҗалыгы налогын түләү өчен – 33,45;
Страхование – 138,43
Кредитка – 300
Неделимый фонд – 1420
Пай взнослары – 4243
Вступительных взносов – 1125
Отчет төзелде: 28-29 март, 1932 ел
Гомуми җыелышта расланды: 6 апрель, 1932 ел
Райфога җибәрелде: 8 апрель, 1932 ел

*Искәрмә:* Татарстан Милли архивы материалларыннан күренгәнчә, Ворошилов исемендәге колхозның оешу вакыты 1931 елның 7 апреле. Мөгаен, әлеге отчет беренчеседер, чөнки ул 1931 ел нәтиҗәләре буенча ясалган. Отчет рус телендә төзелгән, шунлыктан кайбер сүзләр русча кертелде, тәрҗемә вакытында отчетның стиле, кабатланган саннар үзгәртелмәде.

**1934 елның 1 декабренә колхозга керүчеләр саны:**

Юлбат – 141 гаилә
Тенеки – 123 гаилә
Йосыф-Алан – 48 гаилә

**1936 елгы колхоз отчеты күчермәләре**

Ворошилов исемендәге колхозда (Юлбат авылы) 1936 елда чәчүлек мәйданы, уңыш алу һәм аны бүлү

| | Мәйданы (гектарларда) | Уңыш (центнерларда) | Тулай җыем (центнерларда) |
|---|---|---|---|
| Арыш | 288 | 4,74 | 1367 |
| Бодай | 85 | 0,97 | 83 |
| Арпа | 40 | 1,07 | 43 |
| Солы | 185 | 3,15 | 583 |
| Карабодай | 20 | – | – |
| Вика | 20 | 1,76 | 35,18 |
| Борчак | 70 | 1,48 | 100 |
| Җитен | 33 | | |
| Киндер | 3 | | |
| | 744 | 3,12 | 2212 |

Дәүләткә сату – 1158 ц
Симәнәгә – 540 ц
МТСка натуралата түләү – 124 ц
Фуражга – 189 ц
Колхозчыларга хезмәт көненә – 162 ц

Ворошилов исемендәге колхозның (Юлбат) 1934 елга производство планыннан:

Барлык чәчүлек мәйданы – 1206 га
Урып-җыюны тәгалләргә – 18 көндә
Язгы чәчүгә хәзерләнергә – 15 февральгә кадәр

| Эш кораллары | Ремонтларга, тәртипкә китерергә | Сатып алырга |
|---|---|---|
| Сука 1 төрәнле | 10 данә | – |
| Сука 2 төрәнле | 42 данә | – |
| Ат тырмасы | 25 данә | – |
| Ат чәчкече | 8 данә | 3 данә |
| Культиватор | 1 данә | 2 данә |
| Лобогрейка | 5 данә | 1 данә |
| Молотилка | 3 данә | – |

**Колхозчыларны эшкә бүлү:**

| | Ирләр | Хатын-кызлар | Яшүсмерләр |
|---|---|---|---|
| 1 бригада | 20 | 40 | 7 |
| 2 бригада | 16 | 34 | 14 |
| 3 бригада | 19 | 42 | 12 |
| 4 бригада | 20 | 29 | 15 |
| 5 бригада | 18 | 31 | 8 |
| 6 бригада | 15 | 33 | 12 |
| 7 (терлекчелек) | 15 | – | – |
| 8 (яшелчә) | – | 10 | – |

Кадрлар хәзерләргә:
Бригадир – 3
Тракторист – 2
Хисапчы – 2
Кошчы – 1
Сөтче – 1
Куян карауч ы – 2.

## “Нахальный” урамы

Совет власте елларында авылда йорт салу өчен урын бирүне колхозчыларның гомуми җыелышы хәл иткән, чөнки авылдагы җирләр колхозлар карамагына мәңгелеккә беркетелгән булган.

1934-1935 елларда йорт салып башка чыгасы кешеләрнең гаризаларын колхоз идарәсе карый, ләкин яшьләр гомуми җыелыш карарына кадәр үк йорт төзү эшен башлыйлар. Шуның өчен урамга  халык  “Нахальный” дигән исем бирә. Гомуми җыелыш карарын көтмичә, кыюланып эш башлауга да халык телендә аңлатма бар: йорт урыны кирәк кешеләрнең күбесе идарә членнары була.

Авылның чиге бу елларга кадәр Сөрән елгасына кадәр генә булып, әлеге йортлар өчен алынган урыннар чәчүлек җирләр – киндер басуы булган.

Ул вакытта Гаффар колхоз председателе була. Йорт урынын жирәбә тәртибендә бүләләр. Иң беренче жирәбә Насый абыйларга (хәзер Кадыйров Барый яши), аннан соң – Гаффарга  (хәзер Рәфкыя апа яши), аннан соң кладовщик Һадига чыга. (Һади – Мөхәммәтҗанов Фәритнең әтисе Мәүлетҗанның абыйсы, хәзер Габделхаева Нажия апалар урыны).  Агроном-ревком Тимерхуҗа Ислам улына  (Мөдәррис абыйның әтисе) аннан соңгы жирәбә чыга. (Хәзер ул урында Мөдәррис абыйның улы Марат гаиләсе яши.) Чираттагы жирәбә авыл советы рәисе булып эшләүче Ганигә чыга (Ганиева Нуриянең әтисе). Тагын менә кемнәр

җир урынлы булалар: Хуҗин Фәтхри (Хуҗин Азатның әтисе), Фазлый дигән кеше (Фәтхриев Рухылбаян урыны), Шәрип (хәзер Фәтхриев Рөстәм урыны), Сабирҗан Биктаһиров (хәзерге Фәтхриев Илнар урыны), Билал (Вафи абыйлар урыны), Сафин Әхәт (Нурия апаның әтисе).

Өстәге якта: беренче Фәесхан Мөхәммәтҗанов (Вафи абыйның әтисе, хәзер ул урында Сөрән кырыендагы юл), Нәҗип Мотыйгы (Йофар абыйлар урыны), Сәләхетдинов Гыйззетдин, 1899 елгы (хәзерге Гыйззетдинов Нуретдин урыны), Насыйр (хәзер Билалов Тәлгать урыны), Сафин Хәй (Насый бабайның әтисе, Халикова Нурия урыны). Барый Рәхимов дигән кеше дә урын алган, ләкин башка чыкмаган. Бу мәгълүматлар 1935 елгы Гыйззетдинов Нуретдин хәтерләве буенча 2012 елда язып алынды. Үземнең хәтерләвем буенча, 1980 еллар башына кадәр урамның өске ягында Нурия ападан соң калган җирләрдә йортлар юк иде.

Бүгенге көндә Нахальный – ике яклы, төзек, матур урам. Узган гасырның туксанынчы елларында анда бик күп яшь гаиләләр башка чыгып, үз куышларын булдырдылар. Алар барысы да уңган-булган кешеләр, төзек, матур йортларда үзара тату, бердәм гомер кичерәләр. (*И.С.*)

## 1940, 1941, 1942 елларны эченә алган хуҗалык кенәгәсенә күзәтү

Юлбат авылының сугыш алды, сугышның беренче елларындагы тормышын тулырак күз алдына китерү өчен, 1936 елдан алып Юлбат җирле үзидарә архивында сакланган хуҗалык кенәгәләренә мөрәҗәгать иттек. Без 1940, 1941, 1942 елларны эченә алган хуҗалык кенәгәсен анализладык. Юлбат авылында ул елларда 171 хуҗалык булган. Кызыксынучылар булса, кенәгәнең күчермәсен кушымтада тәкъдим итәбез. Аның белән танышкач, ул чор кешеләренең туган елларын, тормыш-көнкүрешен белергә була. 1940-1942 елгы кенәгә буенча хәзер бу урында кемнәр яшәвен, ул гаиләдән сугышта һәлак булганнарның исемен күрсәткән тагын бер графа куйдык. Бөек Ватан сугышы алдыннан һәм сугыш башлангач халыкның күпме терлек тотуын күрсәткән таблицаны китереп үтәбез. 171 хуҗалыклы авылда терлек саны түбәндәгечә булган:

| Еллар | Сыер саны | Сарык | Кәҗә |
|---|---|---|---|
| 1940 | 83 | 238 | 44 |
| 1941 | 38 | 194 | 91 |
| 1942 | 35 | 133 | 71 |

Умарта тотучы хуҗалыклар шушы еллар эчендә 22. Бу шөгыль Юлбат авылында бүген дә киң таралган. Күзәтүләрдән күренгәнчә, кырыгынчы елларда умарта тоткан кешеләрнең нәсел дәвамчыларының кайберләре бу һөнәрне үз иткән.

| № | Фамилиясе, исеме | Хәзер бу урында кем яши | Ничә баш умартасы булган | |
|---|---|---|---|---|
| | | | баганалы | рамлы |
| 1 | Галләмов Низамый | Низамиев Рафаэль | 1 | 1 |
| 2 | Гарипов Закир | “Зиннәт” кибете | 1 | 1 |
| 3 | Шәйхетдинов Баһау | Баһавова Әминә | 1 | 1 |
| 4 | Сәхапов Ногман | Буш тора, Хаҗиев Зөфәр бакчасы | 1 | |
| 5 | Рәхимуллин Гатау | Рәхимуллин Сәйфулла | 1 | |
| 6 | Нигъмәтҗанов Галимҗан | Галимҗанов Вакыйф | | 2 |
| 7 | Гыйниятов Нурулла | Фазлыева Гөлчирә | 1 | |
| 8 | Нуриев Хаҗиәхмәт | Хаҗиев Илһам | 1 | |
| 9 | Сафин Хәй | Хәсәнов Равил | | 2 |
| 10 | Хәбибрахманова Хәзинә | | 3 | |
| 11 | Вәлиев Галиәхмәт | Галиев Шамил | | 1 |
| 12 | Шәймәрдәнова Маһи | | 1 | |
| 13 | Вәлишин Барый | Шәмсетдинова Мәгефия | 1 | |
| 14 | Һадиев Барый | | | 2 |
| 15 | Гәрәев Вәли | Вәлиев Илназ | 1 | 2 |
| 16 | Баһавиев Зыятдин | Зыятдинов Каюм | 1 | 7 |
| 17 | Гарипов Фатих | Фатыйхов Вазыйх | | 1 |
| 18 | Сафин Насыйбулла | Кадыйров Габделбарый | 1 | |
| 19 | Исламов Тимер | Исламов Марат | 1 | |
| 20 | Сафин Әхәт | Рәхмәтуллин Сәет | 3 | |
| 21 | Сафин Муса | Мөбәрәкҗанов Рөстәм | 1 | 2 |
| 22 | Галләмова Тайфә | Низамиев Рамил | 1 | 1 |
| Барлыгы: | | | 21 | 23 |

Хуҗалык кенәгәсендә 24 мунча теркәлгән. Төзелү еллары буенча карасаң, 1890 елда – 1, 1895 елда – 1, 1900 елда – 1, 1907 елда 4 мунча төзелгән. 1918 елда – 2, 1921-25 елларда – 7, 1927 елда – 1, 1930 елда – 2, 1934 елда – 1, 1936 елда – 1, 1937 елда – 1. Соңгы мунча 1940 елда төзелгән. Хуҗалык кенәгәсенә таянып, 1900 елга кадәр авылда 2 генә мунча булган, дип уйларга нигез бар. Кемнәрнеке булган соң алар? 1890 елда төзелгәне – Кәлимуллин Төхбәт (Төхбәтуллин Салихның бабасы), 1895 елгысы – Хуҗин Хаҗи (Хаҗиев Айратның бабасы) мунчалары.



в. Шерсти:

а) овечьей полугрубой по норме 1,300 граммов

10% надбавка колхозникам 0,130 граммов

(На основании ст. 4 постановления Совета Министров СССР и ЦК ВКП(б) от 18. IV-1949 г. и постановления Совета Министров СССР № 1945 от 11. VI-1951 г. „п. 10").

Предоставлена скидка ——— % за наличие ——— тонкорунных и полугрубошерстных овец 5.720 граммов

Подлежит сдаче овечьей полугрубой ——— граммов

б) козьей по норме . . . 0200 граммов

10% надбавка колхозникам 0020 граммов

Подлежит сдаче козьей шерсти . . . ——— граммов

в) верблюжьей . . . . . . . ——— граммов

Всего подлежит сдаче шерсти 5,940 граммов

Шерсть должна быть сдана на Сабинскому пункт Заготживсырье

до 15 июля 3560 грамм, до 15 ноября 2380 грамм.

За невыполнение обязательства в указанные сроки Вы несете установленную законом ответственность.

20 января 1952 г.

Районный Уполномоченный Министерства заготовок СССР ——— подпись

М. П. Агент по госпоставкам сельскохозяйственных продуктов ——— подпись

Жалобы на неправильное привлечение к обязательным поставкам подаются районному уполномоченному Министерства заготовок СССР в 10-дневный срок со дня вручения обязательства.

Решение райуполномоченного Министерства заготовок СССР может быть обжаловано в Райисполком в 10-дневный срок со дня вручения решения.

Райисполком, если находит жалобу основательной, свое решение вносит на утверждение уполномоченного Министерства заготовок СССР в области, крае и республике (не имеющей областного деления), решение которого является окончательным.

Полтава, обл. тип. № 6376

Серия Т. С. № 3353.

**ОБЯЗАТЕЛЬСТВО**

**на поставку государству в 1952 году мяса, молока, брынзы-сыра, яиц, шерсти и кожевенного сырья**

Гр. Закирожанова (фамилия)

Хосниҗамал. (имя и отчество)

Колхозник, рабочий, служащий, единоличник (нужное подчеркнуть)

Колхоз им. Ворошилов

Села Тулбат

Сельсовета Тулбат

Района Сабинский

Обл. (кр.), респуб. ТАССР.

На основании постановлений Правительства Вы обязаны сдать государству в 1952 году по государственным заготовительным ценам:

Статиздат, 2аб, 43|86|50Т|400 IX-51 г., т. 12.000.000

Ворошилов исем. колхоз исеме наименование колхоза

№ 26 керем ордерына квитанция

Квит. к приходн. ордеру № 3/ VII 1954 ел г. число, ай, число, м-ц

Принято от Жамилов З. ———

на базарга ает бирү ———

за бугаев оеи

уп биш сум

язу белән суммасы—сум сумма руб. прописью

(15 сум руб. 2 т. к.)

кабул ителде

Н. У. М. П. Казначей ———

Налог кәгазе

# Юлбат авыл җирлеге Советының 2013 елда эшләгән эшләре турында отчеты



Юлбат авыл җирлеге башлыгы
Шәмсиев Талип Рәшит улы

*(Халыкның тормыш-көнкүрешендәге үзгәрешләрне киләчәк буыннарга чагыштырып карау өчен отчет текстын китереп үтәбез)*

Хөрмәтле авылдашлар! Яңа 2014 елга аяк бастык.

Безнең җирлеккә дүрт авыл керә: Юлбат, Тенеки, Йосыф-Алан, Калатау авыллары. Барлыгы 284 хуҗалыкта 791 кеше яши.

*Схема*

**Җирлектәге демографик күрсәткеч**

| | Хуҗалык | | Халык саны | |
|---|---|---|---|---|
| | 2012 | 2013 | 2012 | 2013 |
| Юлбат | 156 | 157 | 464 | 461 |
| Тенеки | 55 | 55 | 175 | 177 |
| Йосыф-Алан | 43 | 43 | 85 | 76 |
| Калатау | 29 | 29 | 73 | 77 |
| Барысы | 283 | 284 | 797 | 791 |

**Авыл җирлеге биләмәсендә**

| | 2012 | 2013 |
|---|---|---|
| Туу | 8 | 15 |
| Үлү | 12 | 8 |
| Язылышу | 5 | 10 |
| Аерылышу | 1 | – |
| Авыл җирлегенә килүчеләр саны | 10 | 10 |
| Авыл җирлегеннән китүчеләр саны | 20 | 23 |

Җирлек үзенең эшен еллык төзелгән эш планы буенча Устав нигезендә алып барды. Ел дәвамында җирлеккә 27 кеше телдән, 22 язмача мөрәҗәгать итте. Һәр мөрәҗәгать вакытында каралып уңай хәл ителде. 528 кешегә төрле мәсьәләләр

буенча белешмәләр язып бирелде. Биләмәдә 190 пенсионер, 5 инвалид бала, шулай ук гомуми авыру буенча 66 инвалид яши, тыл ветераннары – 30, студентлар – 41.

2013 елда 10 кеше тернәкләндерү үзәгендә ял итеп кайтты. Ялгыз яшәүчеләргә караучылар билгеләнде.

Авыл җирлеге биләмәсендә бер урта мәктәп балаларга белем-тәрбия бирү өстендә эшли. Йосыф-Алан һәм Тенеки авылы балалары урта мәктәпкә техника белән йөриләр. 2013 елда мәктәпне 6 укучы тәмамлады, бердәм дәүләт имтиханнарын уңышлы тапшырып, барысы да аттестатлар алдылар. 6 укучының 5се югары, 1 се махсус урта уку йортларына укырга керде. Мәктәптә быелгы уку елында 70 бала белем һәм тәрбия ала. Өлгермәүче укучылар юк. Сыйфат – 51%, өлгереш – 100%.

Барлык фәннәрне дә тиешле белеме булган укытучылар укыта, программа үтәлә. Укучыларның белем сыйфатын һәм фикерләү сәләтен үстерү максатыннан район һәм республика күләмендә үткәрелгән чараларда актив катнашалар.

Мәктәптә 8 түгәрәк эшли.

1. Хоккей
2. Техник иҗат
3. Драма
4. Вокал
5. Квиллинг
6. Уен кораллары ансамбле
7. Шахмат
8. Хореография

Республика, район олимпиадаларында катнашып сертификатлар, дипломнар алабыз. Район фән олимпиадасында 7 укучы призлы урынга ия булды.

Бөтендөнья яшьләр уеннарының төп символы – Универсиада уты 28 июнь көнне Саба урамы буенча үтте. Спортта зур уңышларга ирешкән Кәримова Гүзәл Сабада уенның ут касәсен кабызу өчен факел белән Саба урамы буенча үтте.

Юлбат урта мәктәбе ел әйләнә 58927 куб.м. газ, 38800 кВт электр энергиясе тоткан, 1 кв.м. га 35,18 куб.м. газ, 1 кв.м. 23,16 кВт электр энергиясе туры килә. Бер баланы укыту – 169000 сум. Мәктәп кирәкле инвентарьлар белән тәэмин ителгән.

Йосыф-Алан башлангыч мәктәбендә балалар саны ким булу сәбәпле, мәктәп балалар бакчасы итеп үзгәртелде. Бүгенге көндә балалар бакчасына 6 бала йөри. Ел әйләнә 42044 кВт. электр энергиясе яккан. 1 квадрат метрга 233,5 кВт электр энергиясе туры килә. Бер баланы тоту чыгымы 49136 сум. Биләмәдә шулай ук “Ромашка” балалар бакчасы эшли. Бүгенге көндә 30 бала тәрбияләнә. Бер баланы тоту чыгымы 70378 сум. Балалар бакчасында бер баланы ай буена тукландыру кечкенәләр өчен – 96,24 сум, зурлар өчен – 83,60 сум. Балалар бакчасында ел буенча 6898 бала йөрде. Уртача йөреш – 24 бала.

Авыл җирлеге биләмәсендә бер китапханә, бер мәдәният йорты, ике клуб халыкка хезмәт күрсәтә. Һәр мәдәният йортында тәҗрибәле, үз эшләрен яратучы кадрлар эшли. Юлбат китапханәсе дүрт авылга хезмәт күрсәтә. Һәр елны Юлбат авыл хуҗалыгы предприятиесе һәм шәхси эшмәкәрләр “Зиннәт”, “Кадыйрова” кибетләре газета-журналларга язылуда ярдәм итеп киләләр. Халыкның 74 % ы китап укый, ягъни 590 кеше китапханәгә йөри дигән сүз. Китап фонды 9162 данә. Халыкны китапханәгә тарту йөзеннән төрле чаралар үткәрелә. Иң күп китап укучы, иң күп китап укучы гаилә һәр елны яңа ел кичәсендә истәлекле бүләк белән бүләкләнә. Өлкәннәргә өйгә барып хезмәт күрсәтелә. Иске китаплар вакытында чыгарылып барыла.

Мәдәният йортында бер генә бәйрәм дә чарасыз үтми. Солдат озату, портрет кичәләр, “Мөселман егете” бәйгеләре зур оешканлык белән үтә. Терлекчеләр белән очрашулар һәрдаим концерт программалары белән үткәрелә. Районда үткәрелгән чараларда да бик теләп катнашалар. Юлбат мәдәният йорты, Йосыф-Алан, Тенеки авыллары клубларында эшләү өчен бөтен мөмкинлекләр бар.

*Схема*

**Электр энергиясе тотылышы**

| | | Ничә кВт | 1 кв. метрга | Тотылган сумма |
|---|---|---|---|---|
| Юлбат СДК | 2012 | 4718 | 9,36 | 15490,19 |
| | 2013 | 4301 | 8,53(-417) | 15486,45 |
| Тенеки клубы | 2012 | 16670 | 133,3 | 52750,68 |
| | 2013 | 16830 | 134,64(+160) | 60728,10 |
| Йосыф-Алан клубы | 2012 | 18911 | 147,3 | 60108,48 |
| | 2013 | 21133 | 165,1(+2222) | 76221,34 |
| Юлбат мәктәбе | 2012 | 38080 | 22,73 | 123341,74 |
| | 2013 | 38800 | 23,16(+720) | 143579,89 |
| Йосыф-Алан мәктәбе | 2012 | 40524 | 225,2 | 130530,32 |
| | 2013 | 42044 | 233,5(+1520) | 153144,64 |

**Газ тотылышы**

| | | Ничә куб.м. | 1 кв. метрга | Тотылган сумма |
|---|---|---|---|---|
| Юлбат СДК | 2012 | 23777 | 47,17 | 109117,09 |
| | 2013 | 24227 | 48,06(+450) | 126939,29 |
| Юлбат урта мәктәбе | 2012 | 68243 | 40,74(-8287) | 313284,28 |
| | 2013 | 58927 | 35,18(-9316) | 309762,42 |

Юлбат авыл җирлеге биләмәсендә ике медпункт халыкка медицина хезмәте күрсәтә.

Юлбат фельдшер-акушерлык пункты Юлбат, Тенеки авылларындагы 597 кешегә хезмәт күрсәтә. 2013 елда 2333 кешегә амбулатор ярдәм, 507 кешегә өйдә ярдәм күрсәтелде, 1739 процедура үткәрелде.

Участок терапевты тарафыннан район үзәк шифаханәсендә генә түгел, үзебезнең фельдшер-акушерлык пунктында да авыруларны кабул итү оештырыла.

Юлбат медпункты ел әйләнә 481 кВт энергия тоткан.

Йосыф-Алан медпункты ике авылга: Й.-Алан, Калатау авылларына хезмәт күрсәтә. Барлыгы 150 кешегә. 2013 елда 1783 кешегә амбулатор ярдәм, 193 кешегә өйдә ярдәм күрсәтелде, 1177 процедура үткәрелде.

Йосыф-Алан медпункты ел әйләнә 8750 кВт энергия тоткан.

Җирлектә бер почта бүлекчәсе эшли. Ул 5 авылга: Юлбат, Тенеки, Йосыф-Алан, Калатау, Урта Саба авылларына – почта хезмәте күрсәтә. Өч почтальон, көннең нинди булуына карамастан, халыкка вакытында матбугатны җиткереп торалар. Аларның эшеннән халык бик канәгать. Еллык газета-журналларга язылу планы 111% ка үтәлде. Бүгенгесе көндә 160 хуҗалыкка телефон кергән. Юлбат авыл җирлеге буенча 29 хуҗалык телефон кертү өчен чиратта тора (Юлбат – 15, Тенеки – 5, Йосыф-Алан – 7, Калатау – 2).

Биләмәдә 5 кибет халыкка сәүдә хезмәте күрсәтә, 2се – райпо, 3се – эшмәкәр кибетләре. Кибетләрнең барысында да халыкка көндәлек куллану товарлары бар, кирәк әйберләрне заявкалар белән дә алып кайталар.

Җирлектәге шәхси хуҗалыкларда төзелеш эше елдан-ел киңрәк колач ала. Шулай ук абзар-кура, мал, авыл хуҗалыгы техникасы алу өчен бирелә торган кредитлардан шактый хуҗалыклар файдаланды. 2013 елда 28 хуҗалык бу кредиттан файдаланды. Җирлектә халык төп терлекчелек, кош-корт асрау белән шөгыльләнә. Үзләреннән арткан терлекчелек продуктларын сату мөмкинлеге дә бар.

2012 елда мөгезле эре терлек 313 баш булса, 2013 елда 270 баш булды, ягъни 43кә ким, сыерлар 144 булып, 2013 елда 129 булды, ягъни 15кә ким. 2013 елда хуҗалыклардан 352353 кг сөт сатылып 4932942 сум акча керде.(уртача 14 сумнан).

*Схема*

**Хуҗалыкта мал саны**

| | 2012 | | 2013 | |
|---|---|---|---|---|
| | Мөгезле эре терлек | сарык | Мөгезле эре терлек | сарык |
| Юлбат | 145 | 75 | 125 | 89 |
| Тенеки | 92 | 78 | 79 | 74 |
| Калатау | 34 | 140 | 26 | 148 |
| Й-Алан | 42 | 93 | 40 | 92 |
| Барысы | 313 | 386 | 270 | 403 |

Юлбат авыл хуҗалыгы предприятиесе хуҗалыкта эшләүчеләрне печән, икмәк белән тәэмин итте. Пай җирләре хисабына халыкка 233000 сумлык салам, 303000 сумлык бодай, 273000 сумлык катнаш азык бирелде. Шулай ук хөкүмәт тарафыннан 1 сыерга 2000 сумнан акча бирелде (129х2000=258000 сум).

2013 елда Юлбат авыл җирлеге буенча урамнарны кардан ачу, кырдыру өчен Саба МППга 14823 сум 34 тиен, ООО "Транссервис"ка 21465 сум 14 тиен акча күчерелде. Урам утлары 33131 кВт яккан, 121787 сум 64 тиенлек, материаллар алу өчен 8855,60 сум тотылды, 1 лампочкага 525 кВт туры килә. (63)

Авылларда айга ике мәртәбә Саба коммуналь хуҗалыгы тарафыннан чүп җыйнау эше алып бара.

*Схема*

**Су**

| | |
|---|---|
| 01.01.2013 ел башына кереп бетмәгән сумма | – 58945,68 |
| 2013 ел өчен исәпләнгән сумма | 463270,66 |
| 2013 елда кергән сумма | 462629,38 |
| 01.01.2014 ел башына кереп бетмәгән сумма | – 59586,96 |

**Чүп**

| | |
|---|---|
| 01.01.2013 ел башына кереп бетмәгән сумма | – 34047,71 |
| 2013 ел өчен исәпләнгән сумма | 248680,38 |
| 2013 елда кергән сумма | 250095,36 |
| 01.01.2014 ел башына кереп бетмәгән сумма | – 32812,73 |

Авылларыбыз елдан-ел матурая, төзекләнә. Ләкин безнең чисталык өстендә эшлисе эшләребез бик күп әле. Бакча башындагы печән-салам, төзелеш материалларын алып бетерәсе була. Үтәлмәгән очракта, йорт хуҗасы административ җаваплылыкка тартылачак. Тиешсез урыннарга чүп ташлауны туктатырга кирәк.

Өч авылда да иман йортларыбыз бар. Һәрберсендә авылның имам-хатыйплары эшли. Йосыф-Аланда Хуҗин Габделхәй, Тенекидә Хәсәнов Мөхәммәтнур, Юлбатта Фатхуллин Габделвәли абыйлар. Үзләрендә җыйналган акчалардан ут һәм газ өчен вакытында түләп баралар.

Үзебезнең эшчәнлекне Устав нигезендә алып барабыз. Җирлек тарафыннан кабул ителгән барлык карарлар район прокуратурасы тарафыннан даими тикшерелеп торыла. Аерым кимчелекләр булган очракта, вакытында төзәтелә.

**2013 елда налоглар үтәлеше түбәндәгечә булды**

| | План | Үтәлеше |
|---|---|---|
| Җир салымы | 430000 | 401030 |
| Милек салымы | 103000 | 114124 |
| Керем (подоход) салымы | 201000 | 330125 |
| Авыл хуҗалыгы (сельхоз) салымы | 14000 | 2882 |

2013 елда эшләнгән эшләр шактый булды. Юлбат авыл эчендәге күпергә ремонт ясалды (12 616 000 сум ), Юлбат мәдәният йортында 124 306 сумлык ремонт эшләре башкарылды, җылылыкны көйләү приборлары куелды (Юлбат СДК – 36346 сум, Юлбат СОШ – 78702 сум), Йосыф-Алан балалар бакчасына 332512 сумлык ремонт ясалды. Тукай урамына юлга 216 м. (413794 сумлык) щебенка җәелде, Тенеки авылында М.Җәлил урамында юлга су трубасы салынды (31583 сумлык), хайван зираты ремонтланды (35352 сум), посадкадан корган агачлар киселеп, җыештырылды, 2013 елда Калатау авылында 30 башка исәпләнгән ат фермасы (Галимов М.), Юлбат авылында 50 баш симертү үгезләренә исәпләнгән (Абдуллин Ф.) гаилә фермалары эшләнелде (1,5 млн. грант отып). (41476 000 сум) Йосыф-Алан авылында 400 башлык сыер торагы, 2 сенаж чокыры, фураж өчен склад, плитә юл (9 950 000 сум), фермага аерым башня куелып су кертелде. Бу объектлар 2013 елда эшләп тапшырылды.

2013 елның көзендә Юлбат кирпеч заводы эшли башлады. Бүгенге көндә заводта 34 кеше эшли. Бу – киләчәктә халыкка эш, җирлеккә өстәмә керем булачак дигән сүз.

Ел саен язын, көзен авыллардагы зиратлар чистартыла, корган агачлар киселә, зират коймалары яңартыла. 2012-2013 нче елларда Йосыф-Алан халкы 110 430 сумлык материал алып зиратларын койма белән әйләндереп алдылар, Тенеки авылы халкы 167000 сумлык материал алды. Бүгенге көндә зиратка койма тоту эше дәвам итә. Юлбат авылы зиратына чүп контейнеры куелды. Халыктан 13150 (8797 сум бюджет) сум акча җыелып Юлбат авыл башындагы чишмә ремонтланды. Бу эш киләчәктә дә дәвам итәчәк.

Район башлыгының тәкъдиме белән 2014 елда зиратлар өчен тотылачак чыгымнарның 50%ы бюджеттан финансланачак. Калган 50% үзарасалым хисабына эшләнәчәк.

2014 елда урамнарны ремонтлау, һәйкәлне төзекләндерү, хуҗасыз калган хуҗалыкларны ачыклап теркәлү үткәрү төп бурычыбыз булып тора. Шулай ук Тенеки авылының Бишбалта урамы белән ферма арасындагы елганың күперен ремонтлап бетерүне максат итеп куябыз.

2014 ел барыбызга да бәхет, шатлык, исәнлек-саулык, муллык, тынычлык алып килсен.

## Эрләндерүдән соң колхоз тормышы

1953 елда түбәндәге колхозлар берләшә:

Юлбат “Ворошилов“,

Тенеки “Яңа юл“,

Йосыф-Алан “Магнит“

Берләшкән колхозга Ворошилов исеме бирелә. Берләштерелгән колхозда терлекләрне урнаштыруда кыенлыклар туа. Дүрт колхозның терлеген ничек урнаштырырга? Һәрберсендә дүртәр-бишәр төрле терлек. Мәсәлән, Йосыф-Аланда гына да алтмышлап кәҗә, сарык, сыер, күркә, каз булган.

Тенекидә – дуңгызлар, Йосыф-Аланда сыерлар кала. Юлбатка сарыклар, кәҗәләр төшерелә. 800 баш сарык һәм тавык калдырыла. Күркә, каз дәүләткә сатыла яки тавык белән алмаштырыла. Юлбатта саманнан сарык торагы, Тенекидә агачтан дуңгызлар торагы салына. Колхозда 40 баш ат була. Тимерчеләр булып Юлбатта Сафин Насыйбулла, Мөбәрәкшин Дәүли, Тенекидә Ганиев Хәбибрахман абыйлар эшли.

1956 елда Ворошилов исемендәге колхозның исеме “Искра” колхозы итеп үзгәртелә.

1953-1955 елларда колхоз председателе булып эшләгән Хуҗин Габдрафыйк истәлекләреннән:

“Колхозчы кулында миңа кадәр кул арбасы иде, колхоз идарәсе ат белән тәэмин итә башлады. Хуҗалык кул белән бакча китмәнләүдән котылды, сука кerә башлады.



Иске клуб алдында бирнә җыючылар

Ул чакта урман кисү һәм юл эшләренә колхозчылар тартылды.

Зур истәлек – районга кайтарылган 8 машинаның берсен – “ГАЗ-51”не безнең “Ворошилов” колхозына бирделәр. Колхозның беренче машинасы. Шофёрыбыз юк иде әле, шофёр итеп Сатыш авылыннан Фәттахов Нәҗмине килешү белән эшкә алдык. Аның ярдәмчесе булып Юлбаттан Шәйхетдинов Фазылҗан эшләде. Ике елдан соң инде Юлбатның үз авыл егете Габделхаев Насих бу шоферны алыштырды”.

“ГАЗ-51” машинасыннан тыш 8 сантиметрга туралган агач (чурки) ягып йөрүче бер машинасы булган колхозның. Бу машинаның шофёрлары Мусин Миңлебай, Ихсанов Равил. Чуркиларны ике малай – Локман белән Солтан Ногмановлар ягып йөргән.

1955-1959 елларда колхоз председателе булып Мифтахов Вафа Шәрәфетдинович эшләгән, 30 меңче, Октябрьскидан, КПСС члены.

Ул эшләгән чорда, 1958 елда, МТСлар бетерелә, техника колхозларга сатып бирелә. Шул елны “Искра” колхозына 5 трактор, 5 комбайн тракторчылары, комбайнчылары белән кайта. Менә ул комбайнчылар: Сафин Раян, Фәттахов Зиннур, Сәгыйтов Нургали, Кәшипов Җәүдәт, Фәтхриев Габдрахман. Үз тракторларын иярләп кайткан тракторчылар: Хаҗиев Миңлебай, Бадиков Дәүли,



1961 елда төзелгән ремонт мастерское. 2013 елда сүтелде

Сәләхов Миңлехан, Исламов Мөбәрәкҗан, Саттаров Фоат, Фәйзриев Хәй, Хисамиев Фәттах, Ибәтуллин Мөдәррис, Мәрдәнов Хәбибрахман, Тимеров Мөдәррис. Тракторчылар бригадиры булып Гасыймов Тимерҗан, аның ярдәмчесе булып Галимҗанов Хәниф кайта.

Председатель колхозга яңа “ГАЗ-69” җиңел машинасы юллап ала. Йосыф-Аланда 100 баш сыерлар торагы, проект белән эшләнеп бетеп, файдаланыла башлый. Бу чорда колхоз бухгалтеры Низамиев Габделхәй, счетовод – Шәмсиев Һарун була.

1960-1967 елларда председатель булып Саба авылыннан Вәлиев Миңлегали эшли. Түбәндәге мәгълүмат аның хәтерләве буенча Ракова Саҗидә апа язып алганнардан:

Бу чорда колхозда дүрт “ДТ-54”, өч “Беларусь” тракторы һәм алты комбайн бар иде. Аларда эшләү өчен тракторчы һәм комбайнчылар җитәрлек иде. 1962 елда 8 кеше тракторчылар курсын тәмамлап кайтты. Вәлиев Миңлегали шул елларда шофер булып эшләгән кешеләрдән Мөбәрәкҗанов Рәис, Ихсанов Равил, Хәлилов Сәет, Галиев Наил, бертуган Рухылбаян һәм Габдрахман Фәтхриевларны атый.

Бу еллар эчендә агроном булып Нургалиев Һашим эшли. Иген уңышы өчен җирне тәрбияләүгә игътибар бирелә, чәчүлек орлыкның сыйфатын яхшырту турында кайгыртыла. 1965 елда бөртеклеләрдән 8,45 ц, бәрәңге һәм кукуруз чәчүлекләреннән 129ар центнер уңыш җыеп алынды, 1966 елда уңыш – 8,5 ц. “1966 елдан колхоз I-II класслы орлыклар гына чәчә башлады”, – дип язды агроном Һ.Нургалиев “Җиңү байрагы” газетасының 22 октябрь, 1967 ел санында.




“ГАЗ-51” автомашинасы

Авыл халкы өчен иң зур куаныч – авылга Ильич лампалары кабынды (подстанция белән). Электрлашу Юлбат белән Тенекидә – 1960, Йосыф-Аланда 1961 елда төгәлләнде. Төзү материалы алырга ат белән Казанга, Арчага, Кукмарага барылды. Бу эшкә Арча СМУ-3 начальнигы Попов А. бик зур ярдәм итте, дип искә ала Вәлиев Миңлегали.

1961 елда 2000 башка исәпләнгән чеби торагы төзелде. 1961 елда табигый таштан мастерской салынды (ул 2013 елда сүтелде). 1962 елда Тенекидә агач күпер төзелде (баганалары таш, таш фундаментта). Бу елларда 2000 центнер ашлык сыйдырышлы амбар төзелде. Юлбатта агачтан 150 башка тана торагы, кирпечтән 300 башка тавык абзары төзелде. Тенекидә 60 баш тана, 300 баш симертү дуңгызлары группасы өчен агачтан имән баганалар белән тораклар салынды (1985 елда бу тораклар сарык абзарлары итеп яраклаштырылды). 1963 елда Юлбатта кибет салынды. Клубка, колхоз идарәсе бинасына капиталь ремонт, янкорма эшләнде. 1963 елда борчак сатып «ГАЗ-51" автомашинасы алынды.

Председатель Вәлиев Миңлегали авылны төзекләндерүгә зур игътибар итте. Халык өчен 3000 табак шифер алып кайтты. Ул чакта бу зур ярдәм иде. Ул "Искра" колхозы хезмәтчәннәренең бик эшчән булуларын, эш көненә генә эшләгәндә дә зур көч куюларын искә ала. Үзе дә колхозчыларның хезмәтен җиңеләйтергә тырыша. Терлекчеләр хезмәтен җиңеләйтү өчен, сөтчелек фермасында сыерларга автоэчергечләр куела, тавык фермасында тирес чыгару өчен транспортерлар куела.



Авыл агайлары. Сулдан: Исламов Ихсан, Нигъмәтҗанов Галимҗан, Гыйлаҗиев Габделхай, Шәмсиев Рәшит



Юлбат клубында “Почет билгесе” тапшыру тантанасы.
Трибунада М.Г.Нигъмәтҗанов, президиумда беренче рәттә: (сулдан) райкомның беренче секретаре У.З.Закиров, ТАССР Верховный Советы председателе С.Г.Батыев, партоешма секретаре Г.Н.Низамиев; икенче рәттә: (сулдан уңга) беренче бригада җитәкчесе Н.Т.Галиев, ферма мөдире Ф.Мусин



Нигъмәтҗанов Миңлехан Галихан улы

1967 елның 12 апреленнән 1973 елның гыйнварена кадәр “Искра” колхозында председатель булып Нигъмәтҗанов Миңлехан Галиханович эшли. Ул белгечлеге буенча агроном, КПСС члены, Теләче районы Казаклар авылыннан.

Ул эшләгән елларда Юлбат авылында агачтан 5 бүлмәле башлангыч мәктәп салынды, ә Тенеки авылында яңа клуб бинасы төзелеп бетте. 10 мең башка исәпләнгән механикалаштырылган тавык торагы, 30 мең башлык чеби торагы, Юлбатта таштан амбар, пилорама, 400 тонна сыешлы орлык склады, Йосыф-Аланда 100 башлык сыер торагы сафка басты. Бу төзелешләргә колхоз председателе М.Нигъмәтҗанов күп көч куйды.

1972-1973 елларда Юлбат – Саба дамбасы күтәрелә.

Колхозда 5 йөк машинасы, 6 комбайн, 11 трактор (шулардан 6 сы чылбырлы) була. 1972 елда кошчылыкта эшләүче коллектив һәр тавыктан 192 шәр данә йомырка алуга иреште.

Бу елларда игенчелектә ашламалар куллану артты. Дөрес чәчү әйләнеше кертелде. Механизатор кадрларның белемен күтәрү өстендә эш көчәйтелде. Шул

эшләрнең нәтиҗәсе буларак, игенчелектә уңышлар елдан-ел арта барды. 1966 елда, мәсәлән, һәр гектардан 8,57 ц бөртеклеләр уңышы алынса, 1967 елда – 11,41 ц, 1969 елда – 12,90 ц, 1970 елда – 15,47 ц, 1971 елда – 16,64 ц, 1972 елда – 14 ц бөртеклеләр уңышы яуланды. Корылыклы елда бу зур сан районда иң югары күрсәткеч иде. Шушы елда, СССР төзелүнең 50 еллыгы хөрмәтенә, безнең “Искра” колхозы “Игенчелектә югары культура өчен” ярышта алдынгы урынны алуы өчен КПСС Үзәк Комитетының, СССР Верховный Советы Президиумының һәм ВЦСПСның юбилей “Почет билгесе” белән бүләкләнде.

Әлеге уңышлар – артта калган колхозны торгызу өчен җибәрелгән Миңлехан Галихан улының бөтен белемен, яшьлек энергиясен биреп эшләү нәтиҗәсе. Аның эше “Хезмәттәге батырлык өчен”, “Ленинның тууына 100 ел тулуга” медале, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән зурлап бәяләнә. Ә иң зур бәяне ул җитәкләгән колхоз члennары бирә. Колхозчылар аны бүгенге көндә дә олы хөрмәт хисләре белән искә алалар.

Ул вакыттагы КПСС райкомы, аның оештыру сәләтен күреп, район авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы итеп күчерә.



Әхтәмов Гаптелмәннәф Гапсәләмович

1973 елның 1 январеннан 1986 елның июленә кадәр Әхтәмов Гаптелмәннәф Гапсәләмович колхоз председателе булып эшләде. Ул бөтен көчен, белемен авылның тормыш-көнкүрешен яхшырту өчен биргән шәхес. Авыл халкының аңа булган ихтирамы искиткеч зур. Кукмара районы Чишмәбаш авылында туып үскән кеше булса да, халык аны үз авылдашы итеп хис итә, олылый, чөнки аның бөтен гомере шушы колхоз авылларына хезмәт итеп үтте.

Җитәкче вакытта үзенең гадилеге, кешелеклелеге, шул ук вакытта киң эрудицияле, белемле булуы белән авылдашларының ихтирамын яулады. Лаеклы ялга чыккач та Мәннәф абый авылның иң мөхтәрәм һәм кирәкле кешесе булып кала бирә. Яшь белгечләр аңа киңәшкә киләләр, авылдашлар бакчачылык буенча сораулар белән мөрәҗәгать итәләр.

Ә хәзер ул эшләгән чорда күмәк хуҗалык ирешкән уңышларга тукталыйк. 1973 елда колхоз бәрәңге уңышы буенча һәр гектардан 218 ц уңыш алып, республикада беренче урынны яулады. 1974 елда бөртеклеләрнең һәр гектарыннан 20 центнердан артык уңыш алынды. 1976 елда – 19,1 ц, 1977 елда – 16,6 ц, 1980 елда – 17 ц, 1981 елда (һава шартлары начар ел) 12,3 ц, бәрәңге – 100 ц. 1982 елда – 25,8 ц, 1985 елда – 18,5 ц, 1986 елда – 21,9 ц һәр гектардан бөртеклеләр алынды. Шул рәвешчә, иген уңышы алу елдан-ел яхшыра барып, “Искра” колхозы район, республика хуҗалыклары арасында алдынгы урыннарда булды.

Әхтәмов Г.Г. эшләгән дәвердә төзелешләргә дә зур әһәмият бирелде. 1975 елда авыл уртасыннан ага торган инеш суы аша таш баганалы зур күпер салынды.

Йосыф-Аланда, Юлбатта терлекчеләр йорты төзелде. Йосыф-Аланда 400 башлык сыер торагы сафка басты. Юлбатта яңа пилорама, ашлык киптерү



Уракның беренче көнендә комбайнчыларны кырга озату. Уртада икмәк тотып алдынгы комбайнчылар Гасыймов Тимерҗан, Рәхмәтуллин Сәет (уңда). 1976 ел



Колхоз рәисе Г.Г.Әхтәмов баш агроном Р.Р. Хаҗиев улы белән (уңда)



Колхозның төзүчеләр бригадасы. Беренче рәттә (сулдан уңга) Хәлиуллин Хәммәт, Шәмсиев Рәшит (бригаданың җитәкчесе), Вәлиев Ризван; икенче рәттә (сулдан уңга) Мансуров Самат, Кәбиров Кашафетдин, Фатыйхов Вазыйх

җайланмасы М-1900 эшләнде, бәрәңге подвалы, печән склады, техникага ягулык салу станциясе, Юлбатта симертү терлекләре өчен торак төзелде. Техникага хезмәт күрсәтү өчен 50 тракторга исәпләнгән типовой мастерской төзелде, АВМ-005 агрегаты төзелеп эшли башлады, конторага пристрой (1980 ел, хәзер инде иске контора), АТС, Тенеки белән Юлбат арасында 200 башлык сыер торагы төзелә башлады. Юлбатта культура йорты (1986) куллануга тапшырылды.

1986 елның башында колхозда 19 автомашина, 26 трактор, 19 комбайн (“Нива”, “Колос”), 5 бульдозер, 2 автобус бар иде.

Колхозда механизатор кадрлар саны да арта бара. 1986 ел башына тракторист-машинист таныклыгы булган 60 механизатор хисаплана.

1986 елның июленнән 1991 елга кадәр Фәритов Фоат Фәритович председатель булды. Бу вакытта 200 башлык сыер торагы төзелеп бетте. 1989 елда урта мәктәп бинасы төзелеп файдалануга тапшырылды.



Озак еллар хуҗалыктан сөт җыйган Галимуллина Бәрия



Сабантуй күренеше, 1970 еллар башы



Юлбатлылар район сабантуенда, 1970 еллар уртасы



Теники янындагы сабантуй, арткы планда Юлбат күренә



Төзүчеләр бригадасы. Сулдан уңга: Шәмсиев Рәшит,
Рамазанов Әмирҗан, Хәлилов Галиәхмәт, Мөбәрәкҗанов Раиф


«Искра» колхозы механизаторлары. 1976 ел


Колхоз идарәсе белгечләре, артта уңнан беренче – колхоз рәисе Ф.Ф. Фәритов



Габдрахманов Наил Афзал улы

1991-1997 елларда Габдрахманов Наил Афзал улы күмәк хуҗалыкны җитәкләде. Юлбатта дүрт түгәрәк склад, ябык ындыр табагы, бозаулар торагы, пилорама (Йосыф-Алан), кирпеч заводы (Юлбат), мәчет (Юлбат) төзелде. Юлбат – Йосыф-Алан, Тенеки – Йосыф-Алан дамбалары күтәртелде. Юлбатта һәм Тенекидә газ трассалары салынып, хуҗалыкларга газ җибәрелде. 1993 елда машина-трактор паркында җылы гараж төзелеп файдалануга тапшырылды. 1995-1996 елларда ашлык киптерү агрегаты эшләнде, Юлбатта 200 башлык ике терлек торагы (1991-1993) төзелде. Һәр өч бригадада да тораклар җылы галерка (коридор) белән тоташтырылып (1993-1996), терлекчеләрнең эш шартлары уңайланды. Өч авылда да су үткәрелде, скважиналар, су башнялары яңартылды. Тенеки, Юлбат башнялары үзара тоташтырылып, насослар янган очракта, бу ике авыл бер-берсен вакытлыча су белән тәэмин итәрлек итеп көйләнде.1991 елда “Асты урамда” су беренче тапкыр үткәрелде. Колхозчылар өчен квартиралар төзелде.

1997 елда Габдрахманов Наил Афзал улы район авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы итеп билгеләнде.

2000 елның 18 февраленнән 2007 елга кадәр Наил Афзал улы – кабат хуҗалык җитәкчесе. 2001-2002 елларда ашлык чистарту җайланмасы кайтартып көйләнде.Ул эшләгән чорда электр баганалары алыштырылды, Юлбат, Тенеки, Йосыф-Алан авылларында тимер-бетон субайлар, тимер прогоннар белән күперләр салынды. Тенекидә яңа күпер 2003 елның 3 октябрендә ачылды. Шул ук елның 17 октябрендә мәдәният йортына җирле үзидарә Советы кертелде.



Кәбиров Васыйл Сәетгали улы

Наил Афзалович председатель булып эшләгән еллар колхоз системасы төрле үзгәрешләр кичергән чорга туры килде. Базар экономикасына күчү, реформалар үткәрелү сәбәпле, колхозлар дәүләт ярдәменнән мәхрүм булган бер чорда, ул, төшенкелеккә бирелмичә, бөтен көчен авылның киләчәген өметле итә торган төзелешләргә юнәлтте. Аның тырышлыгы белән булдырылган корылмалар бүгенге көндә дә авыл халкына хезмәт итәләр.

1997-2000 еллар – Кәбиров Васыйл Сәет улы хуҗалык җитәкчесе булган еллар. Йосыф-

Аланга газ трассасы салынып, хуҗалыкларга газ җибәрелде. 1998 елда Юлбат–Саба дамбасы асфальтланды. Калай түбәле ашлык склады төзелде. Мастерской каршындагы ферма эшләнеп бетеп файдалануга тапшырылды.

1990 елларда СССР таркалып, илдә базар мөнәсәбәтләре урнаша башлагач, колхозның да экономик хәле шактый кыенлаша. 1994 елның март аенда “Искра” колхозы “Искра” күмәк предприятиесе итеп, 2003 елның март аенда “Юлбат” крестьян (фермер) хуҗалыгы һәм, ниһаять, 2007 елның январь аенда җаваплылыгы чикләнгән “Юлбат” авыл хуҗалыгы предприятиесе” җәмгыяте итеп үзгәртелә. Коллектив членнарының тырыш хезмәте нәтиҗәсе буларак, җәмгыять бүгенге көндә дә игенчелек, терлекчелек продуктлары җитештереп сату буенча алдынгы урыннарда бара.


Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре Бикмөхәммәтов Закирҗан Миннемуллович

2006 елның декабрендә җаваплылыгы чикләнгән “Юлбат” авыл хуҗалыгы предприятиесе” Саба аграр көллиятенең база хуҗалыгы итеп билгеләнә. Көллиятнең директоры – Бикмөхәммәтов Закирҗан Миңлемуллович. 2007 елның гыйнвареннан 2008 елның 15 февраленә кадәр Тимершык авылыннан Мусин Рашат Гайфиевич хуҗалыкның директоры була.

2008 елның февраленнән – Олы Шыңар авылыннан Мөхәммәтов Илфат Шәкүр улы директор.

Эшнең нәтиҗәлелеген күтәрү максатында, 2013 елның 16 октябреннан Килдебәк, Туктар авыллары “Җаваплылыгы чикләнгән “Юлбат” авыл хуҗалыгы предприятиесе” җәмгыятенә кушылды.

**Юлбатта колхоз председателе булып эшләгән кешеләр:**

1. 1930-1931 ел, сентябрь – Дәүләтшин Гани (Ганиева Нуриянең әтисе), (счетовод булып Хаҗиев Хуҗаәхмәт эшли).

2. 1931 сентябрь – 1932 май – Зәйнуллин Гыйззетдин (Зәйнуллин Гобәйнең абыйсы).

3. 1932 май – 1932 декабрь – Галләмов Низами (Низамиев Рамил Газиз улының бабасы)

4. 1933-1935 еллар – Гомәров Гаффар.

5. 1936 ел – Гаффаров Мансур (Югары Шытсу, КПСС чл.) (счетовод булып Зәйнуллин Гобәй абый эшли, эшне Хуҗаәхмәт абыйдан ала. Контора Ризатдин абыйларның әтисе өендә була. Аслы-өсле өй, өстә – контора, аста Зыятдин гаиләсе тора).

6. 1937 ел – Исламов Госман (Ихсан абыйның энесе), счетовод – Зәйнуллин Гобәй. 1936 елдан 1937 елның җәенә кадәр.

7. 1937-1938 еллар – Гайнетдинов Шәмси – Сатыш кешесе. Ул эшләгән чорда Нуруллалар янындагы су тегермәнен Рәхмәтуллин Сәетләр бакча башына күчереп салалар. Авылның Чәүкә ягындагы ферма урынында саманнан ферма, конюшня эшләнә. Насыйр исемле кешене хәзерге Билалов Тәлгатьләр яшәгән җиргә күчереп, аның урынына иске контора бинасын салалар.

8. 1939-1940 ел – Хуҗин Хаҗи (Хаҗиев Айратның бабасы).

9. 1941 ел – Гайфуллин Билал (9 ай эшләгәч, сугышка китә). Счетовод булып 1941 елның июленнән 1942 елның августына кадәр Низамиев Газиз абый эшли.

10. 1942 ел, җәйгә кадәр Нигъмәтҗанов Галимҗан.

11. Сугыш еллары – Хисамиев Бадыйк.

12. Сәләхов Шәйхи (Юлбат, Сәләхов Ясәви абыйның абыйсы).

13. Шәрипов Хәнәф (Мамалай кешесе).

14. Нигъмәтҗанов Галимҗан (Юлбат).

15. 1945ел – Самарин Салих.

16. 1946 ел – Абдуллин Гали (Көек авылы, КПСС члены).

17. 1947 ел – Абдуллин Гыйният.

18. 1947-1953 еллар – Галләмов Мансур. Счетовод – Зәйнуллин Гобәй. Эшне Мәүгия ападан ала.

19. 1953-1955 сентябрь – Хуҗин Габдрафыйк. Йосыф-Аланда сыер торагы эшләнә башлый. Казаннан килеп эшлиләр. 1954 елда “ГАЗ-51” машинасы алына, тракторлар, комбайннар кайта. 1953 елда колхозлар берләшә: Тенеки – “Яңа юл”, председателе Шәмсетдинов Габделбәр; Йосыф-Алан – ”Магнит”, председателе Гыймадиев Җәләй һәм Юлбат – Ворошилов исемендәге колхоз.

20. 1955-1958 еллар – Мифтахов Вафа (30 меңче, Октябрьскидан, КПСС члены.

21. 1959-1960, февраль – Саттаров Фрунзе.

22. 1960 ел, апрель. – 1967 ел, апрель – Вәлиев Миңнегали (Сабадан, КПСС члены)

23. 1967 ел, 12 апрель – 1973 ел, январь – Нигъмәтҗанов Миңнехан Галихан улы.

24. 1973, январь – 1986, июль – Әхтәмов Гаптелмәннәф Гапсәләм улы.

25. 1986-1991 еллар – Фәритов Фуат Фәритович.

26. 1991-1997 еллар – Габдрахманов Наил Афзал улы.

27. 1997-2000 еллар – Кәбиров Васыйл Сәет улы.

28. 2000 ел, 18 февраль, 2007 ел – Габдрахманов Наил.

**Партия оешмасы секретаре булып эшләгән кешеләр:**

1948-1949 нчы еллар – Низамиев Газиз

1949-1954 нчы еллар Абдуллин Гыйният

1954-1958 нче еллар – Фәләхов Вагыйзь (6 КПСС члены була)

1959-1960 нчы еллар – Абдуллин Гыйният (13 КПСС члены)

1960 ел, октябрь – 1966 ел, октябрь – Ракова Саҗидә (42 КПСС члены)

1966-1973 еллар – Низамиев Габделхай (32 КПСС члены)

1974-1991 еллар – Галиев Наил (56 КПСС члены)

**Юлбатта авыл Советы председателе булып эшләгән кешеләр:**



Гомәров Шәмси

1. 1928-1929 еллар – Фәтхуллин Идрис (Урта Сабадан)

2. 1930-1931 еллар – Гомәров Гаффар (Юлбаттан)

3. 1931-1933 еллар – Дәүләтшин Мансур (Юлбаттан)

4. 1933-1934 еллар – Әхмәдуллин Хәбибулла (Урта Сабадан)

5. 1935 ел – Рәхмәтуллин Сәйфулла (Шытсу)

6. 1936 ел – Гомәров Шәмси (Шәмсиев Талипның бабасы, Юлбаттан)

7. 1937 ел – Мөбәрәкҗанов Кыям (Урта Сабадан)

8. 1938-1939 еллар – Заһидуллин Әһели (Урта Сабадан)

9. 1940-1943 еллар – Камалов Зыя (Урта Сабадан)

10. 1944 ел – Хуҗин Гобәй (Түбән Шытсу)

11. 1945 ел – Самарин Салих (Сабадан)

12. 1946-1947 еллар – Гыйниятуллин Нурый (Бигәнәй)

13. 1948 ел, январь – 1949 август – Низамиев Газиз (Юлбат)

14. 1949-1954 еллар – Абдуллин Гыйният (Юлбат)

15. 1954-1963 еллар – Фәләхов Вагыйзь (Юлбат), (1963-1973 елларда авыл Советы секретаре булып эшли)

16. 1963-1971 ел, 19 май – Тимерова Нурания (Тенеки)

17. 1971-1985 ел, 19 май – Шәмсетдинова Фәрхәнә (Тенеки)

18. 1985, ноябрь – 1986 апрель – Мансурова Сәрия (Юлбат)

19. 1986 апрель – 1988 май – Рәхимуллина Хания (Юлбат)

20. 1988, 11 май – 1995 ел – Абдуллин Һашим (Юлбат)


21. 1996 ел, январь – 2003 ел, август – Кәримов Раил (Юлбат)

22. 2003 ел, август – 2010 ел – Гайфуллина Диләрә (Юлбат), 1980-2003 елларда авыл советы секретаре.

23. 2010 елдан – Шәмсиев Талип (Юлбат)



Абдуллин Һашим



Кәримов Раил



Гайфуллина Диләрә



Сафина Альбина, 2003 елдан Юлбат авыл Башкарма комитеты секретаре



Хәлилова Зәмфәрия, 2002 елдан Юлбат авыл Башкарма комитеты бухгалтеры

***Истәлекләр:***

1931 елның декабреннән 1933 ел урталарына кадәр Дәүләтшин Мансур авыл Советы председателе булып эшли. 1932 елда колхоз һәм аерым хуҗалыклар көче белән Рахимуллин Рамилләр тыкрыгы турында инеш аша агач күпер салына. Озынлыгы 28 метр, өч бозваткычлы. Күпер бөтен авыл халкы көче белән салына. Сабай авылыннан 6 ат белән чуен “Баба” китерәләр. Колхоз 2 диләнкә алып бирә. Кисү, ташу аерым хуҗалыклар көче белән башкарыла. (Бу чакта әле 45 ләп аерым хуҗалык аты була.) Күпер эшләүчеләргә аш пешерелә. Бигәнәйдән Касыйм, Түбән Шытсудан Шәмсетдинов Шәйхетдин исемле осталар эшли.

Бу күпер 1947 елның 3 апрелендә язгы ташу суы белән китә. Икенче көнне бүрек киеп йөрерлек суык булды, дип хәтерли өлкәннәр.

**Беренче тракторчылар (1930-1932 еллар)**

Юлбат авылы буенча:

1. Биктаһиров Галим – сугышта үлә.
2. Гәрәев Хәй
3. Хаҗиев Таҗи – сугышта үлә.
4. Якупов Фәйзерахман – сугышта үлә. Сафин Илдарның әнисе Якупова Оркыяның абыйсы.

Искәрмә: Алар 1930 елда Саба МТСында эшли башлыйлар.

5. Хаҗиев Миңлебай – 1938 елдан эшли башлый.

Тенеки авылы буенча:

1. Хисамиев Фәттахетдин – Хисамиев Фәһеметдиннең әтисе.
2. Фәйзриев Габделхәй
3. Ногманов Нурислам
4. Ганиев Хәбибрахман (1936-1941 еллар).
5. Шәфигуллин Сабир – сугышта үлә. Сабиров Хәтмулла абыйның әтисе.



Якупов Фәйзрахман.
Сугышка кадәрге фото



ГРАМОТА

награждает т. Якупова

почетным званием ударника

II-го года второй пятилетки,

активно проявившего себя в борьбе за

Якупов Фәйзрахманга
бирелгән грамота. 1935 ел




Грамотаның арткы ягы

**1932-1941-1946 елларда эшләгән хатын-кыз тракторчылар:**

Галимуллина Шәмсениса – Юлбат авылы кызы, Галимуллин Рамазанның әнисе.

Тракторчы булып Юлбатка эшкә килеп, авылда төпләнеп калган киленнәр:

1. Мифтахова (Ибраһимова) Гыйлемсара – Мифтахов Хәнәфиянең әнисе.
2. Таҗиева Фатыйма – Хаҗиев Рәшитнең әнисе.



Галимуллина Шәмсениса



Мифтахова Гыйлемсара



Таҗиева Фатыйма


“Юлбат авылы колхозчылары беренче тракторны 1931 елда күрә. Саба МТС-ында эшләүче, шушы авыл тракторчысы Биктаһиров Галим “Фордзон” тракторы белән Юлбатка кайтып керә. Аны бөтен авыл гаҗәпләнү катыш шатлык белән каршы ала. Ләкин әле 1934 нче елларда да ат җигеп, чәчкеч тагып чәчү чәчкәннәр. 1934-1935 елларда колхозга самосброскалар кайта. Бу да шул чор өчен яңалык. Самосброскалар 5 көлтәлек итеп урып ташлап бара, ә колхозчы хатын-кызлар

кул белән көлтә бәйләп бара. Мондый эшләр әле 1950 елларга кадәр дәвам итте". (Сугыш һәм хезмәт ветераны Гайфуллин Билал ага истәлекләреннән.)

"1937 елда "Коммунар", "Саратов" дигән комбайннар кайта. Аларны тәгәрмәчле трактор тартып йөргән. Мин үзем дә тартып йөрдем андый комбайннарны",– дип искә ала шул чактагы тракторчы Хаҗиев Миңлебай абый.

## Хәмидулла Хуҗиәхмәтовның Теннеки авылы турында язмаларыннан

***Хәмидулла Хуҗиәхмәтов (язучы Мәгъсүм Хуҗинның әтисе) – Тенеки авылы тарихыннан кызыклы сәхифәләрне язып калдырган шәхес.***



Хәмидулла Хуҗиәхмәтов

Хәмидулла Хуҗиәхмәтов егерменче гасырның утызынчы еллары ахырында авыл, район тарихында булган вакыйгаларны өлкәннәрдән сорашып һәм үзе хәтерләгәннәр буенча теркәп бара. Алтмышынчы елларда аның авыл, район тарихы буенча язмалары район, республика матбугатында басыла. Ул язмалар истәлекләргә һәм бер үк вакытта архив материалларына нигезләнгән. Хәмидулла ага алтмышынчы-җитмешенче елларда Татарстан Милли архивы, Партия өлкә комитеты архивларында эзләнгән.

Хәмидулла аганың 1904 елда туган булуын исәпкә алсак, аның үзенең дә күп тарихи вакыйгаларның шаһиты булуын аңларбыз. Үзе күргән, үзе кичергән кешенең язмаларына таянып, Октябрь революциясе алды һәм революция елларындагы, колхозлашу чорындагы авыл тормышын күзаллауга өметләнәбез.

Хуҗиәхмәтов Хәмидулла Хуҗиәхмәт улы 1904 елда Тенеки авылында крестьян гаиләсендә туа. Әти-әниләре Октябрь революциясенә кадәр үз хуҗалыкларында эшлиләр һәм байларга бил бөгәләр. Хәмидулла да, авыл мәдрәсәсен тәмамлауга, 1916 елда Сәгъдиевка эшли башлый. Революциядән соң җир алгач, 1920-1926 елларда үз хуҗалыгында әти-әнисенә булыша. 1926-1928 елларда Урал шахталарында забойчы булып күмер чаба. Туган ягына кайткач, авылларда аерым хуҗалыкларны күмәкләштерү буенча эш башлануын күреп, баш-аягы белән оештыру эшләренә чума. 1928-1930 елларда Тенекидә авыл Советы председателе вазифасын башкара. Ул, авыл Советы председателе буларак, Тенекидә иң актив колхоз төзүчеләрдән була (аның ул чордагы хезмәте турында Тенеки авылында колхоз төзелеше турындагы язмадан укырга мөмкин). 1930 елда колхоз төзелгәч, "Яңа юл" колхозы (Тенеки авылы) председателе булып сайлана.

1933 елның мартында, партия райкомы бюросы карары нигезендә, Баландыш авылындагы “Актив” колхозына хисапчы итеп җибәрелә. Шул ук елның июль аенда Килдебәк авылындагы “Яңа тормыш” колхозына председатель итеп сайлана. Бу елларда Хәмидулла Хуҗиәхмәтов югарыдагы җитәкчелек тарафыннан авылларга еш күчереп йөртелә. Сәбәбе коллективлаштыру процессының җиңел генә бармавы белән аңлатыладыр. Кайда эш авырлык белән бара, аны шунда җибәргәннәрдер, мөгаен.

1935 ел башында партия райкомы бюросы тәкъдиме белән Иске Мичән авылындагы “Кызыл йолдыз” колхозына председатель итеп сайлана. 1938 ел башыннан 1942 елның августына чаклы Тимершык авылындагы “Кызыл таң” колхозында председатель булып эшли. 1942 елның августыннан 1963 елның апреленә кадәр, ягъни пенсиягә чыкканчы, район үзәгендәге Карл Маркс исемендәге колхозда председатель булып эшли.


Ә хәзер Хәмидулла ага истәлекләренә мөрәҗәгать итик.

## Тенеки авылы атамалары ни сөйли?

Авылның беренче кешесе милләте буенча чирмеш булырга тиеш. Аның шулай булуын авыл башындагы иске зиратның “чирмеш зираты” атамасы да раслый.

Бездән өлкән өченче-дүртенче буын кешеләре заманында авыл урман эчендә булган булырга тиеш. 1912 елда 83 яшендә үлгән безнең Файзә әби Әрәмә тавы өстендә урман янганны сөйли иде. Басудагы төрле исемнәр дә үзенә күрә бер тарихны аңлата. “Ут урыны” – урман янган урын, “Саз башы” – урман эчендәге сазлыклы урын. Урман кискән җирләрне “ышналар” дип атаганнар. “Югары”, “Урта”, “Түбән” ышна дигән атамалар шуннан калган. Кайбер ышналарны урман кискәч ул җирләрне биләгән кешеләр исеме белән дә атаганнар. “Апый ышнасы”, “Габит ышнасы” дигән җирләр шуннан калган. Патша заманында дәүләт фондындагы Тенеки басуына чиктәш урманны Казан бае Юнысов (ул патшаның якын дусты була) 80 мең сум алтынга сатып ала. Ул аны 4 малаена, 2 кызына бүлеп бирә. (Элекке Кызыл Яр урманы.) Шул вакытларда Тенеки, Мәртен басулары артындагы бер өлеш урманны да Хәбибулла дигән бай сатып ала һәм ике киявенә бүлеп бирә. Бер кияве бер марҗага сата, “Марҗа урманы” дигән атама шуннан килә. Икенче кияве үзенә тигән урманны Тенекидә яшәүче Габтрәкыйпов Дәүләтшага сата, акчасын эчеп бетерә. “Дәүли җире” атамасы шуннан калган. Революциягә хәтле ул җирне балалары биләде. (Дәүли үзе 1906 елда басуда үлә.)

“Бәләкәй җире”, “Бәләкәй юлы”, “Бәләкәй елгасы” атамаларының да үзенә күрә бер тарихы бар. Мәртен, Туктар басуы артындагы урманлы җирләрнең байлардан калган өлешен аз җирле авылларга да бүлеп бирәләр. Бер өлеше Тенеки, Бигәнәй, Урта Саба авылларына, бер өлеше Өчнарат якларына бүлеп бирелә. Ә 70 гектар чамасы җирне элеккеге Әбде волостенда старшина булып эшләүче Гөлем (Владимир) дигән кеше үзенә бүлеп ала. Ул бу җирдә каралтылар корган, иген чәчеп, җирне ваклап сатып файдаланган. Бу кеше үзе Чия башы авылыннан



Хәмидулла Хуҗиәхмәтовның 1930 елларда алып барган көндәлегеннән бит

Бәләкәйнекеләр нәселеннән булган. Шуңа күрә бу җирне “Бәләкәй җире” дип атаганнар. “Бәләкәй юлы”, “Бәләкәй елгасы” да шуннан аталып калган.

“Янәсәй җире” атамасының тарихы да кызыклы. 1911 елда 14 хуҗалык, җирләрен Шытсу мулласына сатып, Себергә китәләр. Алар Енисей елгасы буена китү сәбәпле, җирләренә “Янәсәй” исеме бирелгән.

Йосыф карт һәлакәт белән үлгән урынны Йосыф аланы дип атаганнар.

## 1921 елгы ачлык турында хатирәләр

1921 елда иген уңмау сәбәпле, 1922 елда килеп чыккан ачлыкта Тенекидә 1 январьдан 11 апрельгә кадәр 3 ай да 11 көндә 21 ир кеше, 23 хатын-кыз үлә. Шуларның 26 сы ачлыктан, 7 се ачлык китереп чыгарган авырулардан вафат була.

Шушы ачтан үлгән кешеләрдән Габдулла мулла кабер сәдакасы ала торган була. Түли алмаучыларның исемнәрен, бурычлылар буларак, метрика дәфтәренә язып бара. Мәсәлән, Хөснетдинов Мөбәрәкшадан бер пот арыш, Исмәгыйлев Ибраһимнан бер пот арыш, Мәүлин Минзакирдан 10 кадак арыш аласы калган.

Габдулла мулла үзенең метрика дәфтәренең артына фытыр сәдакасы җыйнау буенча отчет та язып куйган. Фытыр сәдакасын түләп бетерә алмаган 34 хуҗалыкның исемлеген теркәгән. 1921 ел өчен бу исемлек буенча 14 пот 10 кадак бодай җыйнап алынган, 13 пот 30 кадак җыясы калган. Фытыр сәдакасы балигъ булганнар (18 яшьтән) өчен 5 кадак бодай белән була. Әгәр муллага сәдаканы арыш, арпа, солы, борай белән бирсә, крестьян артыграк тиеш булган.

## Өйләнешү, туй йоласы

Өйләндерер, кияүгә бирерлек яшьтә балалары булган кыз һәм егетнең ата-анасы яки якын туганнары, үзара килешеп, сөйләшү өчен вәкил (димче дип атаганнар) җибәргәннәр. Кыз яки егетнең ризалыгы соралмаган, күп вакытта алар, бигрәк тә кызлар, моны белмәгәннәр дә. Кызны ярәшү (ризалашу) вакытында башка бүләк-санаклар өстенә мәһәр турында да сөйләшенгән. Мәһәр – егетнең кыз атасына туй мәҗлесе үткәрү өчен бирергә тиеш булган билгеле бер күләмдәге акча.

## Патша заманында солдат хезмәте

Патшага 25 ел солдат хезмәте иткән вакытта байлар үз балалары урынына фәкыйрь кеше балаларын акчага яллап җибәргәннәр. Мәсәлән, Тенеки авылында “наемщик Шәрәфи” дип йөртелгән кеше булган. Аның әтисе Теләче ягындагы Комаровка авылыннан бер рус бае баласы өчен ялланып хезмәт иткән. Картаеп, сакал җиткереп кайтып, 50 яшьләрдә генә өйләнгән. Ул авылдагы җирдән мәхрүм ителгән. Аңа күп кенә башка өстенлекләр бирелгән булган, тик ул алардан файдаланырга теләмәгән.

## “Мәртен җире” өчен барган дәгъва

Халык телендә “Мәртен җире” өчен дистә еллар барган дәгъва турында имеш-мимешләр яшәп килә. Бу дәгъва кайчан башланган һәм кайчан тәмамланган? Сәбәбе нидә? Ни өчен Тенекиләр Мәртен җирен даулаганнар? Бу сорауларга беркем дә анык кына җавап бирә алмый. Ә менә Хәмидулла ага истәлекләрендә бу сорауларга җавап бар.

Патша заманында дәүләтнең бер өлеш урманын байларга сатып бирәләр. Шул чакта аз җирле авылларга да, агач төпләп чәчүлек җир булдыру өчен, урманның бер өлеше бүлеп бирелә. Тенеки, Бигәнәй авылларына 270 дисәтинә, Өчнарат якларына 340 дисәтинә урман бүленә (Тенекинең 96 яшьлек Гыйлаҗи бабай әйтүенә караганда, бу хәл 1890 елларда булырга тиеш, дип яза Хәмидулла ага). Тенеки халкы, һөнәрче булганга, бирелгән урманны үзе төпләми, ә Мәртен, Туктар халкына килешү белән биреп чистарттыра. Килешү нигезендә иген чәчәргә дә биреп тора. Соңыннан Мәртен, Туктар кешеләре үзләре чистарткан җирне үзләштерәләр. Тенеки, Бигәнәй халкы дәгъвалый башлый, ләкин Мәртеннәр, Туктарлар бу җирләрне хуҗаларына бирүдән баш тарталар. Шулай еллар уза, 1906 елда Бигәнәй һәм Тенеки авыллары Мәртен, Туктарларны судка бирәләр. Җир өстендә суд була. Судта эш тулысы белән Тенекиләр файдасына хәл ителә. Ләкин адвокат белән землемерга дигән акчаны һәм суеп чистартылган казларны, халыктан җыйнап алганнан соң, Тенекинең Габитов Хөсәен, Рәхмәтуллин Шәфигулла, “сельский” Сабирҗаннар үзләренә үзләштерәләр, адвокат белән землемерга аз гына өлешен бирәләр. Шуңа ачу итеп, адвокат белән землемер, җирнең картасын үзгәртеп, 100 дисәтинә җирне Мәртенгә күчереп эшләп куялар. Бу 100 дисәтинә җиргә Мәртеннәр чәчәләр, Тенекиләр налогын түлиләр. Соңгылары, бу хәл белән килешергә теләмичә, “Чертежная палата” дигән урыннан план күчермәсен соратып алалар. Бу эшне Тенекидән Кадыйров Насыйр белән Бигәнәйнең Кашаф (ул яхшы укый-яза белә, русча яхшы сөйләшә) дигән кешеләр Мамадышка барып өязнең җир бүлегеннән тикшертеп башкаралар. Ләкин бу да җирне кире кайтарырга ярдәм итми. Башка чара калмагач, 1907 елда, Мәртен һәм Туктар халкын җирдән куып чыгару өчен, Тенеки, Бигәнәй халкы сугышырга була. Күршеләренең хаклы икәнен белгән Урта Сабалылар да аларга кушыла. Тенекинең бик йөрәкле, таза, көчле кешеләре – Җамали, Гыймади, Зәйнулла, Хәмзәләр башлап йөриләр. (Таза булган өчен патшаның гвардия дип аталган армиясендә хезмәт иткән булалар). Алар кушуы буенча, ул замандагы бик усал, көчле кеше Рәхмәтуллин Шәфыйк, атка атланып, бөтен халыкны сугышырга куып йөри. Карышкан кешеләрне шунда ук кыйнап китә. Авылның “сельский” дип аталган кешесе Вәлиулланың хәбәр итүе буенча, патша хезмәткәре Казак Кәримулла, гаскәр белән килеп, җир өстендәге салкын кораллы сугышны таратып, Туктарларны авылларына хәтле куа. Мәртеннәр качып бетәләр. Тенекидән Хәмзә Ибрае дигән кешенең авызы шушы сугышта кыеклана (аның башын борган булалар), Урта Сабадан Фәттах һәм Фәрхулла дигән кешеләр чулак булып калалар.

Җиргә дәгъва моның белән бетми, көрәш байтак еллар дәвам итә. Җирдән күбрәк вакыт Мәртен белән Туктар файдалана.

1918 елда Икшермә авылының Мухин Зыя дигән кеше бу җиргә тагын дәгъва кузгата. Вакыйгада инде фронттан авылга корал белән кайткан солдатлар да катнаша. Бу хәлләрне инде Хәмидулла яшүсмер малай буларак үзе дә күзәтә һәм күргәннәрен язып калдыра: "Тенеки, Бигәнәй, Урта Саба яклары, Марҗа урманында агач башына сәндерә ясап, Туктар, Мәртен авылларына каршы корал белән сугыштылар. Басу тулы кеше булды. Без дә Бәләкәй елгасына кадәр бардык. Мылтык тавышларыннан куркып, Йосыф-Алан елгасы буйлап төшеп китеп, Юлбат юлыннан кайттык. Без кайтканчы Туктар, Мәртен авылы кешеләрен Тенекигә алып төшеп амбарга япканнар иде. Аларны куркыту өчен амбарның стенасына, түбәсенә аттылар. Шуннан соң, бикле ишек аркылы ант иттереп, Насыйр абзый һәм башкалар аларны ачып чыгардылар. Туктарлар, Мәртеннәр, башкача каршылык күрсәтмәскә сүз биреп, кайтып киттеләр.

1918 елда бу җирнең бер өлешен (күләмен хәтерләмим) безнең авыл халкы үзләренә өлешкә кертеп бүлде. Җир турында яңа закон чыккач, бу җиргә дәгъва бетте. Аны беркетеп, тигезләп бүлделәр. Тенекиләр Йосыф-Аланга күчкәндә аларга бер өлеше бирелде, калганы Мәртеннәргә күчте. Ул җир өчен Мәртен басуының Саз башыннан байтак җир Тенекигә кисеп бирелде". (Хәмидулла Хуҗиәхмәтов язмаларыннан.)

## Имана җире турында

Тенекидә бер иманага бер дисәтинә җир тигән (дисәтинә – 1,092 гектарга тигез).

Бер дисәтинәдән байлар 7-8 арба, урта хәлле (үз җирен үзе эшкәртүче) 5-6 арба, ә инде кешегә сукалаткан атсызлар 3-4 арба уңыш алган. Бер арба бөртеклеләр уңышы 5-6 пот килгән (якынча бер центнер). 10 арбадан бер арба – муллага гошергә, җан башына 5 кадагы фытыр сәдакасына бирелгән. Аннан башка крестьян ярык тояклы бер малны (сыер, сарык, кәҗә) корбанга чалып, тиресен муллага бирергә тиеш булган.

## Көнлекченең эш хакы һәм җир налогы

Байларга кул белән урак уру бер көнгә 20 тиен, бер әвен сугу кеше башына 5 тиеннән булган, бер әвенне 4-5 кеше суккан. Бер иманага налог 4-5 сум булган. Налог түләр өчен байларга арышның потын 30 тиеннән, солыны 20 тиеннән, онны 40 тиеннән сатканнар.

## Авылда Хуҗиәхмәтләр нәселе

Хуҗиәхмәтов Хәмидулла үз нәселе турында истәлекләр дә язып калдыра. Авылда яшәгән һәр кешенең язмышында авыл тарихы чагыла, аерым кешеләр тормышы авыл тормышын күзалларга ярдәм итә. Хуҗиәхмәтовлар язмышы аркылы революциягә кадәрге авыл тормышын фаразларга тырышып карыйк.

“Патша Россиясе заманында безнең нәселне “Мамадыш мещаны” дип йөрткәннәр, – дип башлый Хәмидулла ага үзенең язмаларын. – Метрикага һәм башка документларга шулай язылган.  Безне “Мамадыш мещаны”, башкаларны “государственный крестьянин”, “сәүдәгәр”, “мулла”, “солдат” һ.б. дип язганнар. Октябрь революциясенә кадәр безнең нәсел (“Мамадыш мещаны”) түбәндәгеләр булган: Мостафин Мөбәрәкша, Мостафин Хуҗиәхмәт, Мостафин Нигъмәтҗан, Җамалиев Шәрәфетдин, Галиуллин Тимергали, Гаффаров Мәүлә, Гаффаров Галләм, Гаффаров Фәрхетдин, Хөсәенов Шәрифҗан, Хөсәенов Камалетдин, Әхмәтҗанов Әхтәмҗан, Әхмәтҗанов Мөхәммәтҗаннар. Өлкәннәрнең әйтеп калдыруларына караганда, алар патшага хезмәткә бармаган өчен җирдән мәхрүм ителгәннәр. Бу хәлләр бик күп еллар элек булса да, конкрет фактларга нигезләнгән. Безнең әткәй Хуҗиәхмәтнең атасы Мостафа, аның атасы Гаптелкаһир, аның атасы Гаптелкәрим булган. Менә шушы Гаптелкәрим бабайның ике хатыны булган. Олы хатыннан 4 малай, кече хатыннан 3 малае булган. Бу вакытта яраклы табылган һәр ир кеше 25 ел солдат хезмәте итәргә тиеш булган. Гаптелкәрим бабай, яшь хатыннан туган 3 малаен солдат хезмәтеннән алып калу өчен, үзенә тигән җирдән баш тарткан. Җир алардан соң килгән буыннарга да бирелмәгән. Еллар үтеп, безнең нәсел кешеләрен дә солдатка ала башлагач, җирләрен сорап алганнар. Ләкин аларга җирне үзләре яши торган Тенеки авылыннан түгел, Мамадыш шәһәре янындагы Вятка суы яры буендагы биек тау башыннан, бик начар җирдән биргәннәр, үзләренә шунда күчеп утырырга кушканнар. Хәтта бер хуҗалык – Гаффаров Мәүләнең бер малае Әхмәтов Шакир анда күчеп тә киткән”.

1912 елда Тенеки авылындагы кулаклар, куштаннар бу гаиләләрне авылдан куарга, шул җирләргә җибәрергә тырышканнар. Җирсез булсалар да, бу нәсел кешеләре авылдан китмәгәннәр. Ләкин алар авыл гражданы булып саналмаганнар, авыл җыеннарында катнашу һ.б.лардан мәхрүм ителгәннәр. “Октябрь революциясенә кадәр безнең нәселдән 12 хуҗалык җирсез иде. Мин үзем әткәй мәрхүмнең 1918 елның яз айларында авыл җыеныннан шатлыклы хәбәр алып кайтканын хәтерлим. Безгә дә җирне хәзер авылдан бирәләр, җыеннарга барып катнаша алабыз, яңа закон чыккан, аңа патша урынына куелган Ленин кул куйган икән, дип сөйләде. Шушы 1918 елның язында җир бөтен халыкка (хатын-кызларны да кертеп) тигез итеп яңадан бүлеп бирелде. Без дә җир алып иген чәчә башладык”, – дип яза Хәмидулла ага. (Хәмидулла аганың язуыннан аңлашылганча, патша армиясенә бармаган өчен аларның нәселен авылдагы җирдән мәхрүм итү 5 буынга сузылган, бары Октябрь революциясеннән соң гына бу нәсел җирле булган. – *И.Ф.*)

## Тенеки тарихының  кайбер сәхифәләре

Беренче спектакль Дәүли бай салдырган мәдрәсәнең өйалдында 1920 елда була. Аны Сабадан килгән укытучы Вәлиуллин Гарифулла оештыра.

Авылда кооперация төзү 1924 елда үткәрелде. Аны НЭП чоры сәүдәгәре Ганиев Хәким оештырды. Ул, авыл кешесенең исемлеген язып, кооперациягә членнар туплады. 2 сум 50 тиеннән взнослар җыйнады, ярлылар өчен үзе түләп

торды. Халыкка товар алып кайтып сата башлады. Шул ук вакытта кооперация членнарына күтәргә товар биреп торып алардан процентлар алды. Шулай байлык туплады, раскулачивание вакытында сөргенгә җибәрелмәде, милекләре алынды. Үзе шахтага китте.

Колхозда беренче председатель – Сәгыйтов Шәмси. Беренче бригадир 1932 елда Мөбәрәкшин Габдрахман булды.

1931 елда колхозда кирпеч сугу оештырылды. Ул колхозга күп доход бирде. Саба мәктәбен төзегәндә 120 мең кирпеч бирдек.

## Совет мәктәбе тарихыннан

Авылда беренче совет укытучысы 1918 елда килеп, дин сабагы урынына “җәдитчә” укыту башланды.

Сабаның Вәлиуллин Гарифулла, Гәрәева Асылбикәләр 1920 елда бөтен балаларны, шул исәптән кыз балаларны да укыта башладылар.

1925 елның 2 декабреннән волбашкарма утырышының № 10 беркетмәсе белән Саба авылыннан Шәмсия Әхмәтова халык акчасы хисабыннан айга 20 сум хезмәт хакы белән Тенекигә укытучы итеп билгеләнә. Аңа бу акчаны кышын гына түлиләр, шуңа күрә ул авыл Советында секретарь да булып эшли.

Беренче совет мәктәбе бинасын 1926 елда авыл Советы председателе Саттаров салдыра. Ике класслы мәктәп була ул.

## Тенеки авылында Совет власте урнашу

1917 елда Октябрь революциясе булганнан соң, халык җыенында староста Латыйпов Галинең медален һәм печатен алып, үзен авыл җыеныннан куып чыгарганнар. Бу эшләр белән авылга Совет властен урнаштыручыларга ярдәмгә җибәрелгән солдат Кадыйров Насыйр җитәкчелек итә. Шушы ук көннәрдә Насыйр җитәкчелегендә волостьның старшинасын һәм башка вазифаи затларын урыннарыннан алалар. Волость старшинасы урынына Сатыштан Гариф байда приказчик булып эшләгән Габделганине сайлап куялар, ләкин ул бу эшне алырга курка. Шуннан соң Туктар авылыннан килгән, революцион эшне башлап йөрүче Вәйдуллин Хәлилне сайлап куялар. Туктардан Әмиров Гатаулла, Шыңардан Фәйзрахман, Сабадан Минһаҗ Галиме һәм Шәймәрдәннәр волость идарәсе составына сайланалар. Озак та үтми, Сатыштан Нәҗметдин волбашкарма председателе булып сайлана.

1919 елда Хөснетдинов Сәләхине төшергәч, Кадыйров Насыйр авыл Советы председателе булып сайлана.

Хәмидулла ага язмаларында Кадыйров Насыйр белән бәйләнгән тагын бер факт теркәлгән: авылга килгән отрядлар магазиндагы икмәкне алып китәргә җыенган чакта, Насыйр Кадыйров, авыл ярлыларын туйдырыр өчен кирәк дип, икмәкне сорап алып калган.

1926 елда Тенеки авыл Советы председателе Мияссәр Яруллин, секретаре Сабир Шәфигуллиннар була. Аларны, динчеләр йогынтысына бирелүдә, яр-

лыларга каршы булуда гаепләп, эшләреннән алалар. Хәниф Саттаровны – рәис, укытучы Шәмсия Әхмәтованы секретарь итеп куялар. “1928 елның көзендә авыл Советына сайлау вакытында Саттаров урынына рәис итеп мин сайландым. Ул чакта авыл Советы рәисенең айлык эш хакы 14 сум, секретарьга 13 сум иде. Тормыш алып барыр өчен мин рәис тә, секретарь да булып эшләдем”, – дип яза Хәмидулла ага.

## Тенеки авылында “Яңа юл” колхозы төзелү

Колхозларның 1930 елларда төзелгәнен өлкән буын кешеләр белә. Әле ун ел тирәсе генә Совет власте биргән җирдән файдаланып калган аерым хуҗалыкларны колхозларга берләштерү ничек барган, бу эш күпме вакытта башкарылган, аның чаралары нинди булган, аерым хуҗалыклар колхозга мәҗбүри кертелгәннәрме, әллә аңлату эшләре алып барылганмы, бу эшләр белән кемнәр шөгыльләнгән, яңа оешкан колхозларга дәүләт ярдәме булганмы? Сораулар, сораулар… Еш бирәбезме без үз-үзебезгә бу сорауларны? Һәрберебезнең дә әтиәнисе, әби-бабалары шушы җирдә гомер иткәннәр, бар булган милке белән колхозга кергәннәр. Аңларга тырышабызмы без аларның яшәешен, хис-тойгыларын? Юк, тагын бер кат – юк. Чөнки хәзер бу җирлектә яшәүче буын бары тик күмәк хуҗалык булып яшәүне генә хәтерли. Гел шулай булгандыр кебек. Колхоз төзүчеләр инде берсе дә исән түгел. Ул еллар кайтавазы халык хәтерендә дә бик аз сакланган. Бәлки, аз сөйләнгәндер? Вакыты шундый булган бит.

Колхоз төзелү турында киләчәк буыннарга язып калдырырга кирәк. Чөнки ул безнең үткәнебез, әби-бабайларыбыз кичергән язмыш.

Бу яктан Тенеки авылы бәхетле, чөнки колхозны актив төзүчеләрнең берсе Хәмидулла Хуҗиәхмәтов (язучы Мәгъсүм Хуҗинның әтисе) ул көннәрдә барган вакыйгаларны бөртекләп язып, калын-калын дәфтәрләр туплаган, соңрак ул елларның шавын район, республика матбугатында яктырткан. Без дә Тенеки авылында колхоз төзелү вакыйгаларын аның язмаларына нигезләнеп һәм Октябрь революциясенә 50 ел тулган көннәрдә район, республика газеталарында басылган “Күмәк тормыш корганда” дигән мәкаләсеннән өзекләр китереп бирәбез. Үзе колхоз төзеп йөргән, вакыйгаларның үзәгендә кайнаган, авылдашларының авыр тормышын уңай якка үзгәртү өчен бөтен көчен биргән шәхеснең язмалары “коры” архив материалларына караганда күпкә кыйммәтлерәктер, бәлки.

Ул еллар турында Хәмидулла ага болай яза: “Бөек Октябрь революциясе җиңгәч, Коммунистлар партиясе авыл хуҗалыгын социалистик нигездә үзгәртеп коруны кичектергесез бурыч итеп куйды. В.И. Ленин: “Вак хуҗалык белән мохтаҗлыктан чыгып булмый… Эре үрнәк хуҗалыкларда бергәләшеп эшләүгә күчәргә кирәк”, – диде.

Партия карары нигезендә крестьяннар җирне бергәләп машина белән эшкәртү ширкәтләренә берләшә башладылар. Бу чорда Саба волостеның Иләбәр авылыннан унбишләп хуҗалык үз җирләрен кисеп алды, поселок булып күчеп, җирне бергәләп машина белән эшкәртү ширкәте (ТОЗ) төзеде. Шытсу авылыннан

унлап хуҗалык элеккеге алпавыт Юнысов җиренә күчте, ширкәткә берләшеп, авыл хуҗалыгы машиналары сатып алды. Иләбәр поселогында ширкәтне Газиз Мәрдәнов һәм Кашаф Кәлимуллин, ә икенчесен – Калатау ширкәтен – Рәшит Шәфигуллин оештырды. Безнең Тенеки авылында Шәмси Сәгыйтов, Хәсән Максудов һәм мин үзебезгә тигән җирләрне бер урыннан бүлеп алдык һәм ширкәт булып оештык.

Әлеге авыл хуҗалыгы ширкәтләре 1928 елда авыл хуҗалыгы артельләренә әверелделәр. "Революция" колхозында (Иләбәр) Газиз Мәрдәнов, "Калатау" колхозында Рәшит Шәфигуллин председатель итеп сайланды. Волость күләмендә күмәкләшүгә керешкәндә бу колхозларның эш үрнәкләре телгә алып сөйләрлек иде инде. Төрле авыл кешеләре, әлеге колхозларга килеп, күмәк хуҗалык белән танышып йөрделәр. Без дә өчәүләп "Революция" колхозына бардык.

Авыл хуҗалыгын күтәрү буенча крестьяннарга практик ярдәм күрсәтү өчен, волость башкарма комитеты, берничә авылдан участоклар төзеп, аның җитәкчесен һәм бер агроном билгеләде. Алар авыл Советлары белән берлектә һәр хуҗалыкка чәчү планнары, агрономия чаралары, дәүләткә продукция сату планнары җиткерделәр, бу эшләрнең үтәлешен күзәттеләр.

1929 елның азагы иде. Без волостьның авыл Советы председательләре киңәшмәсенә җыелдык. Анда партиянең волком секретаре Рәхмәтуллин, волбашкарма комитеты председателе Ибәтуллин һәм кантоннан килгән бер вәкил, колхозлар төзү буенча конкрет бурычлар куеп, речь сөйләделәр. Безгә булышу өчен волость учреждение работникларыннан ярдәмчеләр билгеләнде. Тенеки авыл Советына Юныс Нуруллин һәм Усман Мостафин куелды.

Без, әлеге киңәшмәдән соң авылга кайткач, яңа тормыш төзү турында укытучы Харис Бәхтияров белән мәктәп бинасында планнар кордык. Х.Бәхтияров безгә халык алдында сөйләү өчен кыска гына доклад төзеп бирде. Икенче көнне комсомоллар катнашында ярлылар, батраклар җыелышы җыйдык. "Авылда яңа тормыш коруга риза булып колхозга керүчеләр" дигән баш астында исемлек ясап куйдык. Җыелышта исемлеккә беренче булып үземне язып, семьямдагы дүрт җан белән колхозга керәм, дип кул куйдым. Миннән соң Шакир Йосыпов, Гариф Гатауллин, Хәсән Максудов, комсомол ячейкасы секретаре Фәрт Арсланов кул куйдылар.

Иртәгесен авыл Советы членнарын җыйнап сөйләштек. Бу утырышта авыл Советы членнары Шәмси Сәгыйтов, Мөбәрәкша Батыршин колхозга язылдылар.

Берничә көннән соң хатын-кызлар җыелышы булды. Анда колхозны мактап та, яманлап та сүзләр күп әйтелде. Шулай да үзләре семья башлыгы булган Газизә Шәрәфиева, Мәгъфүрә Шаһивәлиева колхозга член булып керделәр. Һәм бу факт үзе генә дә зур җиңү иде.

1930 ел башында ун хуҗалык колхозга берләштек. Хәзер инде, колхоз күзгә күренерлек булгач, авыл җыелышы үткәрергә мөмкин иде, һәм шундый җыелыш 1930 елның гыйнварында булды. Анда катнашу өчен "Революция" колхозыннан Хаҗи Исламовны, "Калатау" колхозыннан Рәшит Шәфигуллинны чакырдык. Алар үз колхозлары турында чыгыш ясадылар. Халык кызыксынып тыңлады,

күп сораулар бирелде. Җыелышта ундүрт хуҗалык колхозга керү турында гариза язды. Шулай итеп, колхозда 24 гаилә булды, колхозга “Яңа юл” исеме бирелде, устав кабул ителде, биш кешедән правление, колхоз председателе итеп Шәмси Сәгыйтов сайланды. Алга китебрәк әйтик, 1930 елның азагында инде колхозга 52 хуҗалык керде.

Бераздан колхозчылар мине председатель итеп сайладылар. Бу вакытта төп бурыч чәчүлек орлык туплаудан, каралтылар төзеп җәмәгать терлекләрен урнаштырудан, кулакларның һәртөрле җимерү эшләрен фаш итүдән гыйбарәт иде. Авылда күпчелек ялгыз хуҗалык булган шартларда боларны тормышка ашыру җиңел булмады. Кайбер колхозчылар һаман да икеләнделәр, кулаклар һәм дин башлыклары яңадан-яңа корткычлык уйлап таба тордылар. Кулакларны сыйныф буларак бетерү өчен көрәш көчәйде. Алар авылдан кача башладылар. Бер төндә өч кулак гаиләсе качты.

Аерым чәчелгән арышларны берләштереп, иллегә якын хуҗалык колхоз булып оешкан хәлдә урып-җыю үткәрелде. Язгы чәчү өчен җитәрлек орлык, терлек өчен азык тупланды, колхозчыларга шактый ашлык бүлеп бирдек. Күмәк хуҗалыкның беренче уңышыннан дәүләт амбарына да өлеш керттек.

Беренче чорда хезмәтне оештыру начар иде. Аны исәпкә алуда, аңа түләүдә, дөресен әйтергә кирәк, тәртип булмады. Доход семьяда ничә кеше булуына карап бүленә иде. Бу хәл исә күп кенә ризасызлык китереп чыгара иде”. (Хәмидулла Хуҗиәхмәтовның алда әйтеп киткән язмасыннан.)

Шулай итеп, колхозлар төзүгә хәзерлек этабында, 1927-1928 елларда, җирне күмәкләп эшкәртү белән шөгыльләнә торган күмәк хуҗалыклар оештырылган. Алар төрле формада булган. Иң киң таралганнары – ТОЗ (товарищество обработки земли) һәм артельләр. Аларда аерым хуҗалыклар бергәләп эшләү буенча беренче күнекмәләр алган, дәүләт ярдәменә өмет итәргә мөмкин булуга инанган.

Тенеки авылында колхоз төзелү елы булып 1930 ел санала. Күргәнебезчә, бу елда әле йөз процент күмәкләштерүгә ирешелми. Район буенча караганда, 1935 елда күмәкләшү 91 процент була.

Алда атап кителгән “Күмәк тормыш корганда” дигән мәкаләсендә Хәмидулла Хуҗин җирне колхозлар карамагына бирү вакыйгасын да тасвирлый. Аның Иске Мичән авылындагы “Кызыл йолдыз” колхозында председатель булып эшләгән вакыты була бу. “1935 елның ноябрендә колхозлар җирне мәңге файдалану өчен дәүләт акты белән кабул иттеләр. Бу тарихи вакыйга зур тантана төсендә үтте һәм ул авылда колхоз строеның тулысынча җиңүен күрсәтте. Җирне мәңге файдалану өчен кабул итү бәйрәмендә безгә күрше колхозлардан делегацияләр килде. Безнең Иске Мичән авылы колхозчылары Керәнне, Бакшанды, Яңа Мичән авылларына бардылар”, – дип яза Хәмидулла ага 1967 елда бу шатлыклы хисләрне кабат күңеленнән кичереп. Еллар узар, колхоз строен хуҗалык итүнең башка формасы алыштырыр, дип уйлый да алмагандыр үзе колхоз төзеп йөргән Хәмидулла ул вакытта. Утызынчы ел колхозчылары, үз җирләрен колхозга биреп, соңрак “мәңге файдалануга” хокук алган кешеләр, дәүләтнең бу адымына шатланып бәйрәм итеп йөргәндә, бу җир хуҗалары кайчан да булса алышыныр, дип шулай ук башларына да китермәгәннәрдер.

**Тенеки авылында 1933 елда хуҗалыкларның бүленеше турында белешмә:**

| № | | Гаиләдә кеше саны | Чәчү җире мәйданы (га) |
|---|---|---|---|
| 1. | Кулаклар | | |
| | Насыйров Габдулла | 3 | 4,65 |
| | Абдуллин Шәми | 5 | 7,75 |
| | Ибраһимов Газизҗан | 8 | 12,40 |
| | Сәгъдиев Камали | 4 | 6,20 |
| | Габдрахманов Гәптри | 5 | 7,75 |
| | Мәхмүдиев Әхмәди | 7 | 10,85 |
| 2 | Көченеп читкә китүчеләр: | 25 гаилә<br>103 кеше | 159,65 |
| 3 | Аерым хуҗалыклар: | 56 гаилә<br>221 кеше | 374 |
| 4 | Колхоз члennары | 79 гаилә<br>345 кеше | 537 |
| 5 | Документны өйрәнгәндә кемлеген ачыклап булмады | 4 гаилә<br>26 кеше | 40,30 |
| Искәрмә: җан башына бер кешегә 1,55 га җир туры килгән | | | |

**“Яңа юл” колхозының (Тенеки) 1936 елда чәчүлек мәйданы, уңыш алу, аны бүлү турында отчеты**

| | Мәйдан (га) | Уңыш ц/га | Тулай җыем ц |
|---|---|---|---|
| Арыш | 328 | 4,23 | 1386 |
| Бодай | 70 | 1,80 | 133 |
| Арпа | 54 | 2,11 | 133 |
| Солы | 197 | 3,02 | 59 |
| Карабодай | 20 | 0,78 | 15 |
| Вика | 15 | 1,60 | 25 |
| Борчак | 80 | 2,80 | 235 |
| Җитен | 26 | 0,87 | 22,8 |
| Киндер | 3 | 0,07 | 0,22 |
| | 757 | 3,28 | 2504 |

Дәүләткә сату – 901 ц
Симәнәгә – 529 ц
МТСка натурплата – 418 ц
Фуражга – 196 ц
Колхозчыларга хезмәт көненә – 307 ц

Колхозда терлек саны:
КРС – 2
Сарык – 17
Атлар – 65
Сату:
Ит – 1,37 ц
Йон – 0,40 ц
Кергән керем:
Тегермән тартудан – 75 ц
Сепаратордан май – 11,8 кг
Урман ташудан – 1526 сум
Йөк ташудан – 2275 сум

## Тенеки авылында көмешчелек һөнәре турында укучыларның эзләнү эшеннән

Тенекидә көмешчелек һөнәре XVIII гасырда башлана, Габделкәрим исемле кеше белән бәйле, дип сөйлиләр өлкәннәр. Аның ике хатыны, беренче хатыныннан дүрт малае, икенче хатыныннан өч малае була. (Габделкәрим хәзерге онықларының җиденче бабасы санала.) Ул икенче хатынын бик тә яраткан икән һәм аңардан туган өч малаен патша армиясенә егерме биш ел хезмәт иттерергә теләмәгән. Моның өчен җирдән ваз кичәргә тиеш булган ул. Һәм Габделкәрим, җирсез калгач, көмешчелек һөнәрен үзләштерә, тора-бара бу шөгыль бөтен авыл кешеләренә үз булып китә. XX гасырның унҗиденче елы алдыннан авылда җирсез гаиләләр ундүрткә җитә, бу гаилә кешеләре тулысынча көмешчелек белән шөгыльләнәләр.

Көмешчелек авыл кешеләренең тормыш-көнкүрешен билгеле дәрәҗәдә яхшыртуга китерә. Революция алдыннан бер йөз җитмеш ихаталы Тенекидә ике йортлы һәм алты почмаклы (бер) йортлы кешеләр утыз бишкә җитә, салам түбәле йортлар илле сигезгә кала, атсызлар илле биш санала (беренче чиратта җирсезләр). Патша заманында авылда эре җир биләүче бер алпавыт, өч сәүдәгәр (НЭП чорында тагын бишәү өстәлә), ике җир арендаторы, өч тегүче була, калганнары көмеш эше белән шөгыльләнә.


Билгеле инде, авыл кешеләренә бүтән һөнәрләр дә ят булмый. Исмәгыйль исемле кеше, мәсәлән, Күмәчче, Итче һәм Дегетче кушаматларын да йөрткән. Ә аның төпчек – җиденче баласы Мөхәммәтгасыйм оста көмешче булып танылa.

Бизәнү әйберләре ясауда хатын-кызлар да катнашкан. Шаһимәрдан исемле кешенең хатыны Зөләйха останың остасы саналган. Гүзәл зат гүзәллек серен әйбәтрәк белгәндер, күрәсең. Шаһимәрдан һәм Зөләйха “өязгә” бергәләп тә чыккалаганнар һәм Пермь өлкәсендә бер авылда (Шәймәрдан булса кирәк) нигез корып та калганнар.

Авылда әле бу гасырның утызынчы елларына чаклы Хәйрулла Кәримулласы һәм Бичи Габдулласы да осталыклары белән дан тотканнар. Кәримулла өязгә




Музейда Тенеки көмешчеләренең эш кораллары




Ганиев Хәбибрахман эшләгән көмеш бизәнү әйберләре

чыгып йөрмәгән, ул үз авылы кешеләре соравына гына эшләгән-осталар да үзләреннән осталарны таный белгәннәр, димәк. Авыл халкы аңа "Гадел кеше" дип кушамат биргән, алтын-көмеш тирәсендә гадел һәм ышанычлы булу – үзе дан-шөһрәт.

Бичи Габдулласы да беләзек-йөзекләрне таң калырлык итеп койган. Кушаматы исә аңа болай бирелгән. Габдулла, өяздә йөреп кайткач, өен яңарта торган булган. Ул, читтә күргән йортларны үрнәк итеп, биш өй салдырган. Шул биш өй аңа Бичи булып тагылган. Габдулланың тагын бер һөнәре була. Тенекинең тегермән буасы суы киң җәелә торган булган. Көмешчеләр өязгә китәр алдыннан авылның ир заты көзге ялтыравык бозда аяк чаңгысында (Тенекидә конькины шулай атаганнар) шуып ярышкан. Бичи Габдулласы шундый ярышларда берәүне дә үзенә җиткермәгән!..

Тенеки көмешчеләре… Әйе, аларның даны еракларга таралган.

Моннан берничә ел элек без тарих укытучысы Илдар абый белән Тенеки көмешчеләренең соңгы буын вәкиле Хәбибрахман ага Ганиевның (әле үзе исән вакытта) өендә булып, аның тормыш юлы белән танышып, көмештән беләзекләр ясау серләрен видеоязмага төшереп кайткан идек.



Хәбибрахман Ганиев

Ә хәзер үзем дә күреп белгән Хәбибрахман ага һөнәренә киңрәк тукталып китәм. Ул көмеш эше серләренә 8 яшендә үк өйрәнә. Уфа якларына өязгә чыгып йөри. Бөек Ватан сугышында катнаша. Сугыштан соң 25 ел тимерчелектә эшли. Авыл кешеләренең үтенечен тыңлап чиләкләр, сәгатьләр төзәтә, хәтта тальян гармуннар ясый. Ә иң яратып эшләгән шөгыле көмешчелек булуын ул бервакытта да яшерми. Без бу турыда сорагач, ул җанланып китте. Бер көмеш кисәге алып: "Моны сезгә эретеп күрсәтмичә булмый. Хәзер, мичне үрләтеп җибәрим әле", – диде. Хәбибрахман аганың мич дигәне эчтән кызыл балчык белән уратылган калай чиләк икән. Ул аны үзе "гурна" дип атый. Агач күмере белән ягыла икән. Күмер кызаргач, кечкенә генә калай чүлмәккә салынган көмеш тәңкә су кебек сыеклана. Нәни улакка күчереп, суынгач кына яңадан көмеш хәленә кайта. Аннары ул сандалга куела. Уртача авырлыктагы чүкеч белән чүкелә. Өслеген тигезләү өчен пресска кертелә. Валны кат-кат әйләндереп, көмеш юкартыла, тиешле озынлыкта кисеп, бөгеп беләзек ясала. Аннан инде бизәк эшләре башлана. Башта игәү-казыгыч белән рәсем ясала. Дөресрәге, төрле фигурадагы чокырлар "казыла", ә аннары әлеге уемнарга "кара алтын" – эретелгән җиз, кургаш, күкерт катнаш масса тутырыла. Кара бизәкле көмеш беләзек килеп чыга. Хәбибрахман ага бөтен ихтыяр көчен, сабырлыгын җыеп, күңел байлыгын тимергә төшерә. "Бу – вакытны күп сорый торган хезмәт. Шуңа күрә яшьләрнең олы түземлек сорый торган "ак" эш белән бик утырасылары килми",– ди Хәбибрахман ага. Дөрес, үзешчән рәссам Хәлим Габдрахманов һәм көмешченең улы Рафис Хәбибрахман агадан байтак

күнекмәләр алганнар. Әмма күңелне шунысы борчый: алар бу эшне алга таба дәвам итәрләрме? Хәбибрахман ага Тенеки авылының соңгы көмешчесе булып калмасмы?

**Шәехзадә Бабичлар нәселе – Тенекидә**

Атаклы Бабичлар нәселенең Тенеки белән бәйләнеше килеп чыгуга да Тенеки кешеләренең көмешчелек белән шөгыльләнүе сәбәпче булган.

Моны галим һәм язучы Галимҗан Гыйльмановның “Бабичлар нәселе –Тенекидә” исемле мәкаләсендә китерелгән мәгълүматлар да анык раслый: “Моңарчы Татарстан җирендә Бабичлар белән бәйле урын яисә шул гаиләдән чыккан кем дә булса бар дип уйланылмый иде. Ә менә соңгы тикшеренү-эзләнүләр нәтиҗәсендә бу фикерне үзгәртергә тиеш булдык. Саба районының Тенеки авылында Шәехзадә Бабичның бертуган апасы яшәгән икән!..”

Бу мәкалә белән танышканчы ук, 2006 елда, без тарих укытучыбыз Илдар Фатхуллович белән Тенеки авылында яшәүче ветеран укытучы Гамбәр апада булып, аның сөйләгәннәрен видеоязмага төшереп алдык. Мәктәп музеенда Шәехзадә Бабичның Гамбәр апа тарафыннан бүләк ителгән ике китабы саклана. Илдар абыйның әнисе Оркыя апа Тенеки авылында 40 ел балалар укыткан, Гамбәр апаның кызыклы шәхес булуын, Саратов гармунында өздереп уйнавын, район газетасы хәбәрчесе булуын укытучыбызга әнисе сөйләгән булган. Гамбәр апаның Шәехзадә Бабичның якын туганы булуы турында да ул сөйләп калдырган булган. Гамбәр апа белән очрашуга без, әлбәттә, Ш.Бабичның иҗатын өйрәнеп бардык. Гамбәр апа сөйләве безгә бик кызыклы булды. Аның сөйләвенчә, Тенекидән Шәмсетдин көмешченең олы улы Галәветдин (Гамбәр апаның булачак әтисе) җиде яшеннән әтисенә ияреп башкорт якларының Әсән авылына көмеш эшенә чыга башлый. Галәветдиннең әтисе өязгә чыгуларының берсендә Мөхәммәтзакир хәлфә белән таныша һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр аның якын дусты булып кала. Белемгә омтылучан Галәветдин, Әсәнгә килгәч, иркенрәк вакытларда Мөхәммәтзакир мәдрәсәсенә сабак укырга кергәли. Сәләтле, бирелгән эшне тиз үзләштерүчән шәкерт Галәветдин Мөхәммәтзакир Бабич күңеленә хуш килә, ул аны үз китапханәсенә өстәмә дәресләр бирү өчен чакыра. Шундый очрашуларның берсендә унсигез яшьлек Галәветдин Бибисара мәхдүмәне очрата һәм беренче күрүдә үк гашыйк була. Көмешче шунда ук кызның кулын сорый һәм шуның билгесе итеп аңа алтын алкалар бүләк итә.

Мөхәммәтзакир хәзрәт белән Бибисаҗидәбану абыстай көмешче Галәветдингә кызларын бирергә риза булалар. 1895 елда зур туй ясыйлар һәм яшьләрне, бирнәләр белән күмеп, берничә олау тезеп, Тенекигә озаталар. Шул ук елны Бабичлар гаиләсендә Шәехзадә исемле тагын бер малай туа.

Тенекидә Галәветдин белән Бибисара гаиләсендә дүрт бала туа – Хәбибрахман, Фәйзерахман, Хуҗагариф һәм Гамбәр. Малайлар бераз үсә төшкәч, Галәветдин аларны үзе белән өязгә алып йөри башлый, әниләренең туган яклары, туганнары белән таныштыра.

XX йөз башы – Шәехзадә Бабичның үсмер чагы, егет чагы. Һичшиксез, Галәветдин дә, аның уллары да шагыйрь белән даими очрашып торганнар, якын дуслар булганнар.

Шуны әйтергә кирәк: Шәмсетдин нәселе кешеләре Шәехзадә Бабич белән һәрвакыт горурланып яшәгәннәр. Бигрәк тә Галәветдиннең олы улы Хәбибрахманга (ул Шәехзадәдән берничә яшькә генә кече) "Бабич җене" кагыла. Хәбибрахман бөтен торышы, шөгыле-кыланышы белән шагыйрьне хәтерләткән, диләр. Аны "Хәйбери-артист", "Хәйбери-җырчы" дип йөрткәннәр. Оста гармунчы буларак та аның исемееракларда билгеле булган. Районда уздырылган смотр-ярышларда ул алдынгы урыннарны яулаган. Ә бит бу артистлык, кәмитчелек "җене", музыкага, гомумән, сәнгатькә мәхәббәт аңа турыдын-туры Шәехзадә нәселеннән күчкән булуы мөмкин. Өстәвенә Хәбибрахман шагыйрьнең иҗатын да бик яхшы белгән. Истәлекләргә караганда, Бабичның 1922 елда чыккан "Шигырьләр мәҗмугасын" ул үзенең өстәл китабы итеп тоткан. Егет андагы шигырьләрне, балладаларны, хәтта "Газазил" поэмасын ятлап алган. Алай гына да түгел, Хәбибрахман үзе дә Бабич шигърияте рухында шигырьләр иҗат иткән.

Тенеки һәм Әсән авыллары (Бабичларның туган ягы), Бабичлар һәм Шәмсетдиновлар династияләре арасындагы якын бәйләныш хакында сөйләүче тагын бер китап сакланган. Ул – Мөхәммәтзакирның кульязма китабы. Гарәпчә күнегүләрне үз эченә алган бу китапка йөз утыз елдан артыграк. Шунысы бәхәссез, ул Бабичларның атаклы китапханәсеннән алынган.

Гамбәр апа (Галәветдин белән Бибисараның кече кызы, кызганычка каршы, ул хәзер мәрхүм инде) аны Әсәнгәме, Кыйгазытамаккамы бер барганда әти-әниләренең алып баруларын сөйләде. Томанлы гына булса да, Гамбәр апа үзе дә Бабичларның китап киштәләре байлыгын хәтерли иде. Тенекигә шуннан берничә китап кайткан. Калганнарының язмышы хәзергә билгеле түгел. Ә Гамбәр апа югарыда искә алынган кулъязма китап хакында әти-әнисенең: "Бабагыз китабы иде", – дип сөйләгәннәрен исендә тоткан. Гамбәр апа сөйләве буенча, ул 12 яшьлек чагында Әсәндә һәм Бабичларның нәсел-нәсәбе башлап киткән Кыйгазытамак авылында (хәзер Башкортстанның Миякә районында) булган, туган-тумачаларын күрүгә ирешкән. Ул вакытта Шәехзадә исән булмый инде.

Гамбәр апа егерме биш ел буе Тенекидә балалар укыткан. Ул Шәехзадә Бабич иҗаты белән кызыксынып яшәгән, шагыйрь тормышына һәм иҗатына бәйле һәр мәкаләне, китапны, календарь битен җыеп барган. Галимҗан Гыйльмановның "Бабичлар нәселе – Тенекидә" дигән мәкаләсе белән дә безне ул таныштырды. "Бабичлар нәселе кешеләре белән мин бервакытта да элемтәне өзмәдем, без якын туганнар булып яшәдек. Бабамның кызлары Фәсәхәт һәм Нәҗибә Бабичлар белән хат алыштым", – дип сөйләде ул безгә.

Шәехзадә Бабич үзе Тенекидә булганмы соң, дигән соравыбызга Гамбәр апа төгәл генә җавап бирә алмады. (Әйткәнебезчә, ул Шәехзадә Бабичны исән чагында күреп кала алмаган, әти-әниләренең вафатына да шактый вакыт узган.) Шулай да Гамбәр апа шагыйрьнең Тенекигә килүенә ышанып яшәгән. Бабичның бер шигырендәге: "Казанга керә алмадым" (Тенекигә килгән вакытта дип уйлый

Гамбәр апа) – дигән юлларны ачык хәтерли ул. Минем дә Шәехзадә Бабичның Тенекигә килүенә бик ышанасым килә. Чөнки 1910-1916 елларда Галәветдиннең уллары баштарак әтиләре белән өязгә чыгалар, соңыннан мөстәкыйль көмешчеләр булып китәләр. Бу вакытта Тенеки белән Әсән арасында элемтәләр тагын да ныгый. Шәмсетдин нәселеннән берничә кеше Мөхәммәтзакир мәдрәсәсенә укырга да керә. Әлбәттә, алар җәйге ялга кайтканда, шагыйрь Шаехзадә Бабичның алар белән Тенекигә килүе мөмкин. Моннан чыгып, без, горурланып, атаклы шагыйрьнең Тенеки ягында, безнең якларда булу мөмкинлеген фаразлый алабыз.

## Йосыф-Алан авылы тарихыннан кайбер мәгълуматлар

Бу авыл урнашкан урыннар элек Казанның Кәрим хаҗи, Дәүли бай җирләре булган. 1917 елда Югары Шытсу, Түбән Шытсу, Юлбат, Тенеки авыллары крестьяннары Кәрим байның имениесен таркаталар, соңыннан ут төртеп яндыралар. Крестьяннарны тыярга тырышкан стражник коралсызландырыла. Совет власте урнашу белән, бай җирләре крестьяннарга бүлеп бирелә. 1927 елда Ямашев дигән агроном крестьяннарны әлеге урман буена күчеп утырырга өнди. Ике Шытсудан да теләгән кешеләр бай имениесе урынына йорт салалар, коммуна төзеп, яңа тормыш башлап җибәрәләр. Калатау ширкәтенең председателе



Юлбаттан Йосыф-Алан авылына күчеп утырып нигез салучы беренче кешеләр. Алдагы рәттә (уңнан) Әхмәтҗанов Габдрахман, Галләмов Ибрай, Фәсхетдинов Фәйзрахман һәм Юлбаттан кунакка килгән Хуҗин Гобәй



Йосыф-Алан авылындагы ударник колхозчы Газиз Галиевка хезмәт хакы һәм премиягә тигән ашлыкны кызыл олаулар белән китерү.1939 елның көзе



Калатау авылы ударниклары. Утырганнар (сулдан уңга) Зиннәтуллина Маһиҗамал, Хәлиуллина Сәрия, Корбанова Шәмсегөл, Гарифуллина Гакиһә. Артта басканнар: Зәбиуллина Фәридә, Минһаҗева Җәмилә, Хәлиуллина Мөнәвәрә, Метшина Хәят.
4 июнь, 1935 ел

Чугунов дигән кеше була. Ул ширкәткә лобогрейкалар, ургычлар, суыру машиналары кайтарта. Түбән Саурыш авылы янындагы дүрт ташлы су тегермәне ширкәт карамагына тапшырыла. Крестьяннар игенне бергә чәчәләр, уңышны җан башына тигез итеп бүләләр. 1932-1935 елларда калатаулылар колхозга кереп Югары Шытсу авылының бер бригадасы булып яшиләр. 1928 елда Юлбат авылыннан күчеп утырган крестьяннар да Калатау составына кертелә. Шушы ук елны Калатау белән янәшә Йосыф Аланы дип йөртелгән аланлыкка Тенеки авылы крестьяннары күчә. Алар үз пүчинкәләрен (пүчинкә – күчеп утырудан барлыкка килә башлаган торак пункт) Йосыф-Алан дип атыйлар. Шулай итеп, Юлбат, Шытсу авылларыннан күчеп утыручылар Калатау авылына, Теникидә күчүчеләр Йосыф-Алан авылына нигез сала.

Калатау, Йосыф-Алан авылларының ике колхоз булып яшәгән вакытлары да була. Аннары икедән бер “Магнит” колхозы төзелә. 1956 елда ул “Искра” колхозына берләшеп, аның өченче бригадасына әйләнә.

Калатау ширкәтенең беренче коммунарларының исемнәре дә билгеле: Кашаф Мөхетдинов, Галиәхмәт Муллануров, Әскәр Галимуллин, Фәйзетдин Фәттахов, Галим Зәйнуллин. (Бу материал беренче коммунар Галим Зәйнуллин сөйләгәннәрдән язып алынганнар буенча бирелде. – *Сафин И.Ф.*)

## *Ватан өчен, Туган җир өчен!*

Юлбат авыл Советыннан сугышка барлыгы 289 ир-егет сугышка китә.

Юлбат авылыннан 120 кеше китә: 80е һәлак була, 40ы төрле тән җәрәхәтләре белән кайта.

Тенекидән 112 кеше китә: 78е һәлак була, 32се төрле тән җәрәхәтләре белән кире кайта.

Йосыф-Аланнан 37 кеше китә: 25е һәлак була, 12се төрле тән җәрәхәтләре алып исән кайта.

Калатау авылыннан 20 кеше китә: 9ы һәлак була, 11е төрле тән җәрәхәтләре белән кайта.

**Юлбат авылы буенча сугышта һәлак булучылар**
**1983 елда җыелган мәгълүматлар**

| № | Исем, фамилиясе | Шулардан егетләр |
|---|---|---|
| 1. | Исламов Госман | |
| 2. | Төхбәтов | егет |
| 3. | Якупов Фәйзерахман | егет |
| 4. | Сәхапов Ногман | |
| 5. | Рәхимуллин Ибәтулла | |
| 6. | Тимерханов Сабирҗан | |
| 7. | Зәйнуллин Гыйззетдин | |
| 8. | Минһаҗев Сәйфетдин | егет |

| | | |
|---|---|---|
| 9. | Сәләхетдинов Кәрим | |
| 10. | Биктаһиров Галим | |
| 11. | Шәмсетдинов Шакирҗан | |
| 12. | Хәлилов Тимер | егет |
| 13. | Гәрәев Вәли | |
| 14. | Вәлиуллин Заһи | егет |
| 15. | Вәлиуллин Гаяз | егет |
| 16. | Рәкыйпов Гайнулла | егет |
| 17. | Нәбиуллин Кәримулла | егет |
| 18. | Гатауллин Әсхи | |
| 19. | Рәхимуллин Төхбәтулла | |
| 20. | Мәрдәнов Габдрахман | |
| 21. | Баязитов Миңлегали | егет |
| 22. | Фәләхиев Ширияздан | егет |
| 23. | Гыйниятов Нури | егет |
| 24. | Красильников Михаил | егет |
| 25. | Галәвиев Мәннән | |
| 26. | Шәймәрданов Әлмөхәммәт | егет |
| 27. | Бариев Габделбәр | егет |
| 28. | Гомәров Шәмси | |
| 29. | Хәлилов Вәли | егет |
| 30. | Шәйхетдинов Хәмит | |
| 31. | Зиятдинов Фәһметдин | егет |
| 32. | Гарипов Фатыйх | |
| 33. | Садыйков Нәҗип | егет |
| 34. | Сәләхов Гыйльметдин | |
| 35. | Төхбәтов Рәхмәтулла | |
| 36. | Зиятдинов Әхтәм | |
| 37. | Нәҗметдинов Шәйхетдин | егет |
| 38. | Әхмәтҗанов Закирҗан | |
| 39. | Тимергалиев Миңнегали | егет |
| 40. | Низамиев Барый | егет |

| | | |
|---|---|---|
| 41. | Төхбәтов Котдус | егет |
| 42. | Таһиров Галимҗан | |
| 43. | Тимерханов Вәлиулла | |
| 44. | Фәйзриев Фәйзерахман | егет |
| 45. | Ишмиев Сәетгәрәй | егет |
| 46. | Шәйхетдинов Баһау | |
| 47. | Шәйдуллин Зиннәт | егет |
| 48. | Хәйруллин Вәлиулла | |
| 49. | Минһаҗев Гани | |
| 50. | Гомәров Гаффар | |
| 51. | Хаҗиев Таҗи | |
| 52. | Галләмов Кыям | |
| 53. | Вәлиуллин Касыйм | егет |
| 54. | Рәкыйпов Гайфулла | егет |
| 55. | Мөхәммәтҗанов Һади | |
| 56. | Исламов Тимерхуҗа | |
| 57. | Дәүләтшин Гани | |
| 58. | Гайнетдинов Шәрип | |
| 59. | Сәләхов Гыйззетдин | |
| 60. | Мотыйков Мәҗит | |
| 61. | Мөхәммәтҗанов Фәесхан | |
| 62. | Гайнетдинов Хәйри | егет |
| 63. | Хуҗин Хаҗи | |
| 64. | Сафин Муса | |
| 65. | Зиннәтуллин Вәли | егет |
| 66. | Һадиев Вәли | егет |
| 67. | Галләмов Рәхи | |
| 68. | Мөхәммәтгалиев Газизҗан | егет |
| 69. | Гарипов Кәшиф | егет |
| 70. | Баһманов Фоат | егет |
| | | |

**Юлбат авылы буенча сугыштан исән кайтканнар**

| № | Исем, фамилиясе | Шулардан егетләр | Үлгән еллары |
|---|---|---|---|
| 1 | Шәмсетдинов Камалетдин | егет | |
| 2 | Шәйдуллин Галимулла | | 1968 |
| 3 | Шәйхетдинов Шәмсетдин | | 1978 |
| 4 | Хаҗиев Хуҗаәхмәт | | 1994 |
| 5 | Сәләхов Ясәви | егет | 1992 |
| 6 | Галләмов Мансур | | 1980 |
| 7 | Рәхимуллин Гарифулла | егет | |
| 8 | Хаҗиев Миңлебай | егет | 1988 |
| 9 | Мәрдәнов Фәйзерахман | | 1984 |
| 10 | Гыйззәтуллин Гыйният | | |
| 11 | Рәхимуллин Гатаулла | | 1993 |
| 12 | Фәләхов Вагыйзь | егет | 1990 |
| 13 | Сафин Фатхулла | егет | 1972 |
| 14 | Гайфуллин Билал | | 1995 |
| 15 | Мифтахов Садри | | 1987 |
| 16 | Дәүләшин Мансур | | |
| 17 | Таһиров Сабир | | 1970 |
| 18 | Таһиров Мөбәрәкҗан | егет | 1965 |
| 19 | Галләметдинов Низами | | |
| 20 | Сафиуллин Габделхай | | |
| 21 | Сәләхетдинов Ибраһим | | 1984 |
| 22 | Гайфуллин Баһман | | |
| 23 | Абдуллин Гыйният | егет | 1994 |
| 24 | Фазлыев Сәетәхмәт | егет | 1978 |
| 25 | Галиев Тимергали | | 1979 |
| 26 | Сафин Насыйбулла | | 1984 |
| 27 | Гайнетдинов Мәүлә | | 1984 |
| 28 | Хуҗин Фәтхри | | 1982 |
| 29 | Рәхмәтуллин Нотфулла | | 1972 |
| 30 | Исламов Ихсан | | 1992 |
| 31 | Мөбәрәкшин Дәүли | | 1989 |
| 32 | Шәмсетдинов Заһри | | 1982 |
| 33 | Зәйнуллин Гобәй | егет | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 34 | Кәбиров Кашафетдин | егет | |
| 35 | Галәветдинов Галләм | | |
| 36 | Мөбәрәкшин Хәмит | | |
| 37 | Шәмсетдинов Фәрви | | |
| 38 | Хәлиуллин Хәмәт | | |
| 39 | Гыйләҗетдинов Габделхай | | 1993 |
| 40 | Мөхәммәтҗанов Мәүлетҗан | | |
| 41 | Фәтхуллин Габдрәүф | | 1989 |
| 42 | Сәләхов Сәет | егет | |
| 43 | Шәвәлиев Галиәсгар | | 1987 |
| 44 | Һадиев Хәсән | егет | |
| 45 | Хәлилов Галиәхмәт | егет | |
| 46 | Ракова Саҗидә | кыз | |
| 47 | Фәрхуллин Фәрхетдин | | 1957 |
| 48 | Хуҗин Зиннур | | 1959 |
| 49 | Нигъмәтҗанов Мөбәрәкҗан | | 1949 |
| 50 | Низамиев Газиз | егет | 1990 |

Шулай итеп, сугыштан 50 кеше исән кайта (ягъни 32 ир, 17 егет, 1 кыз).
1984 елның 30 ноябрендә 25 фронтовик исән була.
“Иптәш Фәләхов В. белән барлап чыктык”, – дип язган Саҗидә апа Ракова.

**Юлбат авылы сугыш ветераннары**



Нуриева (Галимҗанова) Камәрия



Сафин Фәтхулла



Нигъмәтҗанов Мөбәрәкҗан


Хәлиуллин Хәммәт


Ракова Сажидә


Мөхәммәтҗанов Мәүлетҗан



Мөбәрәкшин Дәүли


Хаҗиев Миңлебай


Шәмсетдинов Фәрветдин


Исламов Ихсан


Кәбиров
Кашафетдин


Шәвәлиев
Галиәскәр



Нотфуллин Мөхипулла



Абдуллин Гыйният



Гайфуллин Баһман




Гайфуллин Билалетдин



Гыйлаҗетдинов Габделхай



Зәйнуллин Гобәйдулла



Мәрдәнов Фәйзрахман



Низамиев Газиз



Рәхимуллин Гатаулла



Сәләхов Ясәветдин



Һадиев Хәсән



Фәтхуллин Габдрәүф



Шәмсетдинов Камалетдин




Сәләхов Сәет



Галиев Тимергали



Биктаһиров Мөбәрәкҗан



Гайнетдинов Мәүлә



Шакирҗанов Гайфетдин


Сафиуллин Хәй


Хуҗин Фатхрахман

**Тенеки авылыннан сугышта һәлак булучылар**

| № | Исем фамилиясе | Туган елы |
|---|---|---|
| 1. | Арсланов Мирзаәхмәт Арсланович | 1911 |
| 2. | Баһавиев Шәехзадә Баһавиевич | 1924 |
| 3. | Батталов Нурияздан Батталович | 1919 |
| 4. | Батыршин Мөбарәкҗан Батыршович | 1900 |
| 5. | Вәлиев Гыйлемхан Вәлиевич | 1925 |
| 6. | Галиев Зәки Галиевич | 1908 |
| 7. | Вәлиев Хәлим Вәлиевич | 1914 |
| 8. | Галиев Галимулла Галиевич | 1914 |
| 9. | ГаләветдиновФәйзерахман Галәветдинович | 1915 |
| 10. | ГаләветдиновХәбибрахман Галәветдинович | 1906 |
| 11. | Галимуллин Хөснетдин Галимуллович | 1919 |
| 12. | ГалиевГабдерахман Галиевич | 1904 |
| 13. | Галиев Биктимер Галиевич | 1913 |
| 14. | Галиев Муллаян Галиевич | 1923 |
| 15. | Дәүләтшин Гаделша Дәүләтшинович | 1907 |
| 16. | Җәләлиев Кәшиф Җәләлиевич | 1914 |
| 17. | Җәләлиев Зәкәрия Җәләлиевич | 1909 |
| 18. | Ибраһимов Гали Ибраһимович | |
| 19. | Гафуров Габдерахман Гафурович | 1909 |
| 20. | Галиев Вәли Галиевич | 1906 |
| 21. | Галиев Харис Галиевич | 1911 |
| 22. | Мөбәрәкшин Габдерахман Мөбәрәкшин | 1896 |
| 23. | Нургалиев Вафи Нургалиевич | 1920 |
| 24. | Сәйфиев Гыймай Сәйфиевич | 1909 |
| 25. | Сабитов Сәгыйть Сабитович | 1905 |

| | | |
|---|---|---|
| 26. | Шәмсетдинов Котдус Шәмсетдинович | 1912 |
| 27. | ШакирҗановМуллагаян Шакирҗанович | 1911 |
| 28. | Шәңгәрәев Сөнгәтулла Шәңгәрәевич | 1909 |
| 29. | Хуҗин Миңнемулла Хуҗиевич | 1919 |
| 30. | Хәннанов Сабур Хәннанович | 1914 |
| 31. | Хәннанов Латыйп Хәннанович | 1920 |
| 32. | Хуҗин Нуриәхмәт Хуҗинович | 1919 |
| 33. | Хәйретдинов Кави Хәйретдинович | 1915 |
| 34. | Хисамиев Галиәхмәт Хисамиевич | 1919 |
| 35. | Вәлиев Бари Вәлиевич | 1909 |
| 36. | Җиһаншин Җиһан Җиһаншович | 1909 |
| 37. | Гатауллин Гариф Гатауллович | 1912 |
| 38. | Мәкъсутов Хәсәнша Мәкъсутович | 1909 |
| 39. | Ибраһимов Мөхәммәт Ибраһимович | 1906 |
| 40. | Ибраһимов Тимергали Ибраһимович | 1906 |
| 41. | Кәримов Заһит Кәримович | 1911 |
| 42. | Кәримов Җиһангир Кәримович | 1923 |
| 43. | Лотфуллин Гәрәй Лотфуллович | 1921 |
| 44. | Мөбәрәкҗанов Хәсәнҗан Мөбәрәкҗанович | 1914 |
| 45. | Мөбәрәкшин Кәшиф Мөбәрәкшинович | 1906 |
| 46. | Мияссәров Мулланур Мияссәрович | 1926 |
| 47. | Мөбәрәкҗанов Низам Мөбәрәкҗанович | 1916 |
| 48. | Мифтахов Габдерәхим Мифтахович | 1912 |
| 49. | Мифтахов Вәли Мифтахович | 1906 |
| 50. | Ногманов Хәмит Ногманович | 1919 |
| 51. | Нәбибуллин Нурулла Нәбибуллович | 1924 |
| 52. | Нуриев Гыйльмулла Нуриевич | 1923 |
| 53. | Нотфуллин Абдулла Нотфуллович | 1914 |
| 54. | Сабиров Габдулла Сабирович | 1923 |
| 55. | Сиражиев Миңнеәхмәт Сиражиевич | 1914 |
| 56. | Сафин Иван Сафинович | |
| 57. | Сиражиев Хөснетдин Сиражиевич | 1919 |
| 58. | Сафин Мөбәрәкҗан Сафинович | |
| 59. | Сафин Сәлимгәрәй Сафинович | 1910 |
| 60. | Сәфәров Ягъфәр Сәфәрович | 1902 |
| 61. | Сиражиев Фатыйх Сиражиевич | 1904 |
| 62. | Саттаров Хәниф Саттарович | 1901 |
| 63. | Тимербаев Хәлим Тимербаевич | 1908 |
| 64. | Фәләхиев Нәҗип Фәләхиевич | 1908 |

| | | |
|---|---|---|
| 65. | Фәләхиев Хәниф Фәләхиевич | 1911 |
| 66. | Абдуллин Шәмсемөхәммәт Абдуллович | 1905 |
| 67. | Вәгыйзов Нуриәхмәт Вәгыйзович | 1923 |
| 68. | Лотфуллин Габдулла Лотфуллович | 1919 |
| 69. | Тимерханов Мөхәммәтхан Тимерханович | 1922 |
| 70. | Хәкимов Габдеразак Хәкимович | 1920 |
| 71. | Арсланов Габделфәрт Арсланович | 1909 |
| 72. | Фәләхиев Тәхәветдин Фәләхиевич | 1913 |
| 73. | Шәмсетдинов Закуан Шәмсетдинович | 1909 |
| 74. | Шәрәфетдинов Сабир Шәрәфетдинович | |
| 75. | Баһавиев Зыя Баһавиевич | 1919 |
| 76. | Габделхаков Габделхәлим Габделхакович | 1919 |
| 77. | Газизов Вәли Газизович | 1909 |
| 78. | Вәлиев Мирзахан Вәлиевич | 1920 |

**Теники авылы сугыш ветераннары**



Батталов Мирсәет



Габдрахманов Афзал



Гайфиев Фахразый



Галиев Галимҗан



Галимҗанов Хәким



Ганиев Хәбибрахман



Нурмөхәммәтов Әсхәдулла




Мөбәрәкшин Юныс



Сибгатуллин Зиннәтулла



Баһавиев Ислам




Әфганстанда һәлак булган Илгизәр Харисовка багышланган стенд



Сугыш ветераннары митингтан соң. 1983 ел, 9 Май




9 Май, митинг. Арткы планда иске клуб күренә




Сугышта һәлак булучылар
истәлегенә 1967 елда куелган
беренче обелиск



Сугышта һәлак булучылар
истәлегенә куелган обелиск 1987
елда ясалган реконструкциядән соң

# *Сугыш чоры авылы*

Хаҗиева Рәшидә Хаҗиәхмәт кызы – сугыш елларын кичкән миллионлаган тыл хезмәтчәннәреннән берсе. Сугыш елларында көндәлек язып бара. Ул көндәлектән сугыш чоры авылы тормышын чагылдырган өзекләрне үзгәртмичә тәкъдим итәбез.

1941 ел, 23 июнь. Һадиев Барый, Таһиров Галим сугышка киттеләр.

1941 ел, 25 июнь. Кич 3 сәгатьтә Хаҗиев Миңлебай абыем китте.

1941 ел. 26 июнь. Рәхимуллин Гатау, Гыйләҗиев Хәй, Сабиров Хәсән, Шәйхетдинов Хәмит киттеләр.

Таҗи абыйны 25 июньдә, сугышка китәргә менгәндә, МТС директоры сөйләшеп алып калды.


3 июль. Газиз китте. 1941 ел, 3 июль. Ип. Сталин радио буенча халыкка мөрәҗәгать белән чыкты. Ип. Сталин – Дәүләт Оборона Комитеты председателе.

1941 ел, 9 июль. Миңлебай абыйның Ленинградтан исәнлеген әйтеп хаты килде.

1941 ел, 13 июль. Сәләхов Гыйльми, Исламов Госман, ... Шәрифләргә кичтән хәбәр булды, иртән киттеләр. 22 июньдә башланган сугыш әлегә кадәр дәвам итә.

6 ноябрьдә сугышның барышы турында ип. Сталин доклад сөйләде.

18 апрель, 1942 ел. Байми абыем самолет белән Москвага кайтты. Ташкенттан.



Сугыш елларында укытучы Хаҗиева Рәшидә алып барган көндәлек

29 апрель, 1942 ел. Кич сәгать 11.30 минутта разведкада вакытта (Мурманск) Миңлебай абыйның сул аягын тездән түбән пуля тишеп чыккан. Госпитальдә.

6 май, 42 ел. Бу сугышта 4 абыем да катнашты.

Хуҗа абый – кызылармеец.

Байми – майор, Таҗи – кызылармеец, Миңлебай абый – кызылармеец, "Медаль за отвагу". Хәзергә хатлары килә.

Тормыш авыр, икмәк юк, шулай булса да, сугыш вакыты булгач, түзәргә туры килә. Он 2400 сум, бәрәңге 400-600, май 160-170 сум.

22 июнь, 1943 ел. Германия белән башланган сугышка иртәнге 4 сәгатьтә 2 ел тулды.

19 октябрь, 1943 ел. Халыкның тормышы чиктән тыш авыр. Он, ипи күргәннәре юк. Күп кешенең алабута, бәрәңгесе дә юк. Түләүләр бик күп.

Кызыл Армия уңышлы рәвештә алга бара.

2 февраль, 1944 ел. Сугышлар Кызыл Армиянең җиңүе белән алга бара. Ленинград фронты гаскәрләре көн саен алга баралар. Петергоф, Гатчина, Красное село, Пушкино шәһәрләрен алдылар, 70-100 км алга киттеләр.

25 февраль, 1944 ел. 3 сәгать 5 минутта төнлә газиз анам вафат булды. Җомга көн Мәүлет аеның икенче көнендә көндез сәгать 12дә гүр иясе булды. Аюдай 4 малай үстереп, берсен дә күрә алмады. Миңлебаем, дип өзелеп-өзелеп әйтте. Кайтса, түшәкне җәеп, әтиең белән икебезнең арага яткырып, сөеп, иснәп ятар идем, диде. Их, булмады шул...

1945 ел, 1 август. Кич сәгать 7дә Хуҗа абый белән Байми абый кайтты. Юлда – пароходта очрашканнар.

## Низамиев Газиз абый истәлекләре



Низамиев Газиз

Ул 1923 елда Юлбат авылында туа.

1942 елның августында колхозда хисапчы булып эшләп йөргән егет Ватан азатлыгы өчен көрәшчеләр сафына баса. Висла һәм Одер елгаларын кичкәндә күрсәткән каһарманлыгы өчен "Батырлык өчен" медале, Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә. "Варшаваны азат иткән өчен", "Берлинны алган өчен", "1941-1945 елларда Германияне җиңгән өчен" медальләре дә – утлы еллар истәлеге.

Газиз абый заманы өчен белемле кеше була. Фронттан кайту белән Юлбат авыл Советы секретаре, аннан – рәис, 1949-1954 елларда халык депутатларының район Советы башкарма комитетында социаль тәэминат бүлеге мөдире вазифаларын башкара. 1954 елдан "Ирек" колхозы рәисе, 1962 елдан Шекше авыл Советы башкарма комитеты рәисе итеп сайлана. 1967-1970 елларда Сатыш сельпосына җитәкчелек итә. Аннан соң, лаеклы ялга чыкканчы, район хәрби комиссариатында финанс-хуҗалык бүлеге начальнигы вазифасын үти.

Газиз абый белән Рәкыя апа дүрт ул тәрбияләп үстерәләр.

Олы уллары Фәрит озак еллар Казан радиоаппаратуралар ремонтлау заводының генераль директоры булып эшли. Хәзерге вакытта Америкада яши. Икенче улы Равил гомерен хәрби хезмәткә багышлый. Полковник дәрәҗәсендә отставкага чыга. (Аның турында тулырак китапның “Хәрбиләр” бүлегендә язылды.) Өченче уллары Рафаэль “Сабагаз” идарәсендә эшли, кече уллары Рамил – Теләче районының баш архитекторы. Аның турында шулай ук китапта мәгълүмат бирелде.

Сугыш ветераны Низамиев Газиз сугыш чоры истәлекләрен җыеп, теркәп барган, кайберләрен район газетасы битләрендә бастырган. Ул истәлекләр, мәктәптә музей ачылгач, музейга тапшырылып, шунда сакланды. Хәзер әлеге истәлекләрне тәкъдим итәбез.

“Совет халкының фашизмны җиңүенең 35 еллыгына карата хәтердә калганнардан кайбер истәлекләр”, – дип яза ветеран.

1941 ел. Ватан сугышының беренче елы.

Ватан сугышында җиңү өчен авыл хуҗалыгының роле зур булды, чөнки икмәктән башка армия сугыша һәм җиңә алмаячак. Партия Ватаныбызның куркыныч астында булуын белдереп, көннең төп лозунгысын куйды: ”Барысы да фронт өчен, барысы да җиңү өчен!” Сугыш нәтиҗәсендә колхозда авыл хуҗалыгы эшләрен алып бару зур кыенлыкларга очрады. Җир эшкәртү өчен тракторлар юк диярлек, булган тракторларга ягулык бирү һәм ватык тракторларны ремонтлау өчен запас частьлар кайтару кимеде. Барлык кыр эшләре диярлек ат һәм кул көченә калды.

Аяусыз фашист басып алучылары, Советлар Союзының икмәксез калуына исәп тотып, сугышны урып-җыю алдыннан башладылар. Колхозның бик күп ир-егетләре сугышка алынгач, эшче көчләр азайды. 1941 елда игеннәр бик уңган иде. Совет һәм колхоз җитәкчеләренең төп бурычы – бөтен көчне булган уңышны югалтусыз җыеп алуга туплау булды. Колхозчылар белән җыелышлар үткәрелде, булган кыенлыклар һәм алда торган бурычлар аңлатылды.

Партия оешмасы, авыл Советы һәм колхоз идарәсе урып-җыю эшенә эш яшеннән чыккан карт-карчыкларны һәм яшүсмерләрне тарту буенча зур эш алып барды. Нәтиҗәдә сәламәтлекләре булган барлык өлкәннәр урып-җыю эшендә катнаштылар. Күпчелек колхозчылар эш нормаларын 120-150%ка үтәп бардылар. Урып-җыю эшләре башлану белән, дәүләткә икмәк тапшыру буенча задание җиткерелде. Көндәлек график җиткерелеп, аның үтәлүен райком һәм райисполком даими контрольдә тотты. Һәр көнне, пар атка 8 ц икмәк төяп, олаулар Шәмәрдән заготзерносына барып торды. Колхоз икмәк тапшыру планын тулысынча үтәп чыкты.

Булган игеннәр, лобогрейкалар (атлы уру машинасы) һәм кул белән урылып, көлтәләргә бәйләнде һәм кибәннәргә куелды. Ашлык гади сугу машиналарында суктырылды. Дәүләткә тапшырасы ашлыкны гади сушилкаларда киптереп өлгермәгәнлектән, колхозчылар өй мичләрендә киптереп тапшырдылар. Шулай итеп, 1941 елның уңган игеннәре колхозчыларның зур тырышлыгы белән җыеп алынды.

1942 елның язгы чәчүе уңышлы үткәрелде. Эшнең барышы һәм аерым колхозчыларның тырыш хезмәте колхоз стена газетасында һәм район газетасында яктыртып барылды.

Колхозчылар үзләренең фидакарь хезмәтләре белән немец-фашистларны җиңеп чыгуда зур өлеш керттеләр.

Шул уңайдан "Колхоз байрагы" газетасында басылган (1941 ел) мәкаләмне китереп үтәм:

**Заһидулла бабай**

Ворошилов исемендәге колхозда Заһидулла бабайдан да карт кеше юк. Ул тугызынчы дистәгә аяк баскан инде. Шулай да бабай җегәрле әле. Азатлыгыбызга кара дошман һөҗүм ясагач, аның йөрәге түзмәде: "Әле миндә шактый көч бар, ул илебезнең көченә кушылсын, мин дә колхозда тырышып эшлим әле", дип, җиңнәрен сызганып эшкә тотынды. Заһидулла бабай борчак чабуда күп кенә яшьләрне көнләштерә алды. Бездә көнлек чабу нормасы 0,40 гектар. Ә бабайның чалгысы көн саен ярты гектарны ялап кына бара. Ул чапкан җирдә чалгыга эләкми калган бер салам, җирдә калган бер борчак күрмәссең.

1941 елның октябрендә Кызыл Армия сугышчыларына җылы киемнәр җыйнау башланды. Колхозчылар һәм башка гражданнарга аңлату һәм җылы киемнәр җыйнауны оештыру өчен районда һәм авылларда махсус комиссияләр оештырылды. Бу комиссияләр, кыска гына вакыт эчендә шактый күләмдә җылы киемнәр җыйнап, район хәрби складына тапшырдылар.

Бу эшнең әһәмияте хакында аңлату эшләре алып барылды. Эшнең барышы стена газеталарында һәм район газетасында яктыртылды.

Менә бу эшнең барышын күрсәтеп, минем имза белән 1941 елда район газетасында басылган мәкалә:

**Сүз эштән аерылмый**

Юлбат авыл Советында сугышчыларга җылы киемнәр хәзерләү буенча оештырылган комиссия яхшы эшли. Җылы киемнәр хәзерләүнең әһәмияте турында системалы рәвештә аңлату эшләре алып барылды. Гомуми җыелышта колхозчылар әйберләр хәзерләргә сүз биргәннәр иде, комиссия икенче көнне үк бу сүзләрне практик эш белән раслау өчен көрәшә башлады.

Колхозчылар кызыл сугышчылар өчен инде күп кенә әйберләр тапшырдылар. Маһирә Галиева 3 баш сарык тиресе һәм бияләй белән оекбаш, Газәмбану Фатыйхова 2 баш сарык тиресе китереп бирделәр. Аларның икесенең дә иптәшләре Ватан сугышында.

Район хәрби складына 57 баш тире, 20 килограмм йон, 280 сум акча, 4 килограмм мамык һәм башка күп кенә әйберләр тапшырылган иде. Аннан соң да күп кенә әйберләр җыйналды.

Газиз абый истәлекләрен укыгач, сугыш елларында, нинди генә кампания җәелдерелсә дә, аңлату эшләре алып барылган, шунлыктан бөтен халык аңлы

рәвештә дошманны җиңү өчен бердәм көрәшкән, дигән фикер кала. Шул чорны күзаллау өчен Газиз абыйның истәлекләрен, газетада басылган мәкаләләрен тулысынча һәм үзгәртмичә китердек. Ул чор кешеләренең һәр сүзе, һәр истәлеге киләчәктә алтын бөртегенә тиң булыр әле.

## Сугыш чоры турында балалар яза



Ракова Саҗидә Мирза кызы

Мәктәп музеена туган як тарихы турында материаллар туплауда укучылар күп көч куйды. Һәр елны, Җиңү бәйрәме якынлашкан көннәрдә, алар аеруча зур активлык белән истәлекләр туплfavourable. Сугыш ветераннары белән очрашып, хатирәләрен язып алып, алар искиткеч әһәмиятле хезмәт башкардылар, чөнки бүгенге көндә сугышны үз күзләре белән күргән сугыш ветераны җирлектәге дүрт авылның берсендә генә дә исән түгел инде. Ә укучылар туплаган материал сугыш чорын, тылдагы хезмәтне күзалларга, ул елларда яшәгән кешеләрнең фидакарьлеген аңларга ярдәм итә. Укучыларыбызның хезмәтен алар язганча, үзгәртмичә китапка кертмәсәк, беренчедән, аларның хезмәтен бәяләмәү кебек килеп чыгар, дип уйладык. Икенчедән, укучылар эзләнү материалларын сугыш һәм тыл ветераннары белән әңгәмә тәэсирендә язып биргәннәр бит, шунлыктан ул материалларда сугыш чоры рухы тулырак чагыладыр кебек тоелды.

Иң беренче итеп сугыш ветераны Саҗидә апа Ракованың мәктәп музеена үзе язып биргән хатын тәкъдим итәбез.

*Кадерле укучылар!*

*Сугыш башланган һәм сугыш беткәнгә инде күп еллар үтте. Ләкин ул шомлы еллар сугыш чоры авырлыгын күргән һәркемнең йөрәгендә тирән җәрәхәт кебек саклана. Ул еллар искә төшсә, иң башта әтиләре сугышка киткәч ятим калган, моңсу күз карашлы укучыларым күз алдына килә. Ул елларны искә алу авыр миңа.*

*Сез миннән шул чор турында һәм кайда хезмәт итүемне сорыйсыз.*

*Сугыш башланган көн – минем Свердловскига (хәзерге Екатеринбург) җәйге ялымны уздырырга, әнием янына ял итәргә барган бәхетле көннәремнең берсе иде. Сугыш башлану аркасында иң беренче бу шатлыклы ялдан мәхрүм булдым. Миңа тизрәк эш урыныма кайту кирәк, сугыш чоры тәртибе шулай. (Ул чакта мин Олы Мәтәскә җидееллык мәктәбендә укыта идем.) Мин кайтуга укытучы иптәшләрем белән колхоз эшенә чыга башладым. Авылда да шәһәрдәге кебек көн саен диярлек ирләрне, егетләрне сугышка озату дәвам итте. Көзен бәрәңгене алып бетерүгә, кызларны окоп казырга, урман кисәргә җибәрә башладылар.*

*Сугыш башланып тугыз ай үткәндә, ягъни 1942 елның 12 апрелендә Теләче хәрби комиссариатыннан сугышка китәргә повестка алдым. 13 апрельдә район-*

*нан 30 кыз китеп тә бардык. Ул чакта һәр районнан урта белем белән утызар кызны Мәскәүне һава һөҗүменнән саклау оборонасына алдылар.*

*Мәскәүдән ерак түгел генә Терешкино дигән авылда прожекторчы булырга өйрәттеләр. Без килгәндә бу авыл тирәсе аша үтеп минадан чистартучылар (минерлар) йөри иде, дошман миналап киткән җирләр бар иде әле. Бу авылга 1941 елның көзендә бомба да төшкән. Ике этажлы мәктәпкә һәм без торасы өйнең күрше йортына бомба төшеп юк иткән иде. Урыннарында тирән чокырлар гына калган. Бу авылда 30 кыздан өчебез Теләче районыннан идек. Бераздан безне төрлебезне төрле җирләргә озаттылар. Мин бер полкның күчмә ротасында, бер взводның дүртенче позициясендә прожекторчылар белән хезмәт иттем. Прожекторчыларның бурычы – Мәскәүне һава һөҗүменнән саклау. Көндез дә, төнлә дә чиратлап телефонда, телефон линиясенең чыбыклары өзелсә, эзләп барып ялгап кайту, төз атарга өйрәнү, тревога булса, прожектор янында булу һ.б. эшләр.*

*Без торган урын Коломна шәһәре янына таба иде. Анда хәрби заводлар урнашканлыктан, аеруча нык саклаганнар. Бу шәһәргә немец бер бомба да төшерә алмаган.*

*Мәскәү оборонасы бик көчле иде. 1943 елда инде безнең юнәлештән дошманның бер самолетын да уздырмадылар. Еракка ата торган туплар безнең полкның горурлыгы иде.*

*Командирларыбыз солдатлар турында кайгырттылар. Ашау, ял итү, сирәк булса да кино карау һ.б. оештырылды. Без, төрле милләт кызлары, бик тату яшәдек, тату хезмәт иттек. Мине взводның комсомол секретаре урынбасары итеп сайлаганнар иде, шуңа күрә взвод командирлары җыелышына барырга да туры килде.*

*Сугышчылар авылдан хатлар алып торды. Миңа да үземнең укыткан авылым Мәтәскәдән хатлар килеп торды. Инде 18 яше тулар-тулмас егетләрнең дә сугышка алынуын, авылның ямансу калуын яздылар.*


*Укучылар! Ул чорда солдатлар да, авыл халкы да безнең Совет Армиясе дошманны җиңәчәгенә ышанды һәм, бөтен авырлыкка түзеп, җиңү хакына үзенең хезмәтен куйды. Инде андый авырлык, сугыш афәте күрергә язмасын.*

*Еллар имин булсын!*

*Сугыш ветераны Сажидә Ракова, 1992 ел, февраль.*

**Фронттан хат**

Әтисенең бабасы Бөек Ватан сугышыннан язган хатны музейга Йосыф-Алан авылыннан Каюмова Сөмбелә тапшырды. Өчпочмаклы солдат хаты гарәп хәрефләре белән язылган. Музейга тапшырганда ул кириллицага күчерелгән, кат-кат укудан таушалган, ләкин күз карасыдай сакланган икәнлеге сизелеп торган хат иде. Хатның иясе Гәрәев Каюм сугышның башында ук һәлак була. Гаиләсе аннан шушы бер хатны гына алып кала һәм аны 60 елдан артык иң кадерле ядкәр итеп саклый.




Фронттан хатның адреслы ягы

*Кадерлеләрем, сезгә сагынып хат язучы, хәер-догаларыгызны үтенеп калучы Каюмнан күп сәлам. Мәһисәрвәр иптәшем, сиңа, мин, иптәшең Каюмнан, бик сагынып сәлам. Шулай ук улым Харраска, улым Рәшиткә, улым Шамгунга һәм улым Тимурга, барча туганнарга, күршеләргә, шулай ук абыйларга, янә Саҗидә түтигә бик сагынып сәлам.*

*Сәлам соңында, үзем хәзергә исән-сау. Бу хатны 14 сентябрьдә яздым. Смоленскига якын, 120 километрда торабыз. Иртәгә моннан сәгать алтыда китәбез. Хәерле булсын. Сезне күрмәсәм, бәхил бул, Мәһисәрвәрем. Мин сезгә бер киңәш бирә алмыйм инде. Син бик картайма минем өчен. Картаеп, кайгырып кына мин кайта алмам. Балалар акыллы булсыннар инде, алар бәхетле булсалар, син дә рәхәт яшәрсең. Киткәннән соң мин хат салдым, аласызмы, юкмы – белмим. Өйдән чыкканнан бирле урманда кунып йөрибез. Бу хатка адрес язып булмый. Хат язарга кәгазь дә юк.*



Хатның авторы Гәрәев Каюм

*Хушыгыз, якыннарым. Бәхил булыгыз.*
*Күк йөзләре гөрләп тора*
*Каргалар уйнаганда.*
*Саргайды инде йөзләрем*
*Төрлесен уйлаганга.*
*Хушыгыз, бәхил булыгыз.*

*Гәрәев Каюм. 1941 ел, 14 сентябрь.*

**Кызыл Йолдызлы бабам**

Әтиемнең әтисе, ягъни бабам Фатхулла Әхмәтсафа улы Сафин 1924 елның 13 сентябрендә Саба районы Тенеки авылында дөньяга килә. 1942 елның сентябрендә, 18 яше тулуга ук, Бөек Ватан сугышына китә. Шул елның 19 октябрендә хәрби ант кабул итә. Берничә ай үткәч, минометчы-төзәүче хезмәтенә өйрәнгәннән соң, 1943 елның июль аеннан сугыш хәрәкәтләрендә катнаша башлый. Частьта иң яшь солдат булуга карамастан, аңа кече сержант дәрәҗәсе бирелә. Ул 531 нче артиллерия полкында 120 миллиметрлы минометның төзәүчесе вазифасын башкара, илебез шәһәрләрен, авылларын, Австрия, Венгрия һәм Европа кыйтгасының башка дәүләтләрен фашистлар коллыгыннан азат итүдә катнаша. Гитлерчыларны куып барганда Днепр, Висла, Одер елгаларын кичә. Башкомандующийның 1945 елгы 273 номерлы приказы нигезендә, Одер елгасын кичеп, Бреслау шәһәрен азат итүдә катнашканы өчен Мактау грамотасы белән бүләкләнә.

Ә гомумән, сугыштагы батырлыклары Кызыл Йолдыз ордены, “Сугышчан хезмәтләре өчен” һәм башка медальләр белән бәяләнә.

Бабаема кадәр әнисе Хәмдебикә 4 баласын сугышка озаткан була инде, төпчеге, Фатхулласы – бишенче булып сугышка киткән. Шулардан өчесе – Сафин Әсхәдулла, Камалиев Фәсхетдин, Камалиев Кыяметдинне – бер үк көнне алалар. Аларны озатканда ничек түзде икән ана йөрәге?! Хәмдебикә әби дүрт улын сугышта югалта, бары минем бабам Фатхуллага гына әйләнеп кайту насыйп була. Аның кайтуын анага әле сугыш тәмамлангач та озак көтәргә туры килә, чөнки бабаема армия хезмәтен дәвам итәргә кирәк була. Ниһаять, 1947 елда гына демобилизацияләнеп, туган авылына исән-имин әйләнеп кайта. Сугыштан соң ул туган колхозында эшли, Бөек Җиңүнең 20 еллыгы хөрмәтенә чыгарылган медаль белән бүләкләнә. Тормышында күп авырлыклар күрсә дә, бабаем яхшы күңелле, кешелекле булып кала алган. Әбием аны бик җылы хисләр белән искә ала иде. Аның сөйләве буен-




Сафин Фәтхулла

ча, бабам кешеләргә ихтирамлы, сабыр, тыйнак, хезмәт сөючән, шаян, уен-көлке яратучан булган. Ул үзенең улларын – әтием һәм Рафис абыйны, аеруча кызы Раилә апаны бик яраткан. Аларны авырлыктан, тормышның кырыс җилләреннән сакларга тырышкан.

Кызганычка каршы, 18 яшьтән сугышның алгы сызыгында булу эзсез үтмәгән. Ул балаларының үсеп килүенә куанып, дөнья яменә шатланып яшәр вакытында – 47 яшендә 1972 елда ук бу дөньядан китә. Аның турында авыл халкы, күршеләр, бигрәк тә әтием күңелендә якты истәлекләр генә яши.

Сафин Радик, оныгы, 14 апрель, 2000 ел.



НАГРАДНОЙ ЛИСТ.

306

1. Фамилия, имя и отчество Сафин Фаткула Насредович
2. Звание мл. сержант 3. Должность и часть наводчик миномета 531 Армейского минометного Запорожского полка

Представляется к награждению орденом Красной звезды.

4. Год рождения 1924 5. Национальность татарин. 6. Партийность ВКП(б) 1944
7. Участие в гражданской войне, последующих боевых действиях по защите СССР и Отечественной войне (где, когда) участник отечественной войны с 1942 ю.з.ф. III: I укр. фронт.
8. Имеет ли ранения и контузии в Отечественной войне не имеет
9. С какого времени в Красной Армии с августа 1942 10. Каким РВК призван Сабинским РВК Тат. ССР
11. Чем ранее награжден (за какие отличия) медаль "За б/заслуги" Приказ 531 АМЗП № 01/н от 25-02-44 г.
12. Постоянный домашний адрес представляемого к награждению и адрес его семьи. [redacted]

1. Краткое, конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг.

Работая наводчиком, т. Сафин проявил мужество и отвагу. 25-02 когда перешел в контратаку и вел обстрел огневых позиций, тов Сафин не обращая внимания на опасность для жизни точно и хладнокровно выполнял команды. В результате чего контратаки были отражены с большими для него потерями.

Минометом тов Сафина за день было уничтожено 2 стан. пулемета подавлен огонь минбатареи и уничтожено до 30 солдат пр-ка.

Тов Сафин знает свое дело, из минометных номеров подготовил 2 наводчика. Тов Сафин достоин правительственной награды — ордена "Красной звезды".

КОМАНДИР 531 АРМЕЙСКОГО МИНОМЕТНОГО ЗАПОРОЖСКОГО ПОЛКА

Подполковник (МЫШКОВ)

"4" марта 1945 года.

Наградной лист (Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләү кәгазе)

## Сафин Фатхулла

Сафин Фатхулла 1924 елның 13 сентябрендә Тенеки авылында туган. 18 яше тулуга, 1942 елның 5 октябрендә сугышка китә. 1947 елның 3 апреленә кадәр Кызыл Армия сафларында хезмәт итә. Кече сержант, 120 ммлы миномет төзәүчесе.

Бөек Ватан сугышында 3 нче Көньяк-көнбатыш, 1 нче Украина фронтлары составында катнаша. Днепр, Висла, Одер елгаларын кичә, Австрия, Венгрияне һәм Европаның башка илләрен фашизмнан азат итүдә катнаша. Бреслау шәһәре тирәсендә Одер елгасын кичкән өчен Башкомандующийның 11 февраль 1945 ел № 277 приказы нигезендә рәхмәт белдерелә. Күрсәткән батырлыклары өчен "За боевые заслуги" (1944 ел), "За отвагу" (1944 ел) медальләре, 1945 елның мартында "Кызыл Йолдыз" ордены белән бүләкләнә.

## Минем бабам

Минем бабаем Низамиев Габделгазиз Низами улы 1923 елның 10 июлендә Юлбат авылында дөньяга килә. 1942 елның августында, Ворошилов исемендәге колхозда хисапчы булып эшләгәндә, аны фронтка алалар. Бу вакытта Габделгазиз бабайга 19 яшь була. 1942 елның августыннан октябрьгә кадәр ул Мәскәү округының 336-Б укчы полкында кызылармияче булып хезмәт итә. Ә инде 1942 елның октябреннән декабрьгә кадәр Воронеж фронтында 175 нче танк бригадасында фашистларга каршы көрәшә. Шушы вакытта, бик көчле контузия алып, яралана. Аның туган йортына: "Улыгыз 1942 елның 16 нчы декабрендә Воронеж өлкәсенең Филоново авылы янында батырларча һәлак булып күмелде,"– дигән хәбәр килә. Ләкин Габделгазиз бабай исән кала. Ул 1943 елның октябренә кадәр Башкортстанның Уфа шәһәрендә 3887 нче номерлы госпиталендә дәвалана. 1943 елның октябреннән сугыш беткәнчегә кадәр I Белорусия фронтының Харьков хәрби округында фронтның алгы сызыгында сугыша. Берлинны алуда булган каты бәрелешләрдә катнаша. Бик күп сандагы медальләр һәм Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.

*Низамиева Гөлнара (оныгы)*

## Хәтердәге төеннәр

Әниемнең әтисе Шакирҗанов Гайфетдин 1927 елда туа, 12 яшьлек малай, ат җигеп, кыр эшенә йөри. Ә 1944 елның 29 ноябрендә хәрби хезмәткә алына. 1945 елның июленә кадәр запастагы 57 нче полкта, ә аннан 415 нче МВД полкында стрелок булып хезмәт итә. 1945 елның 9 маенда җиңү яуланса да, әле туган илебез явыз көчләрдән арынып бетмәгән була. Бабам сөйләве буенча, алар Грозный тирәсендә, Эльбрус, Казбек таулары арасына яшеренгән бандитларны



Шакирҗанов Гайфетдин

күзәткәннәр, кулга алганнар һәм частька алып кайтып тапшырганнар. Андагы авырлыкларны Гайфетдин бабам еш искә ала иде. Кышкы зәмһәрир суыкларда карлы тауда төннәр буе ятып, ике аягын да өшетә. Ләкин илне ярату, аңа тугры хезмәт итү тойгысы көчлерәк була. 1945 елда “За победу над Германией”, 1948 елда “30 лет Советской Армии и Флота” медальләре белән бүләкләнә. Бабамның хәрби хезмәте җиде елга сузыла.

*Галимуллин Рушан (оныгы).*

**Утны-суны кичкән бабам**



Фәләхов Вагыйзь

Сугыш.... Планетабызда һәр кешене “дер” селкеткән иң куркыныч сүз бу. Кемнәрнең генә үзәген өзмәгән дә, тормышын җимермәгән бу каһәр суккан афәт. Әгәр уйлап карасаң, шушы афәт тәрәзәсен чиртмәгән, ишеген какмаган бер генә гаилә дә юк бит. Миллионлаган кешеләрнең яшьлек елларын, балалык чорын, пар канатлы булып, тигез гаиләдә яшәүне урлаган бу кара еллар...

Минем бабам Фәләхов Вагыйзь Фәләхетдин улы сугыш ветераны булган. Бабам 1923 елның август аенда Юлбат авылында туган. 7 нче сыйныфны тәмамлагач, Казанга укырга киткән. Укып чыккач, хәрби заводта 1942 елга кадәр эшләгән. Шушы елның башында үзе теләп фронтка киткән. Аның сугышчан юлы төньяк фронттан башланган. Бабаем миномётчы булган. Гитлерчылар белән бәрелештә дүрт тапкыр авыр җәрәхәтләнеп, госпитальдә (кыр лазаретында) дәваланган. Яралары төзәлгәч, ул яңадан сугышка кергән. Бер бәрелештә аңын югалтып егылган хәлдә, аны яшь кенә шәфкать туташы, плащ-палаткага салып, лазаретка кадәр өстерәп кайткан. Сугышның төрле авырлыкларын җиңеп, сугыш тәмамланганнан соң, бабаем 1945 елның сентябрь аенда туган авылы Юлбатка кайта. Ләкин 1941 елның башында ук киткән Ширияздан абыйсы кайта алмый, хәбәрсез югала…

Мин әбиемнән бабам белән кайчан танышканлыкларын сорыйм. “Мине 1948 елда Мәгариф бүлеге приказы белән Юлбатка укытучы итеп җибәрделәр, – дип искә ала әбием. – Авыл Советы бинасына кердем. Өстәл артында маңгай чәчләре сирәкләнгән бер ир-ат утыра. Мин кергәч, зур кара күзләре белән күтәрелеп карады. Исәнләштек. Мин приказны бирдем. Ул: “Яхшы, бергәләп эшләрбез”, – диде. Аннары укытучы яшәгән йортка киттек. Анда күп еллар Юлбат башлангыч мәктәбендә белем биргән укытучы Газизә апа яши иде. Ул: “Авыл Советына кердеңме? Кеше бар идеме?” – ди. Мин әйтәм: “Бер ир кеше утыра иде, авыл Советы секретаре икән”. Газизә апа көлеп куйды: “Ир кеше түгел әле ул, ә утны-суны кичкән егет кеше. Чамала, чибәр кызларны ярата. Үзеңә дә күзе төшеп куяр әле”, – диде. Аның юраганы фәрештәләрнең “Амин” дигән сәгатенә туры килде. Ике ел сөйләшеп йөргәч, өйләнешеп тә куйдык.

Бабаеңны 1946 елда җирле Советларга сайлауда депутат итеп сайладылар. Сайланган депутатлар арасыннан Юлбат авыл Советы башкарма комитеты секретаре сайлыйлар. Пенсиягә чykканчы авыл Советының секретаре, председателе һәм бухгалтеры булып эшли. Олы буын кешеләре бик хөрмәт иттеләр. Чөнки ул эшен җиренә җиткереп, гаделлек белән алып барды. Үзенең төпле, акыллы киңәшләрен бирер иде. Бигрәк тә ишле балалар белән тол, ятим калган хатыннарның балаларына эшкә урнашу өчен документлар алуда ярдәм итте. Аны район җитәкчеләре дә хөрмәт итә иде", – ди әбием.

Бабаем 1991 елда вафат булган. Кызганычка, мин аны фоторәсемнәр аша гына беләм. Әбием бабамны еш искә ала. Ул сөйләгәч, күңелемдә горурлык хисләре уяна.

Җиңү! Бу – яу кырында илне саклаган солдатлар һәм аларның дошманны җиңеп кайтуын көткән аналар, апалар, сеңелләр, ул һәм кызлар өчен иң зур бәхет. Ә без бабаемның сугышта фидакарьләрчә көрәшкән өчен алган медальләрен, командиры тарафыннан бирелгән рәхмәт хатын аның төсе итеп саклыйбыз.

Туган илебез зур сынаулар, авыр юллар, чиксез күп югалтулар белән Җиңү таңын каршылады. Юк, җиңел генә бирелмәде бу тынычлык, шуңа күрә дә без аның кадерен белеп, шушы аяз күкебезгә сөенеп, тормышның ямен-тәмен белеп, куанып яшәргә тиеш!

Сугышлар булмый корбансыз.
Ансыз – юк Җиңү туе.
Ә без үлгәннәр алдында
Бурычлы гомер буе.

"Сугыш!" Яратмыйм мин бу сүзне. Әби-бабайларыбызның матур яшьлекләрен тартып алганга, минем кебек үсмерләрнең "әти" дип әйтергә тилмереп үскәннәре өчен, гөнаһсызга коелган кан өчен. Туган халкым кичергән михнәтләр өчен күралмыйм сугышны. Әйе, Җиңүнең бәһасе кыйммәткә төште. Күпме тумаган балалар, кушылмаган яшь йөрәкләр... Шуңа күрә җирдә сугыш булмасын, бары тик тынычлык кына хөкем сөрсен иде.

Сугыш кичкән карт солдатның
Бер сүз каба сулышына.
Кабатлый ул дога итеп:
"Тик булмасын сугыш кына!"

*Фәридә Фәләхова, оныгы. 2012 ел.*

### Гафуров Галләм Галәви улы –
### күп сугышларда катнашкан авылдашыбыз
*(1897-1967)*

Гафуров Галләм Галәви улы 1897 елда Юлбат авылында Галәви һәм Мәфтуха гаиләсендә беренче бала булып дөньяга килә. Галләмгә 10 яшь булганда әтиләре дөнья куя.

Ул 18 яшендә хәрби хезмәткә алына. Беренче Бөтендөнья сугышында катнаша. Кавалериядә хезмәт итә. Энесе Саттар белән Апанаев дворында аерылышалар. Саттар сугышта үтерелә. Галләм 1917 елгы революциядән соң авылга кайта. Мәрьям исемле кызга өйләнә. 1919 елда гражданнар сугышына китә. Аннан кайткач, колхозда төрле эшләрдә эшли. Балалары – Зәйнәпбикә (1924), Ибраһим (1929), Гыйлемхан (1933).

Галләм 1941 елда Бөек Ватан сугышына китә. Каты яралана, контузия ала. Госпитальдә ятып чыккач, күперләр төзүдә катнаша. Авылга 1946 елның март аенда кайта. Колхозда ат караучы булып эшли. 1967 елда дөнья куя.

Характеры буенча кырыс, гадел, хезмәт сөючән кеше булган, балаларны бик яраткан.



Гафуров Галләм
Галәви улы


*Галләм бабай турында кызы Зәйнәпбикә сөйләгәннәрдән Фәрхуллина Лилия язып алды. 9 декабрь, 1996 ел, 17 сәгать 30 минут.*

## Ил картлары ни сөйли

Юлбат башлангыч мәктәбе директоры Саҗидә Ракованың “Җиңү байрагы” (1 май, 1967 ел) газетасында басылган мәкаләсеннән. Бу мәкалә мәктәптә укучыларның гражданнар һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары Галләм һәм Галимулла бабайлар белән очрашуы турында.

“Яшьләре олыгаеп килүгә карамастан, колхоз эшендә актив катнашып йөрүче Галләм һәм Галимулла бабайларны балалар башка вакытта да көнгә берничә кат күреп, сәлам биреп китәләр. Менә алар бүген мәктәпкә килгән.

Бабайларны хөрмәтләп каршы алып, түргә уздыргач, алар сөйләгәннәрне тыңларга әзерләндек. Галләм бабай сүз башлады.



Шәйдуллин Галимулла

– 18 яшькә җитеп солдатка киткәнче аякка күн итек кермәде. Авыр иде тормыш. Мин 1919-1922 елларда гражданнар сугышында катнаштым. Совет властеның халык власте икәнен аңлаган идек инде, аны саклап калу өчен күп көч куярга, зур корбаннар бирергә туры килде.

Галләм бабайга Ватан сугышының башыннан ахырына кадәр катнашырга туры килә. Менә Киев шәһәре янында алар Днепр елгасы аша тимер юл күпере салалар. Задание срогыннан 4 көн элек үтәлә. Мәскәүдән генерал-майор Кабанов килә. Күперне җәяүләп чыга, аннары аның аша эшелон үтә. Күпер төзүчеләргә бүләкләр бирелә. Алар арасында Галләм бабай да була.

# *Сугыш ветераннары турында истәлекләр*

## Ак халатлы шәфкать иясе



Мусина (Галимҗанова) Камәрия Галимҗан кызы

Мусина (Галимҗанова) Камәрия Галимҗан кызы 1921 елда Юлбат авылында туа. Юлбат башлангыч, Сатыш җидееллык мәктәпләрен тәмамлаганнан соң Чистай шәһәрендә фельдшер-акушерлык мәктәбендә укый. 1939 елда аны тәмамлагач, Балык Бистәсе районы Яңа Арыш авылына эшкә урнаша. Фин сугышы башланганчы шунда эшли. Фин сугышы башлангач, 1940 елның январеннан 9 маена кадәр Казанда госпитальдә эшли.

Бөек Ватан сугышы башлангач, 1941 елның августыннан 1943 елның сентябренә кадәр Казанда күчмә госпитальдә эшли, бер үк вакытта кичке институтта укый. 1943 елның сентябреннән 1945 елның декабренә кадәр Беренче Белоруссия фронты, Польшаның Познань шәһәре госпитальләрендә эшли. Сугыш елларында дүрт медаль белән бүләкләнә.

Сугыштан соң, хәрби кешегә кияүгә чыгып, Украина, Белоруссия җирләрендә хезмәттә була. Ире хезмәт иткән Владивосток шәһәрендә, Петропавловск-на-Камчатке шәһәрләрендә яши.

1958 елда Казанга кайта һәм калган гомерен ире белән Казанда үткәрә. 1960-1990 елларда участок шәфкать туташы, өлкән шәфкать туташы, мәктәпкәчә яшьтәге балаларның шәфкать туташы булып эшли. “Хезмәттәге батырлык өчен” медале белән бүләкләнә.

1999 елда Казанда вафат була, Юлбатта җирләнә.

## Хуҗин Габдрафыйк Хуҗаәхмәт улы



Хуҗин Габдрафыйк Хуҗаәхмәт улы

Хуҗин Габдрафыйк Хуҗаәхмәт улы 1920 елның 12 ноябрендә Йосыф-Алан авылында туа. Балачагы шушы авылда уза. Озак еллар колхозда эшләп, 1939 елда армия сафларына китә. Ерак Көнчыгышта кавалериядә хезмәт итә.

Бөек Ватан сугышы башланыр алдыннан аларны Көнбатышка күчерәләр. Озакламый сугыш башлана. Сугыш башланып ун көн узуга, аларның дивизиясен Воронежга китереп, сугышка кертәләр.

Немец солдатларының бомбага тотуыннан Рафыйк абый контузия ала һәм, башына бомба ярчыгы тиеп, каты яралана. Аны Мичуринск шәһәренә госпитальгә озаталар.

Госпитальдә озак кына ятканнан соң парашютно-десантный частька Саратов шәһәренә өйрәнүгә җибәрәләр. Шунда аларны парашюттан сикерергә өйрәтәләр һәм дошман тылына ташларга әзерлиләр. Ләкин шул вакытта немецлар Мәскәү янына килеп җитәләр һәм аларны Мәскәүне сакларга җибәрәләр. Анда каты сугышлар башлана. Алар немецларны 40 км Көнбатышка куалар. Шулай итеп, немецларның Мәскәүне тиз арада алу планы җимерелә. Десантчыларның исән калганнарын кире Мәскәүгә чакыртып алалар һәм немец тылына ташлау өчен хәзерлек эшен яңадан башлыйлар.

Мәскәү өчен сугышларда күрсәткән батырлыклары өчен Рафыйк абыйга “За отвагу” медале һәм “Старший десант гвардии” дигән исем бирәләр.

1942 елның августында, Сталинград өчен канкойгыч сугышлар барганда, Рафыйк абыйлар дивизиясен Сталинградны камау өчен десант итеп немецларның тылына ташлыйлар. Шунда Рафыйк абый тагын яралана. Аны Астраханьга госпитальгә җибәрәләр. Госпитальдән чыгуга, миномет частена взвод командиры итеп билгелиләр. Озак вакытлар шушы частьта сугыша. Сталинград өчен барган сугышлардагы батырлыгы өчен Рафыйк абыйны Дан ордены белән бүләклиләр. Ул шулай ук Волгоградны, Ростовны, Донбассны азат итү өчен сугышларда катнаша. Днепропетровск, Запорожье, Кривой Рог шәһәрләрендә сугыша. Одессаны азат иткәндәге батырлыгы өчен “Кызыл Йолдыз” ордены белән бүләкләнә. Бу сугышларда тагын яраланып, Одесса госпиталендә ята. Госпитальдән соң, Кара диңгез аркылы чыгып, Румынияне азат итә. Аннан Бухарестны, Албанияне, Болгарияне, Югославияне, Венгрияне азат итүдә катнаша. Будапештны алганда күрсәткән батырлыгы өчен “Ватан сугышы” ордены белән бүләкләнә. Аннан Австриянең Вена шәһәрен алуда катнаша, шунда соңгы мәртәбә яраланып, Венгриянең Кечкемент шәһәрендә госпитальдә ята. Сугыш беткәч тә аны армиядә тагын бер елга тоткарлана. Шулай итеп, ул сугыш кырында җиде ел йөреп кайта.

Бөек Ватан сугышы беткәнгә хәзер 50 ел тула. Бәхеткә каршы, Рафыйк абый да безнең белән Җиңү бәйрәмен күрәчәк. Без халкыбызның батырлык һәм фидакарьлеген, зур югалту һәм корбаннарын һич кенә дә истән чыгармаска тиешбез. Бер кичергән афәт, газаплар бүтән килмәсен! Илдә тынычлык булсын”

*8 класс укучылары тарафыннан төзелгән*
*“Җиңүгә өлеш кертүчеләр” альбомыннан. 1995 ел.*

**Бөек Ватан сугышы ветераны Мөхәммәтҗанов Мәүлетҗан**

Ул 1918 елның 20 июлендә Юлбат авылында туган. Юлбат башлангыч, Сатыш җидееллык мәктәпләрендә белем алган. 1937-1939 елларда авыл Советы секретаре булып эшли. Ул 1939 елның декабрь аеннан алып 1946 елның октябренә кадәр Совет Армиясендә хезмәт итә.



Мөхәммәтҗанов
Мәүлетҗан

1940 елда Фин сугышында катнаша, аннары Бессарабияне алалар (Румыния сугышсыз бирә). Көнгә 50 шәр километр җәяү йөрелә иде, ди ул.

Бөек Ватан сугышы башланганда ул армия сафларында була. Беренче көннәрдә алар сугыша-сугыша артка чигенәләр. Бу Украинаның Волынск өлкәсенең бер авылы янында була. Бер атнадан яраланып, немецлар кулына эләгә. Аларны Норвегиягә җибәрәләр. Өч тапкыр качып карыйлар, ләкин аларны тоталар. Норвегия халкы әсирләргә ярдәм итәргә тырыша. Лагерьда әсирләргә 200 г ипи (яртысы пычкы чүбе), сыек кына аш бирәләр, өйрәтелгән этләр белән саклыйлар. Сакчылар әсирләрне теләсә нишләтә алганнар, качырмаска гына тиеш булганнар.

Сугыш беткәндә Мәүлетҗан абыйларны инглизләр азат итәләр. Өч комиссия үткәреп, бер айдан соң илгә кайтаралар. Туган якка Швеция, Финляндия аша кайталар.

Сугыштан соң колхозда ветсанитар, аннан соң 14 ел кырчылык бригадасы бригадиры, пенсиягә чыгар алдыннан завхоз булып эшли.

*Укытучы Халикова Мәрзия Гатаулловнаның ветеран сөйләве буенча эшләгән альбомыннан, 1995 ел*

**Зәйнуллин Гобәйдулла Зәйнулла улы**



Зәйнуллин Гобәйдулла
Зәйнулла улы

1917 елның 15 декабрендә Зәйнулла абый белән Фаидә апа гаиләсендә алтынчы бала булып дөньяга килә. Туган авылы Юлбатта башлангыч белем ала. Беренче укытучысы Газизә апа Иманкулованы бүген дә зур хөрмәт белән искә ала. Уналты яше тулган көннәрдә аны Мамадышка счетоводлар курсына укырга җибәрәләр. 6 ай укыганнан соң авылга кайтып, идарәдә счетовод булып эшли башлый.

1937 елны Гобәй абыйның яшьтәшләренә армиягә чакыру кәгазьләре килә башлый. Яшьтәшләре белән армиягә китү насыйп булмагач, ул Мәскәүгә эшкә китә. Туку цехында эшли. Ләкин озак эшләргә туры килми. 1939 елда Япон белән сугыш башлана. 24 сәгать эчендә эштән азат ителеп, Гобәй абый повестка ала. Мәскәүдән алып киткәч, аларны алты ай чамалы сержантлыкка укыталар.

1941 елның 22 июнь таңында да Мәскәүдә була ул. Түбәндәге өзекне нәкъ ветеран сөйләгәнчә китерәчәкләрен искәртә альбом төзүчеләр. Без дә үз чиратыбызда ул өзекне үзгәрешсез бирәбез, чөнки ул ветеранның үзе күргәннәр, үзе кичергәннәр буенча язылган. Гомумән, сугыш ветераннары хатирәләренә кагы-

лышлы истәлекләрне үзгәрешсез бирәчәгебезне искәртеп үткән идек инде. Бүген ул ветераннар берсе дә исән түгел, бары истәлекләре генә безнең арада.

Сугышның беренче көннәрен күргән Гобәй абый сөйли:

– 1941 елны немецлар Мәскәүне чолгап ала башлагач, безнекеләр бик нык каршылык күрсәттеләр. Мәскәү астыннан каты сугыш китте, Смоленскига кадәр немецларны кудык. Ул шәһәр немецлар кулында. Немецлар Заячья гора янында оборонага туктадылар. Без 30-35 км ераклыктан боларны күзәтәбез. Көндез землянкада ятабыз, ә мин яшерен пакет белән йөрим. Дивизия бездән 15 км артта, минем хәтта көнгә өчәр мәртәбә барып кайткан чакларым да булды. Кышкы көн булганлыктан, чаңгыда йөри идем. Минем белән тагын рус милләтеннән булган икәү бар. Алар шактый олы яшьтә, бераз урманга кадәр озаталар, шуннан мин үзем генә китәм, ә кайтканда каршы алалар. Аннан соң безнең дивизия Брянск разъездына күчте.

Бераз уйланып утыргач, сугышның икенче эпизодына күчә ветеран:

– Украинада каты сугышлар булды. 1942 елны Днепрны кичтек. Днепрның бер ягында немец оборонасы. Күзәтеп ятабыз: немецлар Днепр суында котелоклар юалар. Безнең 120 нче полк иң беренчеләрдән булып Днепрны кичте һәм иң әһәмиятлесе – югалтулар күп булмады. Ә менә 103 нче полк зур югалтуларга дучар булды, алар Днепрның түбәнрәк агымында иде, аларга немецлар көчле һөҗүм ясадылар.

– Белоруссия сазлыкларын кичүе гаять авыр булды, – дип искә ала Гобәй абый.

### Үлемне җиңгән каһарман


Гайфетдинов Фахразый Гайфетдин улы

Тенеки авылыннан Бөек Ватан сугышына авылның 112 ир-егете китә. Шуларның 78 е яу кырында ятып кала, бары тик 34 ир-егет кенә туган якларга кайту бәхетенә ирешә. Авыр сугыш юлы узып, җиңүгә өлеш керткән каһарманнарның берсе – Гайфетдинов Фахразый Гайфетдин улы. Ул 1918 елда Саба районы Тенеки авылында крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Сабый чагы туган авылында уза. Сатыш җидееллык мәктәбен тәмамлый.

1935 елны слесарьлыкка укырга ФЗӨ мәктәбенә китә. 1939 елга кадәр Казан шәһәрендә 22нче заводта слесарь булып эшли, 1939 елның язында Архангельскига китә. Сентябрь аенда, солдатка каралу өчен, кире Казанга кайткан һәм бишенче сентябрьдә армиягә алынган. Байкал арты хәрби округына эләккән. 3 ай полк мәктәбендә укыган.

1941 елның 10 маенда, эшелоннарга төяп, аларны Көнбатышка җибәрәләр. Сугыш башлану турында хәбәрне Алма-Ата шәһәрендә ишетәләр. Аларны Белоруссиянең Орша шәһәренә җибәргәннәр. Смоленск шәһәренә кадәр чигенеп,

Вязьма янында аларның часте чолганышта кала. Чолганыштан чыккач, 16 нчы запас полкка күчергәннәр. Аннан Фахразыйны Горький өлкәсендәге Богородск шәһәренә өч айлык курсларда укыталар. Анда чит ил коралларын кулланырга өйрәтәләр. Ә 1942 елның апрель аенда Горькийдагы 168 нче танк бригадасына чит ил коралларын өйрәтү буенча белгеч итеп җибәргәннәр. 1942 елның җәендә Мәскәү оборонасы, Курск сугышында катнашкан. Беренче Украина фронтында Киевны алуда аяусыз көрәш юллары узган. Днепрны дошманнан азат итүдә катнашкан, Днепрны кичкән. Шул вакытта армиянең генерал-лейтенанты Ватутинга һөҗүм була. Ватутинны Киевта Крещатка дигән урында җирлиләр, кабере өстенә танк куялар.

Күп югалтулар аша Эстония, Латвия, Литва җирләрен азат итеп, Польшага килеп керәләр. Аннары Германиянең Найденбург, Остерода, Тайденбург шәһәрләрен алуда катнашкан. Шул ук елны, яңак сөяге яраланып, госпитальдә ятып чыга.

Сугыш беткәч, 1945 елның сентябрендә, туган авылына ялга (отпуск) кайта. Ә авылга бөтенләйгә кайту 1946 елның сентябрь аенда гына насыйп була.

Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен “Кызыл Йолдыз” ордены һәм бик күп медальләр белән бүләкләнгән.

1946 елның сентябрь аенда Тенеки авылының Зәйтүнә исемле кызы белән тормыш корып җибәрәләр. 1947-1949 елларда Мәртендә авыл Советы рәисе, 1950-1953 елларда “Яңа юл” (Тенеки авылы) колхозы рәисе булып эшли. Колхоз берләшкәч, кырчылык бригадасы бригадиры, зоотехник, төзүчеләр бригадасы бригадиры була. Зәйтүнә апа белән биш бала тәрбияләп үстерәләр.

Фахразый бабайның безгә әйтер сүзен җиткерәбез: “Мин II группа сугыш инвалиды. Кешелеккә теләгем шул: тормышның ямен, кадерен белеп яшәсеннәр. Сабыйларга ачлык, авыр тормыш күрергә язмасын”.

*9 сыйныф укучылары төзегән альбомнан,*
*җитәкчесе – Халикова Мәрзия Гатаулловна.*
*Апрель, 1995 ел.*



Баһавиев Ислам

### Ветеранның сугышчан юлы

Баһавиев Ислам Баһави улы 1919 елның 5 маенда Тенеки авылында туа. 1935 елда Сатыш җидееллык мәктәбен бик яхшы билгеләренә генә тәмамлап, Казан учет-кредит техникумына укырга керә. Аны 1937 елда уңышлы тәмамлап, Зеленодольск шәһәренә финанс инспекторы итеп билгеләнә, тагын бер елдан өлкән фининспектор итеп күтәрелә.

1939 елда, Икенче Бөтендөнья сугышы башлангач, Ислам Баһавиевич илне саклау өчен хәрби профессия үзләштерергә карар кыла. Кабул итү

имтиханнарын бик яхшы билгеләренә генә тапшырып, Подольск шәһәрендәге артиллерия училищесына укырга керә. Аны 1940 елда лейтенант дәрәҗәсендә тәмамлап, Забайкальский военный округның артиллерия полкына взвод командиры һәм штаб начальнигы урынбасары итеп хезмәткә җибәрелә. Сугыш башлану хәбәрен поездда Көнбатыш фронтка таба хәрәкәт иткән вакытта ишетә.


Полковник
Баһавиев Ислам

Беренче хәрби чыныгуны 1941 елның 3 июле көнне Смоленск шәһәре тирәсендә Орша, Ельня торак пунктлары янында ала. Кыю командир “За боевые заслуги” медале белән бүләкләнә.

1941 елның декабреннән Мәскәүне саклаучылар сафына баса. Волоколамск шоссесы буедагы Крюково авылы янында генерал Панфилов дивизиясе белән янәшәдә сугыша. Волоколамск шоссесына җибәрелүне оныгына сөйләгән истәлекләрендә ветеран болай искә алган: “1941 елның ноябрь ахыры – декабрь башларында мине Мәскәүгә – Верховный Главнокомандующий Ставкасына чакыртып алдылар. Сталин һәм Жуков белән очраштым. Мин хезмәт иткән дивизион маршал Жуковка буйсына иде. Миңа соңрак “катюша” дип исем бирелгән реактив минометлар алып Нагатино пунктына барырга приказ булды, минометларны алуга, приказ үзгәртелеп, Волоколамск шоссесы ягына китәргә яңа приказ алдым. Шулай итеп, безнең дивизион Панфилов дивизиясенә артиллерия уты белән булышырга тиеш булды”. Ислам Баһави улының бу бәрелешне тасвирлаган истәлекләрен оныгы язып алган, анда панфиловчыларның батырлыгы да сурәтләнгән. Сугыш кораллары беткәнлектән, Баһавиев хезмәт иткән дивизион тылга чигенергә приказ ала, алар панфиловчыларны калдырып китәргә мәҗбүр булалар. Ислам Баһави улы генерел Панфилов белән шәхсән таныш була, Крюково янындагы сугыштан соң да очрашып сөйләшә. Мәскәү астындагы сугышлардан соң лейтенант Баһавиев 30 нчы реактив дивизионның штаб начальнигы итеп күтәрелә һәм Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә. Ләкин командование яшь артиллеристка өлкән лейтенант званиесе бирү һәм “За боевые заслуги” медале белән бүләкләү белән чикләнә. Күп тә үтми Чой Бал Сан җитәкчелегендәге Монголия делегациясе аны Монгол Халык Республикасының Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкли.

1942 елның кыш һәм яз айларында Мәскәү астындагы сугышлар өчен Ислам Баһавиев капитан званиесе ала һәм Смоленск шәһәрен алудагы батырлыклары өчен Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә.

Курск дугасындагы сугышлар өчен (хәзер инде гвардия майоры) Багавиев кабат Герой званиесенә тәкъдим ителә, ләкин югарыдагы җитәкчелек 24 яшьтән гвардия майоры булу һәм Герой званиесе алу артык күп дип саный һәм корпус командованиесенең тәкъдимен кире кага. Яшьлеген сәбәп итеп, Генштаб академиясенә укырга җибәрүдә дә аның кандидатурасы кире кагыла.

Курск дугасыннан соң гвардия майоры Баһавиев дивизионы Украина юнәлешенә күчерелә. 1943 елда II дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены, 1944 елда Александр Невский ордены белән бүләкләнә. Оныгы Семен Витальевич Давыдов бу орденның фронт белән командалык итеп зур яуларда җиңүгә ирешкән генерал һәм маршалларга яки Верховный Главнокомандующийның якыннарына гына бирелүен билгеләп үтә һәм орден кавалерлары арасында бабасының да булуын зур горурлык белән ассызыклый. Горурланырлык та шул: аның бабасының, Тенеки авылының Баһавиевлар гаиләсендә тәрбияләнгән Исламның, сугышта алган 7 ордены һәм 15 медале була. Командование өч тапкыр Герой исеменә дә тәкъдим итә, ләкин Югары командование төрле сәбәпләр табып кире какканлыктан, ул звание бирелми кала.

Гвардия майоры Ислам Баһавиевич Баһавиев Җиңү көнен 1945 елның 9 маенда Прагада каршылый. Чехословакияне азат иткән өчен Чехословакия ССРның Югары Офицер кресты һәм Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.

Әйе, Ислам өчен сугыш тәмамлана, ләкин бу гаиләдә төзәлмәс яралар кала: геройның ике өлкән абыйсы – әле гаилә дә корып өлгермәгән Мөхәммәтзыя белән Шәехзадә – сугыш кырларында ятып кала. Шулай итеп, дүрт ул, бер кыз тәрбияләп үстергән Баһаветдин белән Гөлфәридәнең терәге булып кече уллары Сәүбән кала. Ә Сәүбәнгә балалык белән бик иртә саубуллашырга туры килә. Сугыш вакытында тылдагы бөтен авырлык картларга, хатын-кызларга, үсмер малайларга-кызларга төшә бит.

Төп нигездә Сәүбән абый гаиләсендә сигез бала үсә. Әти-әниләре аларны эшчән, гадел, туган җанлы, туры сүзле, гомумән, Баһавиевларның нәсел агачының дәвамчылары итеп тәрбиялиләр.

Ислам Баһави улы сугыштан соң да хәрби хезмәтен дәвам итә. 1945-1949 елларда Прикарпатский хәрби округында реактив дивизион (“катюшалар”) командиры, 1949-1953 елларда Германиядәге совет гаскәрләре сафында, 1953-1957 елларда – Төньяк Кавказ хәрби округында хезмәт итә. 1958-1959 елларда Ленинградта Югары хәрби артиллерия мәктәбендә укый. 1957-1962 елларда – Германиядә Совет гаскәрләренең полк командиры ярдәмчесе. 1962 елда артиллерия подполковнигы дәрәҗәсендә отставкага чыга. 1985 елда, Бөек Җиңүнең 40 еллыгын бәйрәм иткәндә, Мәскәүдә Җиңү парадында катнаша. 1995 елда Бөек Җиңүнең 50 еллыгы уңаеннан полковник дәрәҗәсе бирелә.

Отставкага чыккач та төрле җаваплы эшләрдә эшли. 1997 елда 79 нчы яшендә вафат була. Туган авылы Тенеки зиратында җирләнгән.

Ветеранның сугышчан юлы турында вакытлы матбугат битләрендә дә язылган. Басмалар рус телендә булганлыктан, үзгәртмичә китерәбез.

1. *Багавеев И.Б.* Бой у деревни Крюково. – Газета “Комсомолец Татарии”. – Май, 1975. – С3.

2. *Василенко Д.* Встреча с маршалом Чой Бал Саном. – Газета “Советская Кубань”. – Август 1981.

3. *Тамарова Т.* Остался в строю. – Газета “Трудовая Слава”. – Май 1984. – С1.

4. *Шевчук В.* Над Прагой – солнечное небо. – Газета “Вечерняя Казань”. – Май 1985. – С2.

## *Минем гаиләм тарихында — сугыш*

### Хаҗиевлар гаиләсе



4 улын сугышка озаткан әти-әни: Хаҗиәхмәт һәм Маһиҗиһан Хаҗиевлар

Гаиләләрне төпсез кайгыга салган, балаларны вакытыннан алда олыгайткан, хатыннарны тол иткән, карт-корыны ял итеп утырыр урында ат урынына эшләткән сугыш... Илебездә сугыш ишек какмаган гаиләләр юктыр, мөгаен.

Әйе, 1941-1945 елгы, бик зур корбаннар китергән дәһшәтле Бөек Ватан сугышы минем гаиләмне дә читләтеп узмаган. Минем әниемнең дүрт абыйсы сугышның беренче көннәреннән үк фронтка китәләр. Әниемнең иң олы абыйсы – Хаҗиев Хуҗа Хаҗиәхмәт улы (1899-1986) – 1942 елның 25 февралендә сугышка алына. Бөек Ватан сугышында Калинин фронтында 1943 нче елның сентябренә кадәр, көнбатыш фронтта 1943 елның сентябреннән 1944 елның апреленә кадәр, Белоруссия фронтында 1944 елның апреленнән 1945 елның маена кадәр 1259 укчы полк һәм 245 укчы полк составында укчы булып катнаша. Рядовой, сержант. “Сугышчан хезмәтләре өчен”, “Германияне җиңгән өчен” медальләре белән бүләкләнә. 1945 елның 8нче июлендә запаска җибәрелә. Юлбатка кайта. Заготовщик булып эшли.



Хаҗиев Хуҗа

1986 нчы елда үлде.



Хаҗиев Баймөхәммәт

Әниемнең икенче абыйсы – Хаҗиев Баймөхәммәт Хаҗиәхмәт улы (1901-1975) – хәрби кеше була. Бөек Ватан сугышының беренче көненнән үк фронтка китә. Беренче Белоруссия фронтында Рокоссовский армиясендә комбат (батальон командиры) булып, сугышның ахырына кадәр хезмәт итә. “Сугышны 9 май көнне Чехословакиянең Җамберек шәһәрендә тәмамладым,” – дип сөйли иде.

“Руда Армаде! Наздар! Наздар! – дип чехларның безнең гаскәрләрне сәламләвен, бик яхшы кабул итүләрен хәтеренә ала иде. Сугыштан исән-имин

кайтуына гаҗәпләнә иде. Нинди генә хәлләр күрмәдем. Командир гел алда була, югыйсә, ә миңа бер генә пуля да тимәде, яраланмадым, Ходай саклагандыр”, – дип сөйли торган була ул. Ике Ватан сугышы ордены, ике Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнелә.

Сугыштан 1946 елда Казанга гарнизонга кайта, шунда штабта эшли. 1955 елда подполковник дәрәҗәсендә отставкага китә.

1975 елның 24 маенда вафат була. Юлбат авылы зиратына алып кайтып җирләнә.

Әниемнең өченче абыйсы Хаҗиев Таҗимөхәммәт Хаҗиәхмәт улына (1908 – ?), сугыштан исән-имин әйләнеп кайту насыйп булмый. 1908 елда Юлбат авылында туа. Ул Юлбатта беренче тракторчы була. 1930 елда Саба МТСында эшли башлый. Беренче район Советы депутаты була. 1943 елда сугышка китә. Курск дугасы өчен барган сугышларда катнашуы билгеле. “Днепрны исән-сау чыктык...” дигән хаты аннан соңгы хәбәр була. Хәбәрсез югала.



Хаҗиев Миңлебай

Әбиемнең дүртенче абыйсы, Хаҗиев Миңлебай Хаҗиәхмәт улы (1916-1989), 1916 елның 28 гыйнварында Юлбат авылында крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Авыл мәдрәсәсендә Мифтахетдиннән гарәп телен һәм латин телен өйрәнгән. Совет мәктәбе ачылгач, Юлбат башлангыч мәктәбендә Газизә Иманкуловадан дүртъеллык белем алган.

1933 елның март аенда Саба МТСында 4 айлык трактористлар курсын бетерә. 1936 елга кадәр шул ук МТСта слесарь-ремонтчы булып эшли. 1936 елның ноябрь аенда хәрби хезмәткә алына. Закарпатьеда Ужгород шәһәрендә хезмәт итә. 1939 елда Украинаны бүлешәләр, анда каты сугышлар булмый, Сталин белән Гитлерның килешүе нәтиҗәсендә, Буг елгасының бер ягын СССРга, бер ягын Украинага бүлешәләр, шуннан демобилизациягә киткәндә, өйгә кайтабыз дип шатланып йөргәндә, рус хөкүмәте Финляндия белән сугыш ача.

Бу Карелия фронты дип атала. Кыш бик салкын була. Һавада очып барган кошлар суыкка түзә алмыйча, мәтәлеп төшеп үләләр. Сугыш озак бармый. СССР Финляндия белән март аенда килешү төзи.

1940 елның 6 ноябрендә демобилизацияләнеп, туган авылына кайта. Солдат беренче категорияле кием белән армиядән кайтса, ул киемне өч көн кигәннән соң, кайткан җирендә хәрби комиссариатка алып барып тапшырырга, дигән приказ чыккан була. Ул бу приказны үти. Шуннан, киемнәрне тапшыргач, Саба МТСына керә. Ул вакытта МТС директоры Ногманов Нурислам абый, аның хәленә кереп, бер телогрейка, чалбар, аягына киез итек биреп, эшкә ала. Шуннан башлап ул “У-2” тракторында эшли башлый. 1941нче елның 6 июлендә Бөек Ватан сугышына китә. Төньяк фронтта хезмәт итә ул. Кандалакша, Петрозаводск, Мурманск шәһәрләрен дошман һөҗүменнән саклыйлар. “Без бик ачыктык. Атлар, мескеннәр, бер каен себеркесе ашап торалар иде, ә солдатлар 12дән 1 кисәк тозлы балык, 100 грамм ипи, бер кружка ылыс суы белән тора идек. Әле бу да

Мурманск портына Америкадан корабльләр исән-сау килеп, азык-төлек китерсә генә була иде,” – дип сөйли торган була ул.

1945 елның 10 июненнән соң аны Вологда шәһәренә автобатальонга өлкән механик итеп җибәрәләр. Әкренләп өлкән яшьтәге кешеләрне, хезмәттән азат итеп, өйләренә кайтара башлыйлар. Ул бәхет Миңлебай абыйга да эләгә. Сержант, отделение командиры була. 1946 елның 16 маенда демобилизацияләнеп, туган авылына кайта. Шул елдан алып, 1961 елга кадәр тракторист булып эшли. 1961 елдан 1970 елга хәтле колхозның электростанциясендә дизелист-электрик булып эшли.

1989 елның 31 июлендә вафат була.

Әтием, Габрахманов Габдрәүф Габдрахман улы (1925-2004), 1925 елның 12нче гыйнварында Саба районы Сатыш авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. 1938-1939нчы уку елында 7нче сыйныфны тәмамлый. Урта белемне Теләче мәктәбендә ала. 1942-1943нче елларда Сатыш авыл Советында секретарь булып эшли.

1943 елның 11 гыйнваренда сугышка китә. Аны Ерак Көнчыгышка учебный батальонга җибәрәләр. Аңа кече сержант званиесе бирелә һәм отделение командиры итеп билгеләнә. Соңрак рота старшинасы була. Алар фронтка сугышчылар хәзерлиләр. Японнарга каршы II Ерак Көнчыгыш фронтта 255 нче укчы дивизия 972 нче укчы полк составында Сунгарь елгасы буендагы сугышта катнаша. “Японияне җиңгән өчен”, “Германияне җиңгән өчен”, II дәрәҗә Ватан сугышы ордены” һәм башка медальләр белән бүләкләнә. Туган якларга ул 1951 нче елда гына әйләнеп кайта. 1953-1955 елларда – Саба районы партия комитетында пропагандист һәм парткабинет мөдире, 1955-1968 елларда – Мәртен, Сатыш мәктәпләрендә директор һәм пенсиягә чykканчы тарих укытучысы булып эшли. “Мәгариф отличнигы” дигән исемгә лаек була. Җиңүнең 55 еллыгына аңа майор званиесе бирелә.

2004 елның 18 октябрендә үлә.

Ирем Рафиснең бабасы, Фәрхуллин Фәрхетдин Фәрхулла улы (1902-1957), 1902е елда Юлбат авылында туа. 1941 елның августында сугышка китә. 1941 елның мартыннан 1943 нче елның октябренә кадәр мед.сан. батальонның 154 отделениесе составында, 1943 нче елның октябреннән 1945 нче елның июленә кадәр 119 нчы гвардия укчы дивизиясенең 344 нче гвардия укчы полкы составында сугыша. 1945 нче елның сентябрендә демобилизацияләнеп туган авылына кайта.

Бер сугышта ул бик каты яралана. Врач-санитарлар да аны, үлгән дип уйлап, калдырып китәләр. Шулай аңсыз килеш яткан вакытта, аны өйрәтелгән эт табып ала һәм санчастька кадәр өстерәп алып кайта. Кулындагы тирән ярасын “тел алырга“ барганда булды дип әйтә торган була. Сугыш беткәч тә армиядә ат врачы булып хезмәт иткән. Сугыштан кайткач та этләргә рәхмәтле калып, яратып эт асраган. Сугышта алган яралар аңа озак яшәргә бирми. 1957 елның 8 мартында вафат була.

Иремнең икенче бабасы Мотыйков Мәҗит сугыш кырларында хәбәрсез югала, бер хаты да килми.

Әнием, Хаҗиева Рәшидә Хаҗиәхмәт кызы (1923-1993), 1923 елның 15 маенда Юлбат авылында туа. 1940 елда Казанда немец теле укытучылары хәзерли

торган курсларны тәмамлый. Башта Әгерҗе районы Көчек авылында укыта, сугыш башлангач, үз ягына, Саба районына кайта. “Балаларның өсләре кырык ямаулы, ачлы-туклы. Әмма дәресләр бара. Ни дәфтәр, ни дәреслек, ни язу карасы юк. Нәрсә туры килсә, шунда язабыз, бер карандашны 3-4кә бүләбез”, – дип сөйли торган була ул. 1951 елның 18 мартында кияүгә чыга. Озак еллар Сатыш мәктәбендә татар теле һәм немец телләре укыта. 1974 елда пенсиягә чыга.

1993 елның 18 гыйнварында вафат була.

Әнием ягыннан туганым, Исламов Тимерхуҗа Ислам улы (1905 – ?), 1905 нче елда Юлбат авылында туа. Сугыштан ике хаты килә. Бер хаты сакланмаган. Икенче хаты 1943 елның 18 августында язылган. Ул хатында “моңарчы партизан отрядында идек, хәзер армиягә кушылдык, иртәгә сугышка керәбез, исән булсам, хат язармын. Киев өлкәсе, Украина сугышы белән барабыз” дигән.

Бу аның соңгы хаты була. Хәбәрсез югала.

Таҗи абыйның хатыны Фатыйма әби тракторда эшләгән. Бер басудан икенче басуга кадәр җәяү барганнар, запчастьларны Шәмәрдәннән, Арчадан күтәреп ташыганнар. Әниемнең апалары Хөсникамал, Мәймүнә, иремнең әбиләре – Әминә, Хәтирә әбиләргә төрле авыр эшләрдә эшләргә туры килә. Урман кисәләр, окоп казыйлар, Шәмәрдәнгә икмәк ташыйлар...

*Искәрмә:* Бу фоторәсем безнең гаилә, нәсел өчен бик истәлекле. Ул 1941 елның 23 июнендә Сабада якыннарны фронтка озатканда төшерелгән.



1941 елның 23 июнендә Сабада якыннарны фронтка озатканда төшкән фоторәсем

1 рәт: (сулдан уңга) Исламов Тимерхуҗа (әниемнең апасының ире), Галимҗанова Камәрия (сугышта медсестра булган), Хаҗиев Таҗимөхәммәт (хәбәрсез югалган), әнием Хаҗиева Рәшидә (озак еллар Сатыш мәктәбендә немец теле укыткан), Хаҗиев Миңлебай.

2 рәт: (сулдан уңга) Ибәтов Миңнемулла, әниемнең апалары – Исламова Хөсникамал, Хаҗиева Фатыйма, Хаҗиева Мәймүнә; Фатихов Кәшиф.

Бу кешеләр бар да мәрхүмнәр инде һәм без үзебезнең бәхетле тормышыбызның алар күргән авырлыклар аша килгәнен онытмаска тиеш.

*Мәҗитова Рәмзия Габдрәүф кызы,*
*Юлбат урта мәктәбенең инглиз теле укытучысы. 2011 ел.*

**Әйтәсе сүзләр бар кебек**

“Әйтәсе сүзләр бар кебек.
Тезелештек кыр казлары сыман.
Күзләрне төбәп алга карап
Төштек өчәү сезнең өчен”.



Авылдашлар сугыштан кайткач

Әти (уртада) туганнары белән төшкән: уң якта – Сафин Фатхулла, сул якта – Галимҗанов Хәкимҗан. Алар өчесе дә Тенеки авылыннан. Шуларның яшь чагы, ут чәчрәтеп, кызлар артыннан йөргән чаклары күз алдына килә. Карап торырга алар исән, форма кигән килеш бусагадан атлап керерләр кебек тоела. Бу бары тик уй гына шул. Алар өчесе дә бу дөньяда юк инде. Кайчак сорау туа: “Ни өчен кеше исән чакта аның яшәгән төп нигезен, тарихын, кемнәр белән туган икәнен сорарга да башка килми? Бу дөньядан киткәч кенә сорыйсы сүзләр күңелдә мәңге әйтелмичә кала”.

Әтинең төрле-төрле мактау кәгазьләре киштәдә җавапсыз тарих кебек өелеп тора. Күпләр аны әнә шулай уңган, булдыклы кеше итеп хәтерли. Минем күңелдә дә ул үрнәк, гадел, ихтирамлы, кешегә ярдәмчел булып сакланып калачак. Барысы өчен дә язмышка рәхмәт. Әти дип аңа әйтергә язган.

Ул 1926 елның 26 мартында Саба районы, Тенеки авылында туа. Гаиләдә икенче бала. Олысы – Зиннәтулла, икенчесе – минем әти – Гыйльмулла, Миңнемулла, Диләфрүз, Сәвия.

Әтинең гомере буе кулыннан гармун, тальян төшмәде. Кая гына барса да, ул аларны үзеннән калдырмады. Тавышы көчле. “Карурман”ны сузып җырласа, бөтен зал яңгырап торган.

Табигате белән кызу кеше була ул. Ни дисәң дә, сугыш чорын узган, контузия алгап, пуля белән кайткан. Дөрес, Ходай аңа яшәргә гомер, көч, өмет биргән. Ничә еллар узса да, әтине онытмаячакмын. Искә алганда күңелем йомшап китә. Исән чакта кадерен белик әти-әниләрнең. Һәрвакыт ярдәм кулларын сузып торучы бары тик әти-әниләр булуын истән чыгармыйк.

*Ландыш Димиева.*
*Яшел Үзән – Васильево*

**Фронтовик авылдашыбыз Хуҗин Зиннур гаиләсе тормышыннан сәхифәләр**


Хуҗин Зиннур гаиләсе белән

Сугыш чоры авырлыкларын кичергән йөзләгән гаилә арасыннан тагын берсе – Хуҗин Зиннур белән Хәйрелхисал гаиләсенә тукталып китик. Танышуны аларның оныгы, гомерен Юлбат авылында балалар укытуга багышлаган Халикова Мәрзия Гатаулла кызының “Ватаным Татарстан” газетасында чыккан язмасыннан өзек белән башлыйк.

“…Әбием Хәйрелхисал 1904 елда Юлбатта туган, Зиннур белән гаилә корган. Сугышка кадәр Асия (әнием), Рамазан, Нәфига туа, иң кечеләре Мөхәррәм әтиләре сугышта чакта, 1942 елның февралендә дөньяга килә. Әбием зур гәүдәле, тәвәккәл булган. Ул ике ат көтүе көткән, башка эштән дә курыкмаган.

1944 елның 6 мартында әбигә урман эшенә китәргә туры килә, алар Дәүләтшина Рауза апа белән эшлиләр. Аударылган агачларны юлга якын махсус урынга тартып китерергә кушалар. Тирән карда батып-чумып йөрүе уңайсыз булгач, әбием кулдаш хатынны, агач кисәргә сорыйк, дип ризалата. Ике көн хәвефсез генә эшлиләр, өченче көндә фаҗига була. Әбине Шәмәрдәннән Иштуган аша Кукмарага илткәнәр…”

*(“Ватаным Татарстан” газетасы, 31.05.2014 ел №78)*

**Хуҗин Зиннур**

Бабам Хуҗин Зиннур (әниемнең әтисе) 1901 елда туган. Төрле елларда колхозның хуҗалык мөдире, кибетче, янгын сүндерүче булган, бүтән эшләр башкарган, озак еллар ревкомиссия, идарә әгъзасы булган.

Бөек Ватан сугышында Мәскәү астында, Смоленск, Белоруссия җирләрендә сугышкан. Әни аның фронттан язган хатындагы җыр юлларын хәтерендә саклый:

Ераклардан күренеп тора
Олы юлның маягы.
Көне-төне җәяү чабып
Бетә минем аягым.
Таш казарма буйларына
Мылтыгымны сөядем.
Туган-үскән илләремә
Кайтыр микән сөягем?

Зиннур сугышта вакытта хатыны Хәйрелхисалны да Шәмәрдәнгә урман кисәргә җибәрәләр. Дүрт баланы ятим калдырып, ул агач белән басылып үлә. Күп кан югалтканлыктан, Кукмара больницасында аның гомерен саклап кала алмыйлар. Шул уңайдан авыл халкы тарафыннан язылган “Хисал бәете”ннән өзекләр язып үтәсем килә.

Урман кисәргә билгеләгәннәр,
Басылып үләремне һич белмәгәннәр.
Урман турында һич уйламадым,
Балаларымны күреп туймадым.
Китәргә диеп өстемә кидем,
Кулыма алып, баламны сөйдем.
Ишек алдында йөргән юлларым,
Кара туфракта зифа буйларым.
Зур чыршы ауды аякларыма,
Күзем йөреттем як-якларыма.
Агач астыннан килеп алдылар,
Мине күргәннәр хәйран калдылар.
Кукмара больницасына илтеп салдылар,
Киемнәремне салдырып алдылар.
Зиннур, ашың пешкән булса, балаларың җыелыр,
Каты итеп эндәшсәң дә, аларга авыр тоелыр.
Яз башында тау битендә алдан карлар бетәдер,
Тормадым якты дөньяда, ризыкларым беткәндер.

Бабай булдыклы, тәвәккәл, абруйлы кеше булган. Тегү эшенә оста (өязгә чыккан), берничә умарта асраган. Яхшы ата, бик юньле кеше итеп искә ала аны якыннары һәм авылның өлкән кешеләре.

*Халикова Мәрзия Гатаулловна, онытгы, Юлбат урта мәктәбенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы, 1995 елда мәктәп музеена эшләп биргән истәлек альбомыннан.*

Сугыш беткәч, Зиннур кайта, Фатиха исемле кызга өйләнә. Аларның тагын Мәрүәр, Рәшидә исемле балалары туа. Хәзер бу гаиләдә үскән балаларның хатирәләренә урын бирәбез.

**Юлбат авылында 1942 елда дөньяга килгән Хуҗин Мөхәррәм сөйләгәннәрдән**

Безнең буынга авыр елларны шактый кичерергә туры килде. Ике яшьлек чагымда, 1944 елда, әниемне агач баскач, мин әниемнең үле гәүдәсе өстендә имәргә эзләп йөргәнмен. Әтием Хуҗин Зиннур сугыштан исән кайтса да, беренче группа сугыш инвалиды булып, 1959 елда вафат булды. Ашарга җитмәгән чаклар күп иде, әмма һич тә бирешергә теләмәдек. Үсмер чагымда кыш башында колхоз малларына дип ылыс ташыдым. Берсендә, кайтыр вакыт җиткәч, атым берничек тә кузгалмады. Аны иркәләп тә, үземнең ипием белән кызыктырып та, әйдәләп тә файда булмады. Атым мине кырыслыкка мәҗбүр итте: астына азрак салам салып ут төртергә туры килде моның. Һәм… атым алып чапты, авылга кадәр туктамады, чыгымчыламады башка.

Мәктәпне тәмамлагач, китаплардан үзлегемнән электрик-монтер һөнәренә өйрәндем, документ алырлык дәрәҗәгә җиттем.

1959 елда булса кирәк, мин Юлбатта һәм Тенекидә ут керттем. Халык су тегермәннәре урынына электр моторы белән эшли торган тегермәннән файдалана башлады. Кул белән такта ярулар да бетте, чөнки колхозда такта яру цехы ачылды. Колхозга һәм шәхси хуҗалыкларга бу бик кирәк иде. Урамнар яктырды, өйләребез нурланды. Мин көндез такта яру цехын эшләттем, тегермән тарттырдым, кичен сәгать 5 тән 11 гә кадәр өйләрне яктырта идек. Бу чор зур этәргеч еллары булды, механизаторларга да яхшы мөмкинлекләр туды.



Подстанция бинасы. 2012 елдагы фото

Электр керткәндә өйгә кайтмый калган көннәр дә була иде, андый чакта әни сеңлем Рәшидәгә эмаль савыт белән аш биреп менгерә торган иде, кечкенә сеңлем тоткан савытның төбе җиргә тиеп-тиеп менә иде. Подстанцияне табигый таштан шулкадәр нык өйгәнбез, ул сүтелгәнче, 2012 елларгә кадәр, яхшы сакланган иде, олыгайгач, авылыма кайткан чагымда, шул кадерле корылманың ташларын сыйпап уза торган идем.

Тенеки халкы авылны электрлы иткәнгә миңа рәхмәт укыганда, мин күңелдән генә: "Нишләп шундый зур эшне эшләмәскә, ди, мин бит сезнең тәмле сөт-каймакларны авыз итеп буын ныгыткан, көч җыйган егет", – дия идем, чөнки Мәртенгә кызлар озатырга йөргәндә, табигый суыткычка – чишмәгә куелган катык, каймаклар белән бик рәтләп кенә, апайлар рәнҗемәслек итеп, сыйлангалаган булды.

Гомер Яшел Үзән районы Васильево бистәсендә үтсә дә, гел авылны сагынып яшәдем, авыл өчен тагын берничә файдалы эш башкардым. Үзем 22 ел эшләгән "Мостопоезд – 33" оешмасы җитәкчесе Захарченко янына туган авылыма күпер төзетүне сорап 11 тапкыр кердем, ышандыра алдым. Ә бит күмәк хуҗалыкны бай дип әйтеп булмый иде, үҗәтлек ярады, нык булмаган агач күперләрне (Юлбатта, Тенекидә) заманча корылган куәтлеләренә алыштырдык, прораб Кардюков Сергейга да рәхмәтлебез. Пенсиягә киткәндә, шундый прогресс булып саналырлык эшләрнең эчендә кайнавым белән горурланам. Күперләрнең проектларын эшләткәннән соң, "КрАЗ"ым белән төзү өчен кирәкле материалны да ташый алуым бик яхшы булды, кешеләргә игелек кыла алуыма куанам.

*Халикова Мәрзия язып алды.*

### Тырмачы Рамазан

Шигырь алда сөйләнгән Мөхәррәмнең 1933 елда туган абыйсы Зиннуров Рамазан турында.

Аталар – сугыш кырында,
Малайлар – иген кырында.
Кискен барды ул чак алыш,
Бигрәк ачы булдың, язмыш.

Авызында сөте кипмәгән,
Кулларында әнә дилбегә.
Бармы кеше хәсрәт чикмәгән?
Күтәрелә халык ил белән.

Атын әйди малай, ул тырмачы,
Тагын күпме җирләр эшләнде!
Ризык соравыңнан, карын, туктачы,
Бар күзләрдә… сагыш төпләнде.

Вика онын пилоткага салып
Тоттырдылар хезмәт көненә.
Өйгә төшкән чакта арып-талып,
Ялмамыйча шуны түз менә!..

“Ялап-ялап кына кайтсам да,
Калмас иде моның бөртеге.
Аш пешереп, бергә ашыйк, дидем,
Булыйк исән, калыйк без тере”.

Сугыш башланганда сигез яшьлек
Рамазан абыем бу.
Сабак белән гыйбрәт алып яшик,
Хәтер, һәрчак уяу бул!”

*Мәрзия Халикова. 12.06.2014*

## “Ат җене кагылган” Мәрүәр

*(Сеңлесе Рәшидә сөйләгәннәрдән)*

Абыйның ат белән “җенләнүе” шуннан башланган: әти (Зиннур) авылда янгын сүндерү отрядын җитәкләгән, аның кул астында бик яхшы ике аты булган. Берсенең исеме Кашемир, икенчесенеке – Кара бия. Әтигә ияреп эшенә баргалаганда, абый аларны яратырга өлгергән, яхшы ат белән эш итәр өчен кыю, көчле булырга кирәклеген төшенгән. Әтинең кул астында эшләгән Сафин Әхәт һәм Мәрдәнов Фәйзи абыйлар да кечкенә Мәрүәрнең атка мөкиббән китүен шул вакытта ук күреп алганнар, ат “күңелен яулауның” серләрен өйрәткәннәр.

Гел ат тирәсендә бөтерелгәч, абыйның үзенә дә күп эләккән дүрт аяклы дусларыннан. Бервакыт ат тибеп маңгаен бик каты ярган булган. Ул вакытта шифаханәгә бару юк бит инде, күрше-тирә, бу бала савыга алмас, дип “диагноз куйган”. Бәхеткә, яра чагыштырмача тиз арада төзәлгән. Күрше Мәрфуга әбинең: “Ат җене кагылган инде бу балага, шуңа гына төзәлде маңгае”, – дигәне исемдә калган.

Бу вакыйгадан соң өлкәннәр, ат янына бүтән бармас Мәрүәр, дип уйлаган булганнар, ләкин ул атларга тагын да ныграк сырышкан. Сабантуйда ат чабышларында бик кечкенәдән узышып, өлкән яшькә җиткәч тә бу мавыгуын ташламады. Ә беренче тапкыр ярышта катнашуы турында мин әнием Фәтиха сөйләгәннәрне генә хәтерлим: “Өйдәге эшләрне тәртипләп, соңлап кына авыл Сабан туена барырга чыктым. Минем алда гына бер пар сөйләшеп бара. Аларның сөйләшүләре миңа ачык ишетелә. Ат чабышы турында сөйләшәләр: “Бер бәләкәй генә малай, ат өстенә ничек менә алган диярсең, ат чабышында беренче килде. Ат җене кагылган малайдыр инде ул, аты да бик яхшы. Килеп җиткәч, ул баланың ат башыннан озын мыеклы бер абзый тотып алды, үзенең күзләреннән яшьләре тәгәри, әтиседер инде ул аның”,– диләр. Мыеклы абзый дигәч, улыбыз Мәрүәрдер, дип



Зиннуров Мәрүәр. 2002 ел

уйладым, һәм шулай булып чыкты да".

Сугыштан соңгы елларда атлар төп эшче көч тә, транспорт чарасы да иде бит. Ләкин бу эшләрне башкарганчы, атны "өйрәтергә" кирәк, үстердем дә эшләтә башладым түгел. Ә яшь атлар тәртә арасына керергә атлыгып тормаганнар. Аларны буйсындыру өчен көчле, куркусыз кешеләрнең зур тырышлыгы соралган. Менә шушы хезмәт "Ат өйрәтү" дип аталган да инде. Бу эшкә иң оста кеше Мәрүәр абыем булган дисәм, зур хата ясамамдыр, мөгаен.

Элек колхоз җитәкчеләре иң яхшы атларда йөриләр иде. Рәис өчен колхозда яхшы айгыр бар, тик өйрәтелмәгән, бер дә җигелмәгән булган. Ул вакыттагы колхоз рәисе Вәлиев Миңлегали: "Энем, өмет синдә, булса, синнән генә була, өйрәт шушы айгырны җигәргә", – дип абыйга мөрәҗәгать итә. Ат бик усал, беркемне дә якын китерми, сыртына атлану турында уйлыйсы да юк. "Бер сыртына утырсам, төшмим инде, ләкин ничек утырырга",– дип уйлый икән абый. Шуннан соң ул, ат торагының түшәменә менеп, айгырның сыртына сикергән, ялларына ныклап ябышкан. И тотынган ат сикерергә, үрәләй сикерә, стеналарга китереп бәрә, ди. Ат күпме генә ярсыса да, буйсынмас малкайның ялыннан урап тотып, шунда утырган Мәрүәр. Тора-бара айгыр үз хәле белән килешкән. Хәзер, җаен туры китереп, йөгән киертәсе генә калган. Монысын да эшләгән ул ат өстендә утырган килеш кенә һәм атны басуга алып чыгып киткән. Шулай итеп, кыш көне басуда тирән карны ерып җигәрлек итеп өйрәткән айгырны "ат җене кагылган" Мәрүәр.

## *Тыл ветераннары истәлекләре*

### Болар кечкенә диеп тормады, балачакны сугыш урлады

Әбием Хаҗиева Әлфинур Нәгыймулла кызы 1926 елның 6 гыйнварында Юлбат авылында дөньяга килә. Сугыш башланганда аңа нибары 15 яшь була. Әтисе Нәгыйм Сафиулла улы сугышның беренче көннәреннән үк фронтка китә. 1942 елның июлендә абыйсы Мәүлетҗан да сугышка алына. Бөтен авырлык әбиемә һәм аның энесе Хәкимгә кала.

1942 елның көзендә әбиемне ФЗӨгә җибәрәләр. Монда да аны авыр сынаулар көтә. 6-7 айдан, ФЗӨ таралгач, авылга кайта. Озак тормый, Юдинога баржа бушатырга китә. Баржа бушату, урман кисү кебек авыр эшләрне башкара яшь кыз. 15-16 яшьтә Юдинодан Шәмәрдән бистәсенә җибәрелә. Шәмәрдәндә дә шундый ук авыр хезмәт көтә.



Хаҗиева Әлфинур

1944 елның ноябрендә әбием һәм аның иптәш кызы Галләмова Зәйнәп урман кисәргә китәләр. Ләкин Зәйнәп авырып китә һәм аны Кукмара хастаханәсенә җибәрәләр. Икенче көнне, иптәш булмау сәбәпле, әбием урманга бармыйча кала, шунлыктан аны кулга алалар. Землянкада күргәзмә суд ясала. 5 елга хөкем итәләр. Төрмәдә аны яңадан-яңа сынаулар көтә: 5-10 кубометр урман кисү, кышларын сал саллау. 5 ай гомере шулай уза. 1945 елның 6 маенда әбием туган йортына кайта. Әбием кайтып 3 көн узуга, шатлыклы, күптән көтелгән хәбәр килә: сугыш беткән.

Сугыш беткәнгә быел 65 ел. Ләкин сугыш һәм тыл ветераннарыбыз бу дәһшәтле сугыш елларының һәр көнен, һәр сәгатен бүгенгедәй хәтерлиләр. Әбиемнең күңелендә сугыш хатирәләре әле дә саклана. Безнең арабызда әби булганга сөенеп бетә алмыйм. Ул һәр ризыкның, һәр тыныч көннең кадерен белегез, дип әйтә. Без, егерме беренче гасыр балалары, шушы иркен, тыныч тормышта яшәвебез өчен бары тик кадерле, хөрмәтле ветераннарыбызга бурычлы.

*Хаҗиева Гүзәл, оныгы, 2010 ел.*

**Шакирҗанова Корбанбикә**



Шакирҗанова Корбанбикә

Кулымда – гади генә альбом. Битләре саргаеп, фотосурәтләре таушалып бетсә дә, ул безнең гаиләнең иң кадерле ядкарьләреннән берсе булып тора.

Менә әбиемнең яшь чагы... Туганнары, дуслары... Бабамның үсмер егет чагында төшкән фотосурәте, солдат формасы белән төшкән фоторәсеме...

Әбиемә сорау арты сорау яудырам. Үзенең авыр сугыш елларына туры килгән балачак истәлекләрен сөйләгәндә әбием моңсуланып калды.

– Без күргән авырлыкларны башка беркемгә дә күрергә язмасын, – дип башлап китте ул сүзен.

Әбием Шакирҗанова (Исламова) Корбанбикә Шәйхелислам кызы 1931 елның 25 мартында Юлбат авылында туа. Юлбат мәктәбендә дүртьеллык башлангыч белем ала. Аннан Сатыш җидееллык мәктәбендә укый башлый. Сатыш авылына укырга киткәнче, төннән торып, туң кар өстеннән күрше Йосыф-Алан авылы янындагы урманга барып, бәләкәй чана белән утын алып төшә торган була. Ан-

нан соң гына өч чакрым ераклыктагы авылга укырга чыгып йөгерә. Әбием җиде класс белем ала. Аннан соң колхозда эшли башлый. Ул елларда яшь кенә кызга төрле авыр эшләрдә катнашырга туры килә.Үзеннән шактый өлкәннәр белән Иштуган станциясенә вагон төяргә йөри. Авыр бүрәнәләрне вагонга аркан белән тарттырып төягәннәр алар.

– Галләмова Зәйнәп, Мөбәрәкшина Сәвия, Сәләхова Гыйльминурлар белән урман кисәргә йөрдек,– дип искә ала әбием. – Участокка барып эшне башлагач, ничә яшьтә булуымны сорадылар. Иптәшләремнән шактый кече икәнне белгәч, эшләтмичә, паеклык икмәкне дә бирмичә, кайтарып җибәрделәр. Авылга кайтып, хәлне колхоз рәисенә аңлатып бирдем. Ә ул ачуланды гына: – Яшеңне әйтмә, барыбер җибәрәбез, – ди.

Яшь кенә кыз бала өлкәннәр белән лобогрейкада эшли. Калын-калын арыш учмаларын әйләндереп төшерер өчен күпме көч-куәт кирәк булгандыр аңа! Һәркөн иртәнге өчтә лобогрейка пычакларын кайратып алып килү вазифасын да, яшь, җитез кыз диеп, әбиемә йөклиләр.

– Колхоз мастерскоенда кайракны тумыштан сукыр булган Хуҗин Гобәй абый кул белән әйләндерә, ә Исламов Ихсан абый пычакны кайракка тотып тора. Шул пычаклар әзер булуга, мин басу түренә алып йөгерә идем,– дип сөйли ул.

Ашлыкны көлтәгә бәйләп чүмәләгә куялар. Кипкән ашлыкны сугар өчен сложная молотилка чыга. У вакытта алар, басудан кайтмыйча, кырда кунып эшлиләр. Төнге 12гә кадәр молотилкада эшли. 2-3 сәгатькә генә чүмәләгә баш төртеп йокымсырап алалар. Таң яктысы беленү белән, тагын эшкә тотыналар. Тыл ветераны – әбием Корбанбикәнең 46 ел хезмәт стажы бар. Авыр сугыш елларында үткән бәхетсез балачагы, сугыштан соңгы авыр елларга туры килгән яшьлек еллары аның хәтеренә бик тирәнгә уелып калган.

“Сугыш” сүзен китаплардан гына укып беләбез, аның никадәр куркыныч булуын күз алдына да китерә алмыйбыз. Бүгенге тыныч тормышыбыз өчен бабаларыбызга, аларның әтиләренә бурычлыбыз. Алар безгә бу тормышны үзләренең гомерләре, сәламәтлекләре бәрабәренә яулап алганнар. Ул вакытта сугыш җиле кагылмаган бер генә гаилә дә булмагандыр. Бабамның әтисе Шакирҗан да 1942 елда Смоленск тирәсендә барган сугышта һәлак була.

*Шакирҗанова Ләйлә, оныгы*

### Гөлшикәр әби сөйли



Гөлшикәр әби

Ирләр сугышка киткәч, авылдагы барлык эшләр хатын-кызлар җилкәсенә калды. Мин үзем лобогрейкада эшләдем. Ашарга юк, ачка үлмәслек көндәлек ашау, шул көе бер караңгыдан икенче караңгыга чаклы эшлисе. Өйдә урын өстендә ята торган әнкәй, кечкенә балалар, шуларны ялгыз калдыра идек.

1943 елның кышында Апас районы Йомралы авылы янында окоп казуда булдык. Кәбир абый, Гыйният

абый, Габделбәр абый, Шәймәрдән Әлмие, Бадиков Сабир, Гайниҗамал, Галләм, Гамбәр, мин – 9 кеше бер группада идек. Авылдан 12 км җир барып, сәгать алтыдан эшли башлый идек, кич алтысыз кайтармыйлар. Аяк юеш, бер кечкенә өйдә аны киптерергә урын юк, бау сузып, шунда асып куя идек аяк киемнәрен. Безнең авылда клубта эшләүче Саба кызын да операция ясаганнан соң терелмәгән килеш окоп казырга җибәргәннәр иде, ул шунда үлеп калды.

Фатир хуҗасы әйбәт кеше булды, нәрсә генә ягып булса да, без кайтканчы өйне җылытырга тырыша иде. Идәнгә калын итеп салам таратып, шунда йокладык.

*Язып алды: Рәхимуллин Марсель, 1994 ел.*

## Йөзьяшәр Вазифа



Вазифа әби 100 яше тулган көндә

23 гыйнварда Тенекидә яшәүче Вазифа Галиева бик сирәкләр бәхетенә тия торган бер гасырлык бәйрәмен – 100 яшен тутырды. Йөзьяшәр әбине юбилее белән котларга өй тутырып балалары, оныклары җыйналды.

Берничә ел элек әби күрү бәхетеннән мәхрүм калса да, дөнья матурлыгын, тормыш бөтенлеген күңел күзе аша кичереп яши. “Дөньяның җәннәтендә яшим, улларым – алтын багана, кызларым – йөзек кашы”, – ди Вазифа әби. Озак яшәвенең серен дә нужа күрә-күрә организм ныгуында күрә. “Орчык кадәр генә булсам да, урманын да кистек, окоп та кызыдык, вагон да төядек, 21нче елгы ачлык михнәтләрен дә күрдек, күрмәгән калмады”, – ди ул, авыр сулап. 1943 елда сугыштан бер аяксыз кайткан Тенеки авылы егете Галимҗан белән гаилә кора Юлбат авылы кызы Вазифа. Балалары – Тайфә, Мәфтуха, Муллаян туа. Олы кызы Тайфә 43 яшендә хуҗалыкларында чыккан янгында вафат була. 2009 елда төп йортта яшәүче Муллаян абый да каты авырып үлә. Бүген исән-сау кызы Мәфтуха Теләче районы Балыклы авылында яши.


Йөзьяшәр әбине бер гасырлык бәйрәме белән Саба муниципаль районы башлыгы Рәис Миңнеханов тәбрикләп, Россия Президенты В.Путинның һәм Татарстан Республикасы Президенты Р.Миңнехановның Котлавын, бүләкләр тапшырды. “Сезнең буынның тырышлыгы нәтиҗәсендә шундый тормышларга ирешкәнбез, инде үзегез игелеген күрегез”, – диде район башлыгы. Шулай ук юбилярны район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Таһир Шәрәфиев, социаль яклау идарәсе начальнигы Марсель Хуҗин, Юлбат җирлеге башлыгы Талип Шәмсиев, Юлбат авыл хуҗалыгы предприятиесе җитәкчесе Илфат Мөхәммәтов котлап, изге теләкләрен җиткерделәр. “Мине зурлаганыгыз өчен Аллаһ үзегезне зурласын, икмәкне мул, түбәләрне нык кылсын”,– дип кат-кат

теләде гасыр кичкән әби. Бүген алар бер йортта дүрт буын вәкиле – 37 ел дустату гомер кичергән килене Гөлфия, оныгы Марат гаиләсе, оныкчыклар яши.

Яктылык – кояш янында, яхшылык – ана янында, ди халкыбыз. Кызы Мәфтуха, үзенә дә 67 яшь булса да, һаман әнисе җылысына тартылып, аның барлыгына куанып яшәве хакында сөйли. "Үскәндә әни янында иркәләнеп ятарга вакыт тимәде, әни гел эштә булды, әти бер аяксыз булгач, төннәр буе сызлана, әнинең керфек какмый уздырган төннәре күп булды, әнинең бар рәхәте картлыгына калган", – ди Мәфтуха апа. Мондый бәхет бөтен кеше өлешенә дә тими. Юкка гына картлыгың хәерле, имин булсын дип теләмиләрдер.

*"Саба таңнары" газетасыннан.*
*31 гыйнвар, 2014 ел*

**Юлбат тыл ветераннары**



Сәләхов Ибраһим




Габделхаев Насих




Шәрифуллин Нурулла



Халиков Мехәммәтхан



Хаҗиев Муллахмәт



Хәлилов Сәетгали



Галимҗанов Хәниф




Фәтхриев Рухылбаян



Гәлләмов Гыйлемхан



Мәрдәнов Хәбибрахман



Гайфуллин Вәлимөхәммәт



Шәмсиев Һарун



Галиева Маһирә



Ибәтуллина Рәшидә



Әхмәтҗанов Кәбир

## *Комсомол тормышыннан*

1922 елда Сабада волость каршында партия-комсомол ячейкасы төзелә. Бу ячейканы төзүдә Урта Саба авылының хат ташучылары Галимулла һәм Гыйльмулла Әхмәдуллиннар башлап йөрүчеләр булалар. Шул чакта Дәүләтшин Мансур абый Юлбат, Мәртен, Туктар, Килдебәк авыллары аша зональный хат ташучы буларак, Әхмәдуллиннар белән таныша. Алар Мансур абыйга комсомолга керергә булышалар. Мансур абый 1926 елда шул оешмага член итеп кабул ителә.

1929 елда Юлбат авылында зональный партия – комсомол ячейкасы төзелә. Шул оешмада 17 кеше учетта тора. Шулардан бер ВКП(б) члены – ячейканың секретаре (Юлбат авылыннан Гомәров Гаффар), ике кеше – ВКП(б) членлыгына кандидат (Туктар авылыннан – Кадыйров Газыйм, Хәсәнов Фәсхетдин). Юлбат авылыннан бер генә комсомол – Дәүләтшин Мансур оешма члены була.

Мансур абый күп кенә җаваплы эшләрдә эшли: авыл Советы председателе, артель председателе, урманчылыкта, уполминзагта, заготконторада һ.б.

1929-1931 елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. 1941-1945 елларда Бөек Ватан сугышында катнаша. 1927 елдан профсоюз члены, 1945 елның августыннан КПСС члены.



Чордаш комсомоллар (уңнан) Галләмов Гыйлемхан (1933 елда туган), Фатыйхов Вазих (1940 елгы), Кәримов Рифкать (1940 елгы), Рәхмәтуллин Камил (1936 елгы), Галләмов Ибраһим

Укытучы Чутаева Шәмсия апа истәлекләреннән.

Мин Юлбатка 1937 елда килдем. Ул елларда комсомол секретаре Мөбәрәкҗанов Кыям иде. Ул вакытта авыл Советы председателе дә булып эшләде. Сугыш башлангач, сугышка китеп, шуннан әйләнеп кайтмады.

1940 елдан башлап, сугыштан соңгы чорларга кадәр комсомол секретаре булып Мифтахова Сара апа эшләде.

**Комсомолга – 50 ел (1968 ел)**

Колхозны комсомол оешмасы 78 ВЛКСМ членын берләштерә. Ул елларда комсомол секретаре булып эшләгән Мәүлина (Вәлиева) Рәфкыя апа сөйләгәннәрдән:

– Комсомол активистлары: Гайфуллина Рабига, Хәмитов Рәшит, Кәримов Рифкать, Фатыйхов Вазыйх, Фәтхриев Фатих, Хаҗиев Илдар, Гомәрова Нәсимә һ.б. Комсомоллар белән авылларга барып спектакльләр куеп йөри идек. “Язылмаган законнар”, “Күрше кызы Фәния” исемле спектакльләр куйганыбызны хәтерлим. Өмәләрдә актив катнаша идек. Аеруча истә калганы Вьетнамга ярдәм акчасы җыю булды. Акча җыюны оештыруда актив катнашкан өчен ВЛКСМның миңа тапшырган истәлек бүләге бар.

Алдынгы комсомоллардан тавык караучы Суфия Гыйззәтуллина, сыер савучы Рәисә Гәрәева, тракторчы Рафаэль Галиев, шофер Азат Хуҗин, комбайнер ярдәмчеләре Рәфис Фәсхетдинов, Ринат Гайфиев кебек эшчәннәребез бар иде. Колхозның ирешкән уңышларында аларның да өлешләре зур.

Комсомолларның үз белемнәрен күтәрү өстендә эшләүләрен күрсәтүче мисаллар да бар. Мәсәлән, Наил Галиев, Рәис Мөбәрәкҗанов, Азат Хуҗин кичке урта мәктәптә укыдылар. Терлекче комсомолкалар Мөслимә Гомәрова, Рәкыя Хуҗина, Тәслимә Идрисова һәм Мәүлидә Сибгатуллиналар Минзәлә совхоз-техникумында белем алдылар.

**Комсомолга – 60 ел (1978 ел)**

Комсомол оешмасы 59 членны берләштерә. Комсомол оешмасы секретаре булып Илзирә Мөбәрәкова (Шекше авылыннан килгән китапханәче) эшли. Ракова Саҗидә апаның “Җиңү байрагы” газетасының №76, 24 июль, 1978 ел санында басылган “Яшьлегемә кайтканда” дигән автобиографик очеркында ул елларның комсомоллары турында түбәндәге юллар бар. “Комсомолларның күпчелеге – производствоның иң җаваплы тармакларында намус белән эшләүчеләр. Механизаторлар – 16 егет. Беренче бригада тракторчысы Насих Хәлиловның кулы җиңел булды. Язгы чәчүдә ул беренчеләрдән булып вымпел алып, социалистик ярышны башлап җибәрде. Газинур Сәйфуллин тракторчы иде, сварщик һөнәрен үзләштерде, Наил Сәйфуллин шундый ук оста куллы, быел ул культуралы

көтүлектә су сиптерә. Комсомолец Илгиз Гыймадиев – товарлыклы-сөтчелек фермасы мөдире. Фәһеметдин Хисамиевны бәрәңге игү звеносы җитәкчесе итеп билгеләделәр. Ринат Сафин – машина-трактор паркы мөдире, коллективта хөрмәт ителә, уйлап эшләүчән. Ризәлә Кәшипова, Гүзәлия Гомәрова, Рузилә Саттарова – урта белемле, класслы терлекчеләр, сөт савып алуда еллык йөкләмәләрен комсомол туган көнгә үтәү өчен ярыш башлап җибәрделәр. Бу иптәшләр авыл Советы депутаты буларак та актив җәмәгать эше алып баралар. Комсомолның 60 еллыгы хөрмәтенә агач утырту буенча өмә оештырылды. Яшьләр тарафыннан 616 төп җиләк-җимеш, 1300 төп декоратив агач утыртылды.

ВЛКСМның XVIII съезды алдыннан комсомоллар Ленин зачетлары тапшырдылар: Илшат Мөбәрәкшин, Тәфкил Зәйнуллин, Расим һәм Рөстәм Мөбәрәкҗановлар, Шамил Галиев, Һашим Абдуллиннар бу эштә актив комсомоллар булдылар.

Хәзерге заман яшьләренә карап күңел соклана, аларның эше һәм тормышы шатландыра. Шулай соклана белү – үзе яшьлекнең бер дәвамыдыр инде ул”.

Алдагы елларда район газетасының штаттан тыш хәбәрчесе Саҗидә апа Ракованың очеркы тулысынча китерелде. Бу нинди максатны күздә тотып эшләнде соң? Беренчедән, егерменче гасырның сиксәненче еллары комсомолларының, Такташ әйткәнчә, “нинди хисләр белән янганнар”ын, нинди максатлар, омтылышлар белән яшәүләрен, илебез тормышында нинди урын алып торуларын бүгенге – комсомол сафларында торып карамаган – буынга аңлату өчен. Икенчедән, өлкән буын кешеләренең ул вакытта яшь буынга мөнәсәбәтен күрсәтү өчен. Минемчә, бу очеркта яшьләрнең хезмәте белән горурлану да, эшләрен бәяләү дә, аларга булган ышаныч та, өлкәннәрнең яшьләрне үзләренең дәвамчылары итеп тануы да ачык чагыла.

**Комсомолга – 70 ел (1988 )**

Комсомол оешмасы 57 комсомол членын берләштерә. Комсомол секретаре – Фәнил Мансуров. Ул сөйләгәннәрдән:

– Комсомолларның 20се – механизатор, 6сы – терлекче, 11е – укытучы, калганнары – колхозда төрле эштә эшләүчеләр. Комсомолның 70 еллыгы уңаеннан Габделхаев Айдар (шофер), Вәлиева Нәзилә (савымчы), Галәвиев Илһам (тракторчы), Хәлилов Насих (тракторчы), Мансуров Фидаил (шофер) колхозның мактау грамоталары белән бүләкләнделәр. Комсомол ветераны Саҗидә апа “ВЛКСМ Үзәк Комитетының 70 еллыгы” медале белән бүләкләнде.

Комсомоллар – спорт һәм җәмәгать эшләрендә башлап йөрүчеләр. Быел кышкы спартакиада уеннарында актив катнаштылар. Бигәнәйдә узган ярышта Сабиров Хәлил җитәкчелегендә I урын яулап, абсолют батыр калдылар.

Комсомоллар культура йорты белән ныклы элемтәдә торалар. Концерт, спектакль, КВНнар җанлы, хәзерлекле уза. Өч авылда да ялгыз әбиләргә шефлык

итәләр. Юлбат авылында – Факиһә, Тенекидә – Хөснури, Йосыф-Аланда Бибиниса әбиләрнең утынын кисеп, ярып бирделәр.

Комсомоллар – өмәләрдә башлап йөрүчеләр. Шундый өмәләрнең берсе – Юлбат зиратын чистартуны әйтергә була. Комсомоллар Тенеки авылы зиратында күмелгән Әфганстанда һәлак булган Илгизәр Харисов каберен хөрмәтләп карыйлар, бәйрәмнәрдә веноклар куялар. Юлбат авылындагы обелискка, комсомол оешмасы җитәкчелегендә, Юлбат сигезьеллык мәктәбе укучылары шефлык итә.

1988 елда, илебез комсомолы үзенең 70 еллыгын билгеләп үткәндә, оешмадан 3 комсомол КПСС сафларына кабул ителде. Менә кемнәр алар:

1. Мәҗитов Зөфәр (алдынгы тракторчы)
2. Шәмсетдинова Вәсилә (алдынгы тракторчы)
3. Дәүләтҗанов Тәлгат (алдынгы терлекче).

## Авылда комсомол-яшьләр тормышыннан кайбер хатирәләр

Совет чорында комсомол оешмалары һәр мәктәптә, оешмада, колхозда бар иде. Күбесенчә формаль идеологик оешма булса да, яшьләрне тәрбияләүдә комсомолның роле зур булды.



Клуб коймасын тоткач төшкән фото. 1966 ел. Алда (сулдан уңга) Билалов Рифкать, Галиев Наил. Артта (сулдан) Галиев Рафаэль, Мифтахов Хәнәфия, Мансуров Рифкать, Ганиев Мәгъсүм, Рахимуллин Гыйльмулла, Заһертдинов Гыйльметдин

Армия сафларында хезмәт итеп кайткач, мине комсомол оешмасы секретаре итеп сайлап куйдылар. Яшьләр белән төрле кичәләр оештыру, концерт, спектакльләр куюда күп яшьләр актив катнаша иде. Спектакльләр куярга күрше авылларга бару гадәти күренеш булды. Бигәнәй, Сатыш, Тенеки, Мәртен, Туктар, Йосыф-Алан авылларына барулар хәтердә калган.

Алтмышынчы елларда авыл клубы элеккеге мәчет булып, аның ян-ягы шәпшәрә иде. 1966 елда, комсомол өмәсе ясап, клуб тирәсен рәшәткә белән тотып алу бурычы куелды. Өмә ясап, ягъни бушка өч көн эчендә клуб тирәсе рәшәткәләп алынды. Урманнан каен үсентеләре алып кайтып, бакча эченә утыртылды. Мәчет бакчасында обелиск янында үсеп утыручы каеннар – шуннан калган истәлек. Каеннарның күбесен, яңа мәчет төзелгәч, кисеп бетерделәр.

Бу өмә 1966 елның октябрь аенда үткәрелде. Эш беткәч, киномеханик Хөсәенов Ленц истәлеккә фотога төшерде.

*Галиев Н.Т. истәлекләреннән,*
*фото аның архивыннан алынды.*

# *Мәгариф һәм мәктәп*

## Юлбат авылында мәгариф үсешенә кыскача күзәтү

1917 елгы революциягә кадәр Юлбатта хөкүмәт тарафыннан ачылган мәктәпләр булмый. Балалар мулла һәм абыстайга йөреп дин сабагы алганнар. Кайбер авылларда (Юлбатта мәдрәсә булуы турында истәлекләр юк) мәчетләр каршында мәдрәсәләр эшли. Авылда мәгариф нәкъ менә шул мәчет-мәдрәсәләрдән башланган да инде. Россия хөкүмәте рус булмаган халыклар өчен мәктәпләр ачуны тыйган бер заманда муллаларыбыз, үзләренең тырышлыклары белән, татар халкын аң-белемле итүдә төп рольне башкарганнар. Шунлыктан бүген без аларны зур ихтирам хисләре белән искә алабыз.

1917 елдан соң балаларны, яшьләрне укыту мәсьәләсенә игътибар бирелә башлый. Халык мәгарифе комиссары А.В.Луначарский 1917 елның 29 октябрендә Россия гражданнарына мөрәҗәгатендә “Иң кыска срокта гомуми грамоталылыкка ирешү”, гомуми мәҗбүри түләүсез белем бирүне кертүне хөкүмәтнең беренче бурычы итеп игълан итте. Ил күләмендә наданлыкны бетерү буенча эш башланды. Билгеле, бу эш Юлбат авылын да читләтеп үтми. Аерым йортларда балаларны укыту оештырыла.

Кадыйр бай йортында (бүгенге көндә бу нигездә Билалов Рифкатьләр яши), Галиәхмәтов Фарук, Сәләхов Ибраһим (Сәләхов Гәптрәкыйп яши), Вәлишә Барыйларында балаларны, яшьләрне укырга-язарга өйрәтү башлана. Өлкәннәрнең әйтүенә караганда, авылга укытучы булып иң беренче Гаффаров Һарун килгән. Ул тумышы белән Шыңар авылыннан.

1924 елда волбашкарма комитеты утырышы карары белән элек дин сабагы укыткан хәлфәләр яки дин сабагын яхшы укып белем алган кешеләр 11



Иманкулова Газзә

авылда халык акчасы хисабына ачылган мәктәпләрдә укытучы итеп расланалар. Алар арасында Юлбатка билгеләнгән Мифтахетдин Фәхретдинов һәм Тенекигә билгеләнгән Мәймүнә Саттаровалар бар. (фонд 1305, опись 1)

1924 елда авылга укытучы булып Иманкулова Газзә килә. Ул Тәкәнеш районы (хәзерге Мамадыш районы) Вахит авылында мулла гаиләсендә туа. Аның башта әнисе, Газзәгә 3 яшь булганда әтисе үлә. Бертуган абыйсы Мирзагабдулла Газзәне үз тәрбиясенә ала. Әтисе үлгәннән соң Мирзагабдулла авылда мулла булып кала. Абыйсы Газзә белемле, укымышлы булсын дип тырыша, аны укытучылар әзерли торган курсларга укырга бирә. Бу курсларны тәмамлап, ул Юлбатка укытучы булып килә.

Газзә Иманкулова авылда 28 ел балаларга белем бирә. Наданлыкны бетерү, авылга культура кертүгә зур көч куя. Актив комсомол-



1934-1935 уку елында Сатыш җидееллык мәктәбендә укучылар арасында Юлбат балалары да бар. Өстәге рәттә уңнан бишенче – Галимҗанова Камәрия, икенче рәттә уңнан беренче Якупова Хәбирә

ка үзешчән сәнгатьтә дә катнаша. Авылыбыз егете Мөхәммәтҗанов Һадиулланы үзенә тормыш иптәше итеп сайлый. Һадиулла кладовщик (амбар мөдире) булып эшли. Алар 1930 елда өйләнешәләр һәм 1942 елга кадәр бик матур яшиләр. (Алар яшәгән нигездә бүгенге көндә Габделхаева Наҗия яши). Ләкин тормышларының бер почмагы китек – балалары булмый. 1942 елда Һадиулла сугышка китә һәм шул китүдән әйләнеп кайтмый. Газизә ирен гомеренең соңгы көннәренә кадәр көтә.

Газзә Иманкулова бик тыйнак, сабыр, итәгатьле, тырыш укытучы була. Тырыш хезмәте өчен ул 1939 елда "Кызыл байрак" ордены (№ 106214), "1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен" медале, 1952 елда хөкүмәтебезнең иң югары бүләге – Ленин орденына (№214036) лаек була. Гомеренең соңгы елларын Газизә ханым туган авылында үткәрә. Үзен тәрбияләп үстергән Мирзагабдулла абыйсының, сеңлесе Мәрьямнең васыятен үтәп, гомеренең соңгы көннәренә кадәр туган нигезен ташламый, 1988 елда вафат була (Туганы Сафина Ә. хатыннан файдаланып язылды).

Юлбатлылар Газзә Иманкулованы тирән ихтирам белән искә алалар. "Газзә апа шулкадәр игътибарлы, ягымлы иде. Ул безне үз балалары кебек күрде. Кышларын безнең шәлләрне бөркәндереп, бүрек колакчыннарын бәйләп, кирәк булса, үз киемнәрен киертеп җибәрә иде. Аның бер авыр сүз әйткәнен, тавыш күтәреп дәшкәнен хәтерләмим". (Юлбатта яшәүче Шәмсетдинов Камалетдин истәлегеннән). "Газизә апа бик матур итеп киенә белә иде. Аның чигүле кара күлмәген киеп басып торуы бүгенгедәй күз алдында. Бик ягымлы да иде. Дәрестә җиренә җиткереп аңлата белде". (1926 елда Юлбатта туган Мөбәрәкҗанова Нәзирә истәлегеннән). Кадыйр бай өендә Газзә Иманкулова тумышы белән Субаш авылыннан булган Иванов белән бергә укыта. Иванов балаларга рус телен өйрәтә.

Безнең авылда шулай ук Шахмаева Хәдичә (Ташкент), Галимуллин Миннебай (Туктар), Бәширова Вәрихан (Җәнәй), Кәбирова Шәмсенур (Тимершык), Мөхәммәтҗанов (исеме билгесез), Хөршидә (фамилиясе билгесез) укытканнар.

"Кәбирова Шәмсенур тырыш укытучы булуы белән беррәттән зур оештыру сәләтенә ия була, үзешчән сәнгатьтә актив катнаша, авыл яшьләренең үзәгендә тора. Ул шулай ук күрше Тенеки авылында да эшли. Тенекидә бергә эшләгән Бариев Мәсгутькә тормышка чыга. Кәбирова-Бариева Шәмсенур күренекле артист Шамил Бариевның әнисе". (Ногманов Әхмәт истәлегеннән).

1932 елда, Төхбәт бай өен күчереп, авылда беренче мәктәп салына. Балаларны укыту шартлары яхшыра. Бу мәктәптә укытуны Иманкулова Газзә башлап җибәрә. Соңрак ул алда санап киткән укытучылар белән бергә эшли. Мәктәптә шулай ук Нигъмәтуллина Гафифә (Арча, Ташкичү), Хәбибуллин Миңнемулла (Сатыш) укыталар. Санап кителгән бу укытучылар Юлбатта 2-3 ел тирәсе генә эшләп китәләр, төпләнеп калмыйлар. Бәширова Вәрихан авылыбыз егете Мәүлетҗанга кияүгә чыга, әмма сугыш афәте аларны аера. Авылдан киткәч, Вәрихан партиянең район комитетында инструктор булып эшли. (*Саба авылында яшәүче Ногманов Әхмәт истәлегеннән.)*



1932 елда төзелгән бинаның арткы ягында Юлбат башлангыч мәктәбе укытучылары (сулдан уңга) Шляпина Сәлимә, Хаева Шафига, Ракова Саҗидә



Чутаева Шәмсия

1937 елда Юлбат башлангыч мәктәбенә укытырга Чутаева Шәмсия килә һәм, авылда төпләнеп калып, лаеклы ялга чыкканчы (1954 елга кадәр) авыл мәгарифен үстерүдә үзеннән зур өлеш кертә. Чутаева Шәмсия 1910 елның августында Кукмара районы Күкшел авылында туган. Балачагы шул авылда ятимлектә үтә. Алар 7 бала үскәннәр. Шәмсия 5 нче бала була. Түнтәр мәктәбендә җидееллык белем алганнан соң, ул районның Зур Сәрдек мәктәбенә укытучы итеп билгеләнә. Бу мәктәптә 2 ел эшләгәч, кулак кызы булганы өчен укытучылыктан чыгарыла. Бу 30 елның язы була.

1930 елның маенда район мәгариф бүлеге аны укытучыларның белемен күтәрү курсларына җибәрә. Курсларны тәмамлаган яшь кыз Саба районына эшкә килә. Ул Алан-Елга, Туктар мәктәпләрендә мөгаллимә булып эшли. 1937 елда Юлбат егете Сәләхов Гыйльметдингә тормышка чыккач, Шәмсия Юлбат мәктәбендә укыта башлый. Бер үк вакытта директор вазыйфасын да башкара. Шәмсия Чутаева һәм Газзә Иманкулова безнең мәктәптә 15 ел бергә эшлиләр. Алар эшләгән чорда, бигрәк тә сугыш елларында,

яшәү бик авыр була. Шуңа карамастан, алар авыл тормышының үзәгендә булып, хезмәтләрен намус белән башкаралар.

Чутаева Шәмсия тырыш хезмәте өчен 1934 елда Татарстанның алдынгы укытучыларының I съездына делегат итеп сайлана, 1942 елда “Хезмәттәге батырлыгы өчен” медале, 1952 елда “Почет билгесе” ордены, 1981 елда “Хезмәт ветераны” медале һәм күп санлы юбилей медальләре белән бүләкләнә.

Ире Гыйльметдин сугыштан әйләнеп кайтмагач, Шәмсия Абдуллин Гыйнияткә кияүгә чыга. Аның белән 1994 елга кадәр бергә яшиләр (Гыйният абый 1994 елда вафат була).

Юлбат авылы мәгариф тарихын язуда Шәмсия Чутаева сөйләгәннәр зур булышлык күрсәтте.

Ул елларда төп укытучылардан тыш, мәктәптә Гыйльметдинова Мөнәздәһә (Урта Саба), Әхмәтова Наилә (Урта Саба килене) укыталар.


BARLЬQ ILLƏRNEŅ PROLETARLARЬ, BERLƏŞEGEZ!
„Sin yz ileŋne anьŋ dəvlətcelegen kytəry məqsədendə aldьŋqь ilərgə tellsəŋ ikən, xalьqьŋ gramotalьlьqьn kytər, yz ileŋnəŋ kul'turasьn kytər" (STALIN).
AZ BELEMLELƏR MƏKTƏBEN BETEREP CЬQU TURЬNDA
TANЬQLЬQ
ATSSR Məqarif Xalьq Komisariatь
RMB məktəbe.
№
Adres
Bu tanьqlьqnь kyrsətyce
nce jьlda tuqan, 19 ncь jьlda az belemlelər məktəbenə kerde həm kyrsətelgən məktəpneŋ tulь kurslarьn 19 ncь jьlnьŋ beterep cьqtь.
məktəptə uqьqanda Tatarstan Məqarif Xalьq Komisariatь programmasьnda kyrsətelgən belem həm kynegylərne ytte həm əlgereşe tyəndəgecə buldь:
1) Ana tele bujьnca
2) Arifmetika bujьnca
3) Geografia bujьnca
Bu tanьqlьq sьnav komisiasenen 193 qararь nigezendə birelde.
P. U.
Məktəp mudire:
Ajsovetь predsedatele
Məktəp uqьtucьlarь
1.
2.
3.

Азбелемлеләр (ликбез) мәктәбен бетерү турында таныклык. 1937 ел

1948 елда мәктәпкә укытучы булып Гаянова Сафия килә һәм лаеклы ялга чыкканчы балаларга белем бирә. Ул 1926 елның 1 февралендә Саба районы Алан Җөри авылында мулла гаиләсендә туган. Туган авылында башлангыч белем алган. Сатыш тулы булмаган урта мәктәбенең җиденче классын тәмамлаган елны сугыш башлана. Сугыш елларында Сафия колхозда завхоз, бригадир булып эшли. Шулай ук урман кисү, торф чыгару (Киров өлкәсендә) кебек авыр эшләрдә катнаша. Сугыш тәмамлангач, укуын Саба урта мәктәбендә дәвам итә. Казан педагогия училищесына укырга керә. Ике курс укыгач, укуын читтән торып дәвам итә һәм уңышлы тәмамлый.


Гаянова Сафия Фәйзелгаян кызы

1947 елда район мәгариф бүлеге аны Оет башлангыч мәктәбенә укытучы итеп билгели. 1948 елда Юлбатка күчерелә. Укыту дәверендә аңа директор вазифасын да башкарырга туры килә. Тырыш хезмәте өчен “Хезмәт ветераны” һәм “Аеруча хезмәт күрсәткәне өчен” медальләре белән бүләкләнә. 1950 елда Юлбат егете Фәләхов Вагыйзьгә тормышка чыга. Аның

белән 6 бала тәрбияләп үстерәләр. Кече уллары Замир әнисе һөнәрен сайлады, Юлбат урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты, физкультура дәресләре укыта.

Сафия Гаянова Юлбат мәктәбенә башта Иманкулова Газизә һәм Чутаева Шәмсия, аннан Газизова Зөлхиҗә (ул Бигәнәйдә яши), соңрак Шляпина Сәлимә, Ракова Саҗидә, Сәгыйтова Рәшидәләр белән бергә эшли.

1955 елда мәктәпкә Шляпина Сәлимә укытучы итеп билгеләнә. Ул 1924 елда Әгерҗе районының Иж-Бубый авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. 1941 елда туган авылында урта мәктәпне тәмамлый, Казанга укырга китәргә хыяллана. Сугыш аның бу хыялын чынга ашыруга киртә була. Сәлимә авылда кала. Окоп казуда (Апас районында), урман кисүдә, юллар чистартуда катнаша. Зенитчылар әзерли торган курсларда укый. 1943 елда ул Алабуга укытучылар хәзерли торган институтка укырга керә. 1945 елда аны уңышлы тәмамлап, Саба районына эшкә җибәрелә. Педагогик хезмәтен ул Саба урта мәктәбендә татар теле укытучысы буларак башлый. 1946-1951 елларда Төбәк җидееллык мәктәбендә эшли. 1950 елда Юлбат егете Сәләхов Ясәвигә тормышка чыга. 1951-1954 елларда ул Сатыш урта мәктәбендә татар теле укыта. 1955 елда Юлбат башлангыч мәктәбенә күчә һәм лаеклы ялга чыкканчы (1979 елга кадәр) авыл мәгарифен үстерүгә үзеннән өлеш кертә. Ире Ясәви белән дүрт бала тәрбияләп үстерәләр.

1960 елга кадәр Шляпина Сәлимә һәм Гаянова Сафия икесе генә эшлиләр.

1960 елда Юлбатка Ракова Саҗидә парторг булып килә. Ул мәктәпкә директор итеп билгеләнә һәм рус телен укыта башлый. Юлбат мәктәбе Саҗидә Мирза



1966 елның октябрь аенда клуб тирәсен койма белән әйләндереп алу буенча комсомол өмәсе. Арткы планда 1932 елда төзелгән мәктәпнең алгы күренеше

кызы җитәкләгән елларда зур үзгәрешләр кичерә. 1966 елның ноябрендә КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Верховный Советы “Гомуми белем мәктәпләренең эшен тагын да яхшырту турында” карар кабул итә. Шушы карарны тормышка ашыру максатыннан, Юлбат башлангыч мәктәбе коллективы яшь буынга белем бирүне яхшырту өстендә эшли башлый, бер үк вакытта укытуны җәмгыятькә файдалы хезмәт белән бәйләү эше башлана. Укучылар мәктәп бакчасында җиләк-җимеш үстерәләр һәм уңышын җыйныйлар. Көзен колхозга бәрәңге чүпләүдә булышалар, кышын көл җыйнап тапшыралар, яз көне сөяк, макулатура, иске чүпрәкләр, металл ватыклары җыйнауда актив катнашалар. “Мин Юлбат башлангыч белем мәктәбендә 1961-1964 елларда укыдым. Хәреф танырга, укырга, язарга мине Гаянова Сафия апа өйрәтте. Без бер бүлмәдә берьюлы беренчеләр (безнең класс) һәм дүртенчеләр укый идек. Без класста 19 бала булсак, дүртенчеләр 11 бала иде. Шундый шартларда да Сафия Фәйзелгаян кызы безгә ныклы белем бирә алды. Рус телен беренче класстан ук Ракова Саҗидә апа өйрәтте. Сатыш мәктәбенә төшүгә, безнең Юлбатта алган белемнәрне тикшерү, барлау максатыннан рус һәм татар телләреннән диктант, математикадан контроль эш эшләтәләр иде. Бу язма эшләрнең һәркайсын яхшы эшләп сөенүем бүгенгедәй хәтеремдә. Юлбат мәктәбен дә мин гел “биш”кә тәмамлаган идем. Сатышта да укуымны шулай дәвам иттем. Димәк, башлангыч мәктәп миңа һәм башка сабакташларга ныклы белем биргән.

Без җәмгыятькә файдалы хезмәттә дә (ул чакта шулай атый идек) актив катнашып үстек. 3-4 классларда укыганда кыш көне ярыша-ярыша көл җыйдык. Үзебезнең өйләрдәге мичнең учакларын чистарту белән генә чикләнмәдек, башкалардан алда күрше тирәдәге уку яшендә балалары булмаган кешеләргә кереп көл алып чыгарга тырыштык. Фермаларга да шефлык иттек. Терлекчеләр алдында һәм авыл клубында бик еш концертлар куя идек. Икенче сыйныфта укыганда Ф.Кәримнең “Пионерка Гөлчәчәккә хат” дигән күләмле әсәрен яттан укыганда, олы яшьтәге апаларның елап утырганы әле дә хәтеремдә. Әнә шулай мәктәп коллективы бездә сәнгатькә һәм хезмәткә мәхәббәт тәрбияләде”. (Шәмсетдинова Мәгефия истәлегеннән).

Мәктәп коллективы укучыларны Ватанны, туган төбәкне ярату рухында тәрбияли. Һәр мөгаллимә бер түгәрәк алып бара. Ракова Саҗидә музыка, Гаянова Сафия яшь әдәбиятчы, Шляпина Сәлимә чигү түгәрәген җитәклиләр.

Укучылар түгәрәкләргә бик теләп йөриләр, бу шөгыльләр балаларны хезмәткә өйрәтә, сәнгатьне аңларга булыша.

Мәктәп бинасы җитмешенче елларга бик искергән була. Мәктәп директоры Ракова Саҗидә яңа мәктәп салуны бурыч итеп куя. Төзелешкә ул елларда колхоз рәисе булып эшләгән Нигъмәтҗанов Миңлехан Галихан улы зур булышлык итә. Мәктәп бинасын биш бура алып кайтып төзиләр. Аны төзүдә Исламов Мөбәрәкҗан, Мөбәрәкҗанов Раиф, Кәримов Рифкать, Гыйззетдинов Нуретдин, Ибәтуллин Сөләйман, Хаҗиев Муллахмәтләр катнашалар. Яңа бина 1974-1975 уку елына әзер була. Яңа бинада укулар башланып киткәннән соң, коллектив алдына класс кабинетларын җиһазлау бу ры ч ы килеп баса. Һәр класс бүлмәсендә укучыларга уңайлы уку шартлары тудырыла.



1932 елда төзелгән мәктәп алдында төшкән фото. 1967 ел



Ракова Саҗидә һәм Шляпина Сәлимә укучылары белән

Хәзер Ракова Саҗидә Мирза кызы биографиясенә күз салыйк. Ул 1918 елның 12 августында Урта Саба (Шайтан-Елга) авылында Мөхәммәтшакир мулла гаиләсендә сигезенче бала булып дөньяга килә. Яше тулганчы ук атадан ятим кала. Башлангыч белемне туган авылында ала. Беренче укытучысы – Биктимеров Хәсән (күренекле артист Шәүкәт Биктимеровның әтисе). Урта Сабада дүртенче класс булмаганлыктан, абыйлары Саҗидәне Саба мәктәбенә урнаштыралар. Бер ел ярым укыганнан соң, аларны Сатышка күчерәләр. 5-6 классларны Саҗидә Сатышта укып бетерә. Дүртенче класстан башлап, ятим кыз тулай торакта яши, каникулларын туганнарында үткәрә. Җидеелык мәктәпне тәмамлагач, Саҗидә Төбәктә укытучылар хәзерли торган курсларда белем ала. Курслар бетүгә, аны Явлаштау башлангыч мәктәбенә укытучы итеп билгелиләр. Шушы авылда 16 яшьлек кыз хезмәт юлын башлый. Кечкенәләр белән бергә үзе белән бер яшьтәгеләрне дә укытырга туры килә аңа. Кичләрен сәхнәдә, халык арасында була. Явлаштау мәктәбеннән аны Килдебәккә күчерәләр. Анда эшләгәндә Саҗидә читтән торып Арча педагогия училищесына укырга керә. Аны Свердловск шәһәрендә тәмамлый һәм 4 ел Олы Мәтәскә җидееллык мәктәбендә немец теле укыта.



Ракова Саҗидә Мирза кызы

Ватаныбызга фашистлар өере ябырылгач, укытучы кыз Саҗидә Ракова кулына корал ала. Ул 347 нче зенит артиллериясе полкында прожекторчы булып хезмәт итә, башкалабыз Мәскәүне һава һөҗүменнән саклауда катнаша. Сугыштан кайткач, Баландыш, Яңа Мичән җидееллык, Түлешкә башлангыч мәктәпләрендә эшли.

1960 елда Юлбат авылына килеп урнаша, лаеклы ялга чыкканчы (1977 ел) мәктәп мөдире булып эшли. Кайсы гына авылда эшләмәсен, эзе кала аның, сагынып искә алалар үзен. Сәләтле педагог булуы белән бергә, ул күп төрле җәмәгать эшләрен дә башкара. Агитатор, пропагандист, кичләре үзешчән талантлар арасында үтә. Озак еллар “Искра” колхозы партия оешмасы секретаре, агитколлектив җитәкчесе, җиде чакырылыш авыл Советы депутаты, хатын-кызлар советы рәисе хезмәтләрен башкара. 43 еллык хезмәт юлы (30 елы мәктәп директоры) әнә шулай кешеләр арасында, тормышның кайнаган җирендә үтә. Саҗидә Мирза кызы Юлбат мәктәбендә балаларга рус теленнән дәресләр бирә.

1958 елдан башлап Саҗидә Ракова – район газетасының актив хәбәрчесе.

1967 елда “Җиңү байрагы” газетасы редакциясенең Почет китабына кертелә, 1968 елда район газетасының Закир Йосыпов исемендәге премиясенә лаек була. Аның үзе турындагы мәкаләләр дә район газетасында еш басыла. Мәсәлән, Фәүзия Бәйрәмованың “Чын хезмәт кешесе” (18 апрель, 1968 ел), Мөнир Гасыймовның “Йөрәк картаймый”, Илфир Салаватуллинның “Кешеләргә гашыйк ул” (3 май 1977 ел) мәкаләләре шундыйлардан. Ул республика матбуга-



1974-1975 елларда төзелгән мәктәп бинасы

тында да үзенең язмалары белән еш катнаша. Хәбәрчелек эше белән бик яратып шөгыльләнә.

Юлбатта урта мәктәп ачылгач, Саҗидә Ракова дүрт ел "Гарәп графикасына өйрәтү" түгәрәге алып барды. Авылда мәгариф үсеше турында, колхоз тарихы буенча мәктәп музеена материаллар туплауда үзеннән зур өлеш кертте.



Сәгыйтова Рәшидә Сәгыйть кызы

Аның фидакарь хезмәте республика газеталарының күп санлы Почет грамоталары, "Халык мәгарифе отличнигы" значогы белән бәяләнде. Ул II дәрәҗә Ватан сугышы ордены, "1941-1945 елларда Германияне җиңү өчен", "Хезмәттәге батырлыгы өчен", "Аеруча хезмәт күрсәткәне өчен" һәм күп санлы юбилей медальләре белән бүләкләнә. ВЛКСМ Үзәк комитетының "ВЛКСМга 70 ел" билгесе Саҗидә Ракова өчен аеруча кадерле, чөнки ул аңа яшьлеген хәтерләтә.

1977 елда, Ракова Саҗидә пенсиягә чыккач, Сәгыйтова Рәшидә мәктәп директоры һәм рус теле укытучысы итеп билгеләнә. Ул 1931 елның 3 июлендә

Саба районы Тимершык авылында туа. Тимершык җидееллык, Саба урта мәктәпләрендә, Казан педагогия училищесында белем ала. Педагогик хезмәтен Оет башлангыч мәктәбендә башлый. Явлаштау мәктәбендә дә укыта. 1954 елда Тенеки башлангыч мәктәбенә билгеләнә һәм 30 елга якын эшли. 1977 елда Юлбат мәктәбенә күчерелә һәм лаеклы ялга чыкканчы (1983 елга кадәр) укыта.



Хаҗиева Фәния Нургали кызы

1979 елда мәктәпкә укытучы булып Хаҗиева Фәния Нургали кызы килә. Ул 1946 елда туган, Юлбатта башлангыч белем алган. Сатыш сигезьеллык, Саба урта мәктәпләрен, Казан педагогия училищесын тәмамлаган. Ул хезмәт юлын 1966 елда Җөри мәктәбендә башлангыч сыйныфлар укытучысы буларак башлый. 1971-1979 елларда Мәртен сигезьеллык мәктәбендә математика укыта. 1979 елда Юлбат башлангыч мәктәбенә күчерелә һәм 2008 елга кадәр, лаеклы ялга киткәнче, үзе сайлаган хезмәткә тугры калып, кече яшьтәге мәктәп балаларына белем бирә. Фәния Нургали кызы талантлы, тырыш педагог. Ул эшләгән чорда мәктәпне алтын һәм көмеш медальгә тәмамлаган 29 укучының 16 сы белем нигезләрен аның классында алуы гына да Фәния Нургали кызының үз эшенә никадәр җаваплы каравы турында сөйли. Ул 17 ел башлангыч сыйныф укытучыларының методик



Сигезьеллык мәктәп ачылу тантанасы. 1982 ел

берләшмәсе җитәкчесе, 19 ел профком рәисе вазыйфаларын башкарды. Тырыш хезмәте өчен “Мәгарифтәге казанышлары өчен”, “Россия Федерациясенең мактаулы мәгариф хезмәткәре” күкрәк билгеләре, Татарстан Мәгариф министрлыгының, Татарстан Республикасы профсоюз комитетының Мактау грамоталары белән бүләкләнде. Хезмәт ветераны.

1982 ел авыл халкы өчен сигезьеллык мәктәп ачылу белән истәлекле. Мәктәп яраклаштырылган биналарда эшли башлады. Колхоз идарәсе яңа төзелгән ашханә бинасын мәктәпкә бирде. Анда башлангыч класслар, интернат, спортзал, хезмәт мастерское, ашханә эшли башлады. (Ул вакыттагы колхоз рәисе Әхтәмов Гаптелмәннәф Гапсәләмович мәктәп ачылган чорда һәм аннан соң да үзенең эш дәверендә мәктәпкә бик зур ярдәм итте). Авыл Советы үзенең бинасын укытучылар бүлмәсе өчен бирде (хәзерге вакытта шәхси эшмәкәр кибете урнашкан бина). Шунда ук китапханә һәм директор бүлмәсе җиһазланды. Кыска гына вакыт эчендә укытучылар һәм мәктәпнең барлык хезмәткәрләре класс бүлмәләре (алар башлангыч мәктәп бинасында урнашты) һәм башка бүлмәләрне уку елы башына әзерләп бетерде. Мәктәп шул елны яңа уку елына әзерлек буенча район мәктәпләре арасында ярышта җиңүче булды.

Мәктәптә Юлбат, Тенеки, Йосыф-Алан, Калатау укучылары белем ала. 1982-1983 уку елында барлыгы 127 укучы була. 6 класс-комплект, 2 озайтылган көн группасы эшли. (Башлангыч классларда бер укытучы икешәр класс укыта, шунлыктан 1-4 класслар 2 класс-комплект дип йөртелә). Сигезьеллык мәктәпнең беренче укытучылары:

1. Нигъмәтҗанов Рөстәм Нурмиевич – директор, математика укытучысы;
2. Нигъмәтҗанова Венера Хәсәновна – рус теле һәм әдәбияты укытучысы;
3. Хисамиева Фәния Фәттаховна-татар теле һәм әдәбияты укытучысы;
4. Сафин Илдар Фатхуллович – рус теле һәм әдәбияты укытучысы;
5. Хөснетдинова (Шакирҗанова) Фәһимә Гаптелфәтовна-өлкән пионервожатый, математика укытучысы;
6. Исламова Зөлфирә Мөбәрәкҗановна-химия, биология, география укытучысы;
7. Гаязов Мидхәт Хафизович-физкультура, хезмәт укытучысы;
8. Рахимуллина (Фәләхова) Гөлсинә Мехәммәтхановна – тарих укытучысы;
9. Хаҗиева Фәния Нургалиевна – башлангыч сыйныфлар укытучысы;
10. Шакирҗанова (Галимуллина) Дания Гайфетдиновна – башлангыч сыйныфлар укытучысы.

Озайтылган көн группасы тәрбиячеләре: Якупова Рокыя, Сәгыйтова Рәшидә, Гаянова Сафия.

## Нигъмәтҗанов Рөстәм Нурмиевич

Нигъмәтҗанов Рөстәм Нурмиевич – 35 ел гомерен мәктәп директоры эшенә багышлаган югары категорияле җитәкче. 1975 елдан Мәртен сигезьеллык мәктәбе директоры. 1982-1989 елларда Юлбат сигезьеллык мәктәбе, 1989-2010 елларда Юлбат урта мәктәбе директоры.



Нигъмәтҗанов Рөстәм Нурмиевич сигезьеллык мәктәп ачу тантанасында колхоз рәисе Әхтәмов Мәннәф Гапсәләмовичтан символик ачкыч ала. 1982 ел

1982 елда Юлбат башлангыч мәктәбе базасында сигезьеллык мәктәп ачыла, Рөстәм Нурмиевич мәктәпнең материаль-техник базасын булдыру, укучылар, укытучылар коллективын туплау, мәктәп яны интернатын булдыру юнәлешендә эшли.

1989 елда 192 урынга исәпләнгән ике катлы урта мәктәп бинасы сафка баса. Яңа бинага җиһазлар кайтарту, укучылар өчен остаханә җиһазлау, мәктәп яны интернатын төзү, кышкы сезонда ике катлы зур бинаны күмер ягып тиешле җылылыкта тоту, ул күмерне техника табып егерме биш километр ераклыктагы Шәмәрдән станциясеннән кайтарту, укучыларны тукландыру мәсьәләсен үз көче белән хәл итү һ.б. Бу эшләр мәктәп директоры җилкәсенә төшкән вазифаларның иң азы, гади күзгә күренеп торганы гына әле. Укытучылар коллективы белән җитәкчелек тә яңадан-яңа алымнар сорый, чөнки урта мәктәптә эшләүче педагогик коллектив алдына үзгә бурычлар куела: мәктәпне тәмамлаган укучыларны югары уку йортларында укып белем алырга хәзерләү, нинди дә булса профессия бирү, мөстәкыйль тормыш шартларында югалып калмаска өйрәтү һ.б.

Рөстәм Нурмиевич бу бурычларны сабырлык, таләпчәнлек, үзенә генә хас зирәклек һәм акыл белән бер-бер артлы җиңә барды, укытучылар коллективының осталыгын туктаусыз үстерүгә ирешә алды.

Пионер дружинасы районның Советлар Союзы Герое Зәки Хәбибуллин исемен йөртә, дружина советы председателе Әхтәмова Гөлнара. Укучыларның комсомол группасы шулай ук районның Советлар Союзы Герое Иван Башкиров исемен йөртә. Комсомол секретаре – Хуҗина Гөлчәчәк.

Сигезьеллык мәктәп ачылган беренче уку елында сигезенче классны 24 укучы тәмамлый. Менә алар: Әскәрова Нурия, Әхтәмова Лилия, Биктаһиров Рәкыйп, Вәлиев Илнур, Вәлиев Раил, Галимуллина Нәфисә, Дәүләтшин Марат, Җәләлиева Гөлфия, Заһретдинов Рәдис, Зәйнуллин Марсель, Ибраһимов Равил, Сираҗиева Фәймә, Сәетгәрәева Рәхилә, Фәсхетдинов Илдар, Фәттахов Илсур, Фәләхова Рәмзия, Фатыйхов Рәдис, Хәмитов Раушан, Хаев Заһит, Хафизова Энҗе, Хөсәенова Лилия, Хуҗина Мөслимә, Хуҗина Гөлчәчәк, Шиһапов Суфьян. Аларның класс җитәкчеләре 1982 елда Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлап кайткан Сафин Илдар Фатхуллович була.

1984 елда мәктәп яны интернаты төзелеп бетә (хәзерге “Юлбат” авыл хуҗалыгы предприятиесе конторасы урнашкан бина), тәрбияче булып Гаязова Ризәлә Равиловна эшли башлый.

Ашханәдә пешекче булып Таһирова Дания эшләде. Аш-суны тәмле пешерүе белән ул бөтен коллективның, балаларның ихтирамын яулады. “Балалар өчен Дания апа кулинария ризыклары пешерә иде. Балалар алдагы тәнәфестә пешәчәк ризыкларга алдан акча түләп куялар иде” (укытучы Фәләхова Гөлсинә истәлегеннән). Сигезьеллык мәктәптә Гаязова Лилия (Туктар), Мөбәрәкҗанова Гөлнәзирә һәм Сираҗиева Зөлфия (Саба) берничә ел рус теле укыттылар. Муллахмәтова Гөлсинә (Сабабаш), Мусина Җәүһәрия (Түбән Шытсу), Гомәрова Рузия (Тенеки), Яхина Алсу (Саба) озайтылган көн группасында эшләде. 1985



Ашханә, башлангыч класслар, спортзал, остаханә урнашкан бина. 1982 ел



Мәктәпнең 8 класс укучылары дәрестә. Укытучы – Сафин И.Ф. 1982 ел



Сигезьеллык мәктәпнең иң беренче район олимпиадасы җиңүчесе Хабибуллина (Билалова) Лилия. Укытучысы – Фәһимә Гаптелфәтовна

елда озайтылган көн группасына Хәсәнова Рәсимә килә. Шул ук елны мәктәптә рус теле һәм әдәбиятын Юлбатка килен булып төшкән Халикова Мәрзия Гатаулловна укыта башлый. Хезмәт дәресләрен Галләмов Фәрит алып бара. Интернатта тәрбияче булып Ибраһимова Рафига эшли башлый.

Билалова (Хәбибуллина) Лилия, Юлбат сигезьеллык мәктәбе укучыларыннан иң беренче математикадан район олимпиадасында I урын алып, республика олимпиадасында катнашты. Бүгенге көндә Саба гимназиясенең югары категорияле математика укытучысы.

1987 елда мәктәпкә Казан педагогия училищесын тәмамлап Галимҗанова Лилия кайта. Кадыйрова (Сабирова) Гөлсинә өлкән пионервожатый булып эшли, физкультура дәресләре алып бара. Шул ук елны физика-математика дәресләрен

Шәмсетдинова Мәгефия Камалетдиновна, химия, биологияне Хәбибуллина Әлфия укыта башлый.

1989 елның 1 сентябрендә Юлбат сигезьеллык мәктәбе базасында ике катлы яңа бинада авыл тарихында беренче тапкыр урта мәктәп ачылды. Яңа бинаны Нигъмәтҗанов Илдар җитәкчелегендәге Шәмәрдән СМУ-2 эшчеләре төзеде. Гатауллина Нурзия (мәктәп ачылгач пешекче булып эшләде), Рәхимуллина Мөсалия (техник хезмәткәр булып эшләде), колхозчылар Төхвәтуллина Вәсилә һәм Ганиева Мәрьям төзелешнең беренче көннәреннән бина кабул ителгәнче төзүчеләр белән бергә эшләделәр. Укытучылар коллективы да чираттагы елларын яңа мәктәп бинасын төзүдә катнашып үткәрде. Алар бу эшне, өстәмә эш дип кабул итмичә, аеруча күтәренкелек белән башкардылар. 13 класс-кабинет, спортзал, ашханә, китапханә җиһазланды. Мәктәпнең гомуми мәйданы – 1620 кв.м. Беренче елларны укытучылар һәм укучылар көче белән мәктәп тирәсенә агачлар утыртылды.

Урта мәктәптә беренче елны эшләгән укытучылар коллективы белән таныштырып китик. Мәктәп директоры – Нигъмәтҗанов Рөстәм Нурми улы. (Ул Юлбат мәктәбен 1982 елдан җитәкли). Беренче елны эшләгән укытучылар исемлеге: Сафина Рәмзия Габделбәр кызы (укыту эшләре буенча директор урынбасары, рус теле һәм әдәбияты укытучысы), Сөнгатова (Шакирҗанова) Фәһимә Гаптелфәт кызы (тәрбия эшләре буенча директор урынбасары, математика укытучысы), Нигъмәтҗанова Венера Хәсәновна (рус теле һәм әдәбияты), Шәмсетдинова Мәгефия Камалетдиновна (математика, көнкүреш хезмәте), Сафин Илдар Фатхуллович (НВП, җәмгыять белеме), Галимуллина Дания Гайфетдиновна (татар теле һәм әдәбияты), Фәләхова Гөлсинә Мехәммәтхановна (тарих, рус



Урта мәктәп бинасына 1988 елның ноябрь аенда нигез салынды

теле), Халикова Мәрзия Гатаулловна (рус теле, география), Саттарова Рәфисә Фоатовна (физика, информатика), Галимҗанова Лилия Гаптелмәннәфовна (химия, биология), Фәләхов Замир Вагыйзович (физкультура, татар теле), Галләмов Фәрит Равилович (хезмәт), Хаҗиева Фәния Нургалиевна һәм Фатхриева Раушания Хәнәфиновна (башлангыч сыйныфлар), Фәтыйхов Рәдис Вазыйхович (производствога өйрәтү мастеры). Музыка дәресләрен культура йорты методисты Галимов Илсур (Шытсу авылыннан) алып бара. Өч озайтылган көн группасында Низамиева Фирая Фаруковна, Хәсәнова Рәсимә Тимербаевна, Шәмсетдинова Мәгефия Камалетдиновна эшли. Көнкүреш хезмәте укытырга декрет ялыннан соң Баһавиева Рифидә үзе килә. Мәктәп яны интернантында тәрбияче булып Ибраһимова Рафига Закирҗан кызы эшли. Беренче елны 11 сыйныфны 13 укучы тәмамлады. Класс җитәкчесе Фәләхов Замир Вагыйзь улы. Өлгергәнлек аттестаты белән беррәттән, малайларга 3 класслы тракторист-машинист, кызларга машина белән сыер саву операторы таныклыгы тапшырылды. Шушы елны татар теле әдәбиятын укытырга Туктар авылыннан Әскәров Нияз Миннегаянович килде (декрет ялына киткән Галимуллина Дания Гайфетдиновна урынына). Ул 1995 елның августына кадәр берничә төрле фән укытып, Туктар башлангыч мәктәбенә мөдир булып күчте.

1990-1991 нче уку елына озайтылган көн группасы тәрбиячесе һәм җыр укытучысы итеп Ибраһимова Равия Рәфгалиевна билгеләнде.

1991-1992 уку елында район олимпиадаларында Сәйфуллина Ландыш, Билалова Гөлүсә, Ибраһимова Алсу, Мөбәрәкҗанова Әлфия призлы урыннар яулады. Бу уку елында мәктәпкә Фәйзрахманова Рәфисә (физика-информатика, Бигәнәй



Урта мәктәпнең беренче укытучыларыннан бер төркем

авылыннан), Әһелова Нәсфия (көнкүреш хезмәте), Артыкбаева Римма (Саба) һәм Мансурова Энҗе (озайтылган көн группасы) эшкә килде. Район пионерлар йорты каршында гарәп графикасына өйрәтү (Ракова Саҗидә), милли көрәш (Фәтхриев Рөстәм), халык уен кораллары (Галимҗанова Лилия), драмтүгәрәк (Мансурова Сәрия) эшләде. Укучылар "Яшь авазлар" район конкурсында уңышлы гына чыгыш ясадылар.

1992-1993 уку елында КДПИ тәмамлап Фәтхриева Рәйхана (вожатый), Гасимова Әнисә һәм Идрисова Гөлүсә (Саба, озайтылган көн группасы) эшли башладылар. Бу уку елында мәктәптә инглиз теле укытыла башлады. Укытучы – Мәҗитова Рәмзия Габдерәүф кызы. Шул ук елны хезмәт укытырга Хәмитов Раушан килде. Сафин Илдар Фатхуллович, И.Ульянов (Ленин) исемендәге Казан дәүләт университетының тарих факультетын читтән торып тәмамлап, икенче югары белем алды һәм тарих, җәмгыять белеме фәннәрен укытуга күчте.

1993-1994 уку елы. Мәктәп коллективы яңа методик тема өстендә эшли башлады: "Уку, танып белү процессында укучыларның мөстәкыйльлек, активлыкларын үстерү, кешелеклелек сыйфатларын тәрбияләү". Бу проблеманы өйрәнүдә укытучылар коллективы тарафыннан зур эш башкарылды. Стандарт булмаган дәресләр методикасын өйрәтү һәм практикага кертүгә юнәлдерелгән эш алып барылды. Шул ук елны мәктәп базис укыту планына күчте. Берничә яңа фән укытыла башлады. 5, 8, 9, 10, 11 классларда "Татарстан һәм татар халкы тарихы" (Укытучы Сафин И.Ф.), 9-11 класста "Базар экономикасы нигезләре" (Сафин И.Ф.), "Мин һәм минем дөньям" дигән факультатив курс кертелде. (8,9 класста, Сафин И.Ф.). Бу уку елында мәктәптә 4 методист укытучы (Нигьмәтҗанов Р.Н., Нигъмәтҗанова В.Х., Хаҗиева Ф.Н., Шәмсетдинова М.К. һәм 5 өлкән укытучы (Сафина Р.Г., Фәләхов З.В., Сафин И.Ф., Хәсәнова Р.Т., Халикова М.Г.) эшләде. Калган укытучылар да осталыкларын камилләштерә бардылар. (укытучыларның осталыкларын бәяләүдә беренче, икенче, югары квалификация категорияләре 2000 нче елларда кертелде, аңа кадәр аттестация нәтиҗәләре буенча "укытучы", "өлкән укытучы", "методист укытучы" дигән квалификация категорияләре бирелеп килде)

1994 елда районның январь киңәшмәсе Юлбат урта мәктәбе базасында үтте. Ул мәктәпнең иҗат отчеты формасында оештырылды.

1993 елның октябреннән район мәктәпләре арасында беренче булып видеокласс ачылды. Җитәкчесе – Сафин И.Ф. Видеокамера, видеомагнитофон, телевизорны "Искра" колхозы идарәсе мәктәпкә бүләк итте. Председатель – Габдрахманов Наил Афзал улы. Ул елларда үз видеокамерабыз булу мәктәп, колхоз тормышыннан кадрларны истәлеккә калдыру өчен бәяләп бетермәслек мөмкинлек иде.

Мәктәпнең тәҗрибә участогы район мәктәпләре арасында 3 урынга лаек булды. (җитәкчесе – биология укытучысы Хәсәнова Р.Т.)

1994-1995 уку елы. Бу уку елында да мәктәп коллективы шул ук методик тема өстендә эшләвен дәвам итте. Укытучылар коллективында да үзгәрешләр булды. КДПУ тәмамлап Мөхәрләмов Рөстәм Габдулла улы (Килдебәк) география, Исмәгыйлов Илнур Сәлимҗан улы (Сатыш) химия, биология укыта башлады. Информатика укытырга Сатыш урта мәктәбеннән Рәхимов Рәдиф

Мулламөхәммәт улы килеп йөрде. Шулай итеп, барлык фәннәрне дә белгечләр укытуга ирешелде. Икенче классга инглиз телен (укытучы Мәҗитова Р. Р.) һәм 9 класста рус телен (укытучы Сафина Р. Г.) тирәнтен өйрәнү башланды.

Тарих, рус теле укытучыларының август киңәшмәләре безнең мәктәп базасында үтте, уку елы дәвамында укыту-тәрбия буенча директор урынбасарларының, башлангыч класс укытучыларының район семинарлары узды.

1995 ел, 9 май. Җиңүнең 50 еллыгына “Туган якны өйрәнү“ музее ачылды. Җитәкчесе – Сафин И. Ф. Музей ачылганчы экспонатлар укучылар тарафыннан җыелды, әти-әниләрнең бу эштә теләктәшлек күрсәтүе нәтиҗәсендә бай материал тупланды. Җыелган экспонатларны “Туган якны өйрәнү” түгәрәге членнары тәртипкә китерделәр, аларга аңлатма язуларны “плакатный перо”лар белән инглиз теле укытучысы Мәҗитова Р.Р. һәм озайтылган көн группасы тәрбиячесе Низамиева Ф.Ф. язды. (соңыннан, мәктәпләргә компьютер кергәч, Сафина Р.Г. компьютерда язып “яңартты”). Музей 1999 елда республика конкурсында җиңүгә ирешеп, “Мәктәп музее” статусы алып, шуны раслаучы таныклыкка ия булды һәм Татарстан Мәгариф министрлыгы тарафыннан диплом белән бүләкләнде.

1998 елда яңа остаханә сафка басты. Анда ир балалар өчен агач, тимер эшкәртү станоклары куелган, кызлар өчен тегү, кулинария бүлмәләре җиһазландырылган. Мастерскойга берәр яңа агач һәм тимер кыру станогы, бер шомарту (шлифовальный) станок алынды.



Музей күренеше



Технология укытучысы Рәфис Мөбәракҗанов дәрестә

Туксанынчы елларда, урта мәктәп ачылганнан соң, педагогик коллектив эшендә иң элек укытучыларның үз белемнәрен күтәрү өстендә эшен билгеләп үтәргә кирәк. Мәктәптә методик семинарлар завуч Сафина Р.Г. тарафыннан даими үткәрелеп, алдынгы педагогик тәҗрибә өйрәнелеп үз бәясен ала барды. Укытучылар, төрле алымнар кулланып, төрле типтагы дәресләр үткәреп, үзләренең осталыкларын арттырдылар. Мәктәпнең методика кабинетына 1999-2000 уку елы дәвамында гына да төрле типтагы 47 дәрес эшкәртмәсе тупланды. Район мәгариф бүлеге тарафыннан оештырылган семинарлар һәр фән буенча Юлбат мәктәбенә билгеләнде. 2000-2003 еллар дәвамында мәктәптә 18 район семинары үткәрелде. Моңа мәктәп бинасының яңа булуы гына түгел, фәннәрне көчле укытучылар укыту да сәбәп булгандыр.

Укытучыларның үз белемнәрен күтәрү өстендә эшләве нәтиҗәсе педагогик аттестация буенча квалификация категориясе бирелүдә дә чагылды. Мәсәлән, 2006 елга мәктәптә эшләүче укытучыларның өчесе – югары категория, 12 се – беренче, 6 сы икенче квалификация категорияләренә ия иде. Бары тик бер укытучы – яшь белгеч – “укытучы” таләпләренә туры килә дип йөртелде.

Укытучыларның хезмәтләрен бәяләүдә 2001-2006 еллар эчендә дирекция тарафыннан аеруча актив эш алып барылды, чөнки бу вакытта педагогик коллектив методик осталыклары камил дәрәҗәдә булган укытучылардан тора иде. Укытучыларның уңай эшләрен күреп, дирекция район мәгариф бүлегенә бүләккә тәкъдим итеп килде, завуч Сафина Р.Г. вакытында документларны эшләп тапшыру нәтиҗәсендә биш ел эчендә 15 укытучы Россия һәм Татарстан мәгариф министрлыклары тарафыннан үзләренең намуслы хезмәтләре өчен бүләкләнделәр. Шулардан 5 укытучы – “Россия Федерациясе мәктәпләренең мактаулы хезмәткәре” күкрәк билгесе, 1 укытучы – Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән министрлыгының мактау грамотасы, 2 укытучы – Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының “Мәгарифтәге казанышлар өчен” күкрәк билгесе, 6 укытучы – Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының мактау грамотасы белән бүләкләнде. 1 укытучы “Россия Федерациясенең иң яхшы укытучысы” исеменә лаек булды.

Эш нәтиҗәләре укучыларның белемнәрендә дә чагылды. Мәсәлән, 1998 елда район олимпиадаларында 13 призлы урын яуланды. Нигъмәтҗанова В.Х.ның

– өч, Галимуллина Д.Г., Сафин И.Ф., Сафина Р.Г.ның икешәр укучылары призлы урыннар алдылар. Нигъмәтҗанова В.Х., Сафина Р.Г., Галимуллина Д.Г. укучылары, республика олимпиадасында катнашып, беренче унлыкка керделәр (ул елларда республика олимпиадаларында 170-180 укучы катнаша иде).

Ә район олимпиадаларында мәктәп тарихында иң күп призлы урын 1995-1996 уку елында яуланды. Ул елны мәктәп 15 призлы урын яулап, призлы урыннар саны буенча район мәктәпләре арасында өченче урынны алды.

1990-2005 еллар эчендә мәктәпне 195 укучы тәмамлады. Шулардан 124 укучы югары һәм махсус урта уку йортларына укырга керде.

2006 елда Сафин И.Ф. "Өстенлекле илкүләм "Мәгариф" проекты" буенча конкурста катнашып, 100 000 сумлык грантка һәм "Россия Федерациясенең иң яхшы укытучысы" исеменә лаек булды.

2010-2011 уку елында өч укытучы "Наш лучший учитель" конкурсында җиңеп, грантка ия булды. Алар: Шакирҗанова Ф.Г., Галимуллина Д.Г., Сафин И.Ф.

2010 ел Россия күләмендә укытучы елы буларак билгеләп үтелде. Шул уңайдан, һәр фән буенча район күләмендә үткәрелгән "Ел укытучысы" конкурсының икенче этабында җиңеп чыгып, 3 укытучы 10 000 сум күләмендә (якынча айлык хезмәт хакы) призга ия булды. Алар: Мәҗитова Р.Г., Фәләхова Ф.Г., Кәримова Р.Р. Финалга үткән 5 район укытучысы 25 000 сум күләмендә акчалата бүләк алды. Район хакимияте менә шундый бүләк әзерләде мөгаллимнәргә укытучы елы уңаеннан.



Башлангыч класслар укытучысы Фәләхова Гөлсинә Мехәммәтхановна укучылары
һәм аларның әниләре белән

2010 елда Юлбат балалар ясле-бакчасы мәктәп остаханәсенең малайлар өчен булган өлешенә кертелде. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар арту сәбәпле, 2012 елның җәендә ремонт ясалып, остаханәнең кызлар өчен булган ике бүлмәсе дә (кулинария һәм көнкүреш хезмәте) балалар бакчасы өчен алынды. Остаханә инглиз теле кабинетына урнашып, инглиз теле тормыш иминлеге нигезләре кабинетына күчте.

2010 ел Юлбат мәктәбе өчен тагын бер ягы – 1982 елдан мәктәп директоры булган Нигъмәтҗанов Рөстәм Нурмиевичның, пенсия яше җитү сәбәпле, ялга китүе белән истәлекле. Ул киткәч тә коллектив остазы өйрәткәнчә эшләвен дәвам итте, алдагы елларда туплаган тәҗрибә коллективның эшен уңышлы дәвам итүгә нигез булды.



Саба елъязмачысы Тәлгать Нәҗмиев белән очрашу. Уңда мәктәп директоры Шәмсетдинов Р. Р.

2010-2011 уку елында мәктәп директоры үзебезнең мәктәпне тәмамлаган Шәмсетдинов Рафаэль Раифович булды. Ул Саба аграр көллиятенә директор урынбасары булып күчкәннән соң, 2011-2012 уку елында мәктәп директоры булып Хәнәфиева Айгөл Шакирҗановна эшләде. 2012 елның июленнән мәктәп директоры – Нигъмәтҗанов Фәргать Тәлгатович.

2011 елның маенда һәр укытучы һәм тәрбиячегә персональ ноутбук бирелде.

2011-2012 уку елында 3 интерактив такта, 4 проектор кайтты.

2006 һәм 2012 елларда мәктәп бинасына капиталь ремонт үткәрелде. 2012 елда укучылар өчен мәктәп бинасында җылы туалет ясалды.



1 сентябрь 2011 ел. Хуҗалык җитәкчесе Мөхәммәтов И.Ш. укучыларны котлый.
Уңнан беренче – мәктәп директоры Хәнәфиева А. Ш.

**Юлбатта сигезьеллык һәм урта мәктәптә эшләгән җитәкчеләр**

Мәктәп директорлары:
1982-2010 ел – Нигъмәтҗанов Рөстәм Нурмиевич
2010-2011 уку елы – Шәмсетдинов Рафаэль Раифович
2011-2012 уку елы – Хәнәфиева Айгөл Шакирҗановна
2012 – Нигмәтҗанов Фәргать Тәлгатович.

Укыту эшләре буенча директор урынбасарлары:
1982-1984 – Нигъмәтҗанова Венера Хәсәновна
1984-1989 – Сафин Илдар Фатхуллович
1989-2006 – Сафина Рәмзия Габделбәровна
2006-2011 – Низамиева Фирая Фаруковна
2011 – Фәтхриева Раушания Хәнәфиновна

Тәрбия эшләре буенча директор урынбасарлары:
1989 – 1991 – Шакирҗанова Фәһимә Гаптелфәтовна
1991-2010 – Шәмсетдинова Мәгефия Камалетдиновна
2010-2011 уку елы – Гомәрова Рузия Тимершәеховна
2011 – Әһелова Рушания Зәкәриевна



Сафина Рәмзия Габделбәровна, 1989-2006 елларда укыту эшләре буенча директор урынбасары



Шакирҗанова Фәһимә Гаптелфәтовна, 1989-1991 елларда тәрбия эшләре буенча директор урынбасары



Шәмсетдинова Мәгефия Камалетдиновна, 1991-2010 елларда тәрбия эшләре буенча директор урынбасары



Фәтхриева Раушания Хәнәфиновна, 2011 елдан укыту эшләре буенча директор урынбасары



Агелова Раушания Закариевна, 2011 елдан тәрбия эшләре буенча директор урынбасары

***Республика, Россия күләмендә бүләкләнгән педагоглар:***

**Татарстан мәктәпләренең атказанган укытучысы**
Нигъмәтҗанова Венера Хәсәновна

**Халык мәгарифе отличнигы**
Нигъмәтҗанов Рөстәм Нурмиевич
Шәмсетдинова Мәгефия Камалетдиновна

**“Россия Федерациясе мәктәпләренең мактаулы хезмәткәре” күкрәк билгесе**
Нигъмәтҗанова Венера Хәсәновна
Галимуллина Дания Гайфетдиновна
Сафин Илдар Фатхуллович
Хаҗиева Фәния Нургалиевна
Сафина Рәмзия Габделбәровна

**“Өстенлекле илкүләм “Мәгариф” проекты” конкурсында җиңүе өчен йөз мең сум күләмендә грант һәм “Россия Федерациясенең иң яхшы укытучысы” исеме (2006 ел)**
Сафин Илдар Фатхуллович

**“Өстенлекле милли проект кысаларында үткәрелгән “Россия Федерациясенең иң яхшы укытучысы” конкурсында катнашып, Татарстан Республикасының иң яхшы укытучылары конкурсы җиңүчесе булды һәм грант алды (2013 ел)**
Сафин Илдар Фатхуллович

**Россия Федерациясенең мәгариф һәм фән министрлыгының мактау грамотасы**
Фәләхова Гөлсинә Мехәммәтхановна
Габделхаева Гөлсинә Раяновна
Халикова Мәрзия Гатаулловна
Шакирҗанова Фәһимә Гаптелфәтовна

**ВЛКСМ өлкә комитетының Мактау грамотасы**
Шакирҗанова Фәһимә Гаптелфәтовна

**Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының “Мәгарифтәге казанышлары өчен” күкрәк билгесе**
Хаҗиева Фәния Нургалиевна
Сафина Рәмзия Габделбәровна

**Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының Мактау грамотасы**
Шакирҗанова Фәһимә Гаптелфәтовна
Нигъмәтҗанов Рөстәм Нурмиевич
Нигъмәтҗанова Венера Хәсәновна

Хаҗиева Фәния Нургалиевна
Сафин Илдар Фатхуллович
Галимуллина Дания Гайфетдиновна
Халикова Мәрзия Гатаулловна
Хаҗиева Әлфирә Рифкатовна.

*Искәрмә:* Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләнүчеләр исемлегенә "Укыту-тәрбия эшендә аеруча уңышка ирешкән өчен" министрлык тарафыннан махсус бүләкләнгән укытучылар гына керде. Министрлык тарафыннан үткәрелгән төрле конкурсларда катнашып бүләкләнгән укытучылар бу исемлеккә кермәде.

**2011 елда Татарстан Республикасының "Иң яхшы укытучы" конкурсында грант алучылар**

Шакирҗанова Фәһимә Гаптелфәтовна
Галимуллина Дания Гайфетдиновна
Сафин Илдар Фатхуллович

**2012 елда Татарстан республикасының "Иң яхшы укытучы" конкурсында грант алучылар**

Фәләхова Фирдания Габделхаковна
Кәримова Равия Рәфгалиевна
Кәримова Әлфирә Рифкатовна

**2013 елда Татарстан Республикасының "Иң яхшы укытучы" конкурсында грант алучылар**

Фәләхова Фирдания Габделхаковна

**Бүгенге укытучылар**



Мәктәп директоры Нигмәтҗанов Фәргат Тәлгатович



Габделхаева Гөлсинә Раяновна, балалар коллективын оештыручы



Фатхриева Райхана Хәнәфияовна, башлангыч сыйныфлар укытучысы



Галимҗанова Лилия Гаптелмәннәфовна, башлангыч сыйныфлар укытучысы



Низамиева Фирая Фаруковна, башлангыч сыйныфлар укытучысы



Кәримова Равия Рәфгалиевна, математика, технология укытучысы



Фәләхова Фирдания Габделхаковна, география, татар теле һәм әдәбияты укытучысы



Фәләхов Замир Вагыйзович, физик тәрбия укытучысы



Хәсәнова Миләүшә Мулламөхәммәтовна, физика, информатика укытучысы



Әмирова Гөлүсә Рифкатовна, инглиз теле укытучысы



Мансурова Энҗе Вазыйховна, библиотекарь



Хаҗиева Әлфирә Рифкатовна, химия, биология укытучысы



Галимуллина Дания Гайфетдиновна, татар теле һәм әдәбияты укытучысы



Мәҗитова Рәмзия Габдрәүфовна, инглиз теле укытучысы



Абдуллина Зилә Илгизовна, өстәмә белем бирү педагогы



Галәвиева Миләүшә Мидхатовна, рус теле һәм әдәбияты укытучысы



Дәүләтшин Нияз Илгизович, математика укытучысы



Йомагулов Айгиз Марсилевич, физик тәрбия укытучысы

***Шигъри күңелле укытучы Халикова Мәрзия Гатаулловна***

**ХӘТЕР АЛАНЫНДА…**

Хәтер аланында җиләк исе аңкый,
Кошлар сайрый, җилләр иркәли.
Ул аланнар әле шау чәчәктә,
Күңел һаман шунда күчкәли.



Халикова Мәрзия
Гатаулла кызы

Хәтер аланнары гел дә яшел,
Корт гөжелди чәчәктә.
Йөрәк нигә ябь-яшь кебек
Иллегәчә яшәп тә?

Якты анда, кояш анда,
Бигрәк зәңгәр күкләре.
Җылы кичләр – безнең өчен,
Дәшә капка төпләре.

“Кызлар-йолдызлар”ны уйный
Арт урамда, белмим, кем?
Хәтерләрдә, онытылмый
Ай-йолдызлы җәйге төн.

Барып чыксам шатлык аланына –
Сыкрауларым бетә дә куя.
Сызлауларым сүнә дә куя –
Килеп керсәм сафлык аланына.

**ЮГАРЫ ҮРЕЛҮ**

Әйтте апам: “Ашыгып,
Бик югары үрелмә!”
Ник үрелмим – биектән
Дөнья күбрәк күренә.

Югарыда кошлар оча,
Анда йолдыз серләшә.
Гел түбәндә ятмам мин дә,
Аллаһ үзе теләсә.

Артышлык тавына мендем,
Сабый идем – сөендем.

Жигули тауларын күрдем,
Урал буенда йөрдем.

Үтә биек менгермәде
Тормышымның баскычы –
Белә алмадым: баскычларның
Бик биеге кайсысы?

Исән чакта нигә талпынмаска?
Вакыт җитәр – без дә китәрбез…
Шуңа телим һаман таптанмаска,
Үрдә булсак, шөкер итәрбез.

## ӘНИЛӘР – ДӨНЬЯ БӘЯСЕ

Әниләр – дөнья бәясе,
Яши баласы өчен.
Әнием – сөю алиһәсе,
Беләм мәхәббәт көчен.

Җылы, рәхәт яңгыр ява,
Җирнең бите чыланган.
“Коенсыннар әле”, – дигән,
Әни гөлләр чыгарган.

Гөлләр кебек күңеле дә,
Нурлар балкый күзендә.
Саф ул, пакь ул, сөйкемле дә,
Иплелек һәр сүзендә.

Барып чыксаң туган өйгә,
Җыеп семья-ояны,
Әни оныкларын сөя:
“Иң бае мин дөньяның!”

## АК ДИҢГЕЗДӘ ХЕЗМӘТ ИТКӘН СОЛДАТ УЛЫМА

“Ак диңгездә – ак томаннар…
Саумысыз, газиз туганнар!” –
Шулай язар кебек беркөн улым,
Уң булса иде юлы.

Ил-җир күреп, ныгып кайтсын! –
Борынгыдан килгән теләкләр.
Кайларда гына булмасын –
Сынатмаслар чыдам беләкләр.

Солдат иңнәрендә – олы хезмәт,
Билләрендә каеш, гел шулай.
Имин булсын дөнья, күкләр аяз,
Ташлама Син безне, и Ходай!

Авыл өсләрендә моңлы тавыш,
Яшьләр җырлап урам әйләнә.
Җырда – китү, җырда – сагыш,
Бәгырь сызлый, йөрәк телгәләнә.

Бәширәнең тавышы булып,
Уй йөгерә ерак калаларга:
“Мәрхәмәтле бул син, язмыш,
Без үстергән балаларга”.

**Юлбат урта мәктәбен алтын медальгә тәмамлаган укучылар**

| № | Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме | Медаль алган елы |
|---|---|---|
| 1 | Нигъмәтҗанова Чулпан Рөстәм кызы | 1996 |
| 2 | Сафин Руслан Илдар улы | 2002 |
| 3 | Гасыймова Эльмира Рузбек кызы | 2005 |
| 4 | Кәбирова Алсу Васыйл кызы | 2005 |
| 5 | Сабирова Алисә Хәлил кызы | 2006 |
| 6 | Низамиева Гөлнара Рамил кызы | 2010 |
| 7 | Габделхаева Алсу Айдар кызы | 2011 |

**Юлбат урта мәктәбен көмеш медальгә тәмамлаган укучылар**

| № | Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме | Медаль алган елы |
|---|---|---|
| 1 | Хаҗиева Гөлнар Рәшит кызы | 1993 |
| 2 | Хаҗиева Энҗе  Рәшит кызы | 1994 |
| 3 | Хаҗиева Диләрә  Рәшит кызы | 1996 |
| 4 | Кәримова Әлфирә Рифкать кызы | 1996 |
| 5 | Рәхимуллина Венера Галимулла кызы | 1996 |
| 6 | Фатыйхова Наилә Вазыйх кызы | 1996 |
| 7 | Ибраһимова Альбина Әмин кызы | 1997 |

| | | |
|---|---|---|
| 8 | Гайфуллина Эльвира Габделхай кызы | 1998 |
| 9 | Фәрхуллина Лилия Хөснетдин кызы | 1998 |
| 10 | Рәхимуллин Марсель Гыйндулла улы | 1999 |
| 11 | Нуриева Энҗе Әнәс кызы | 1999 |
| 12 | Хаҗиев Айтуган Зөфәр улы | 1999 |
| 13 | Хисамиев Камил Фәһеметдин улы | 1999 |
| 14 | Бадикова Альбина Салават кызы | 2000 |
| 15 | Гайфиева Гүзәл Ришат кызы | 2000 |
| 16 | Нигъмәтҗанова Ландыш Рөстәм кызы | 2002 |
| 17 | Мөбәрәкҗанова Зөлфия Рөстәм кызы | 2002 |
| 18 | Галиева Дилә Фәнис кызы | 2002 |
| 19 | Сәләхова Гөлия Гаптрәкыйп кызы | 2002 |
| 20 | Низамиева Зөлфия Рафаил кызы | 2004 |
| 21 | Сафин Радик Илдар улы | 2004 |
| 22 | Мәҗитов Руслан Рафис улы | 2006 |
| 23 | Хаҗиева Эльза Айрат кызы | 2006 |
| 24 | Кәбирова Айсинә Васыйл кызы | 2007 |
| 25 | Гайфуллина Гүзәл Илгиз кызы | 2009 |
| 26 | Галиева Наҗия Шамил кызы | 2009 |
| 27 | Галимова Динә Мөдәррис кызы | 2010 |

## *Алар үзләрен фәнне үстерүгә багышладылар. Юлбат урта мәктәбен тәмамлаган фән кандидатлары*

### Галиева Рәсимә Муллаян кызы


Галиева Рәсимә Муллаян кызы (1997)

Тенеки авылында туган. 1997 елда “Алтын каләм” фестивалендә Гран-при алып, Казан дәүләт университетының журналистика факультетына укырга керде. Юлбат урта мәктәбен тәмамлаган укучылар арасыннан иң беренче фән кандидаты. Филология фәне буенча кандидатлык диссертациясе яклап, журналистика өлкәсендә эшли.

### Насыйбуллова (Гайфиева) Гүзәл Ришат кызы

1983 елда Саба районы Тенеки авылында туган. 2000 елда Юлбат урта мәктәбен тәмамлый. 2000-2005 елларда Казан дәүләт педагогика университетында белем ала. Университеттан соң укуын аспирантурада дәвам итә. 2010 елда “XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар

прозасында хикәя жанры поэтикасы” дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Хәзерге вакытта Казан (Идел буе) федераль университетының тәрҗемә теориясе һәм сөйләм коммуникацияләре кафедрасында эшли. Филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты доценты.



Насыйбуллова (Гайфиева) Гүзәл Ришат кызы

**Хажиев Айтуган Зөфәр улы**

1981 елның 27 сентябрендә Юлбат авылында дөньяга килә. 1988-1999 елларда Юлбат урта мәктәбендә башлангыч һәм урта белем ала. Мәктәпне көмеш медальгә тәмамлый. 1999-2004 елларда Казан дәүләт педагогия университетының (хәзерге ТГГПУ) биология факультеты студенты. Университетны тәмамлау белән Татарстан авыл хуҗалыгы фәннитикшеренү институтына эшкә килә һәм бер үк вакытта шул институтта Селекция һәм орлыкчылык белгечлеге буенча аспирантурага укырга керә. 2008 елда аспирантураны тәмамлап, “Урта Идел буенда селекцион һәм агротехник ысул белән уҗым культураларының корткычларга каршы торучанлыгын арттыру юллары” дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый һәм авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты дигән исем ала. Шул ук елны авыл хуҗалыгы үсемлекләрен корткычлардан һәм авырулардан саклау лабораториясе җитәкчесе итеп билгеләнә. 2010 елда фәндә ирешкән уңышлары өчен Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләнә. Айтуган Хаҗиев – институтта әйдәп баручы яшь белгечләрнең берсе, яшь галимнәр советы һәм аспирантура җитәкчесе. Бүгенге көндә селекция һәм орлыкчылык үзәге мөдире.



Хаҗиев Айтуган Зөфәр улы

**Хаҗиев Айназ Илһам улы**

1988 елда Юлбат авылында туган. 2005 елда – Юлбат урта мәктәбен, 2010 елда Казан дәүләт университетын (КФУ) тәмамлый. “Иске Казанның керамик комплексы” дигән темага диплом эше яклый.

Университеттан соң укуын Татарстан Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институты аспирантурасының көндезге бүлегендә дәвам итә.



Хаҗиев Айназ
Илһам улы

Бүгенге көндә ул кандидатлык диссертациясе өстендә эшли. Шул ук институтта кече фәнни хезмәткәр. Бер үк вакытта “Казан” милли-мәдәни үзәгендә фәнни хезмәткәр һәм экскурсовод вазифаларын башкара. Җәйге чорда тикшерүче буларак археологик экспедиция һәм разведкаларда катнаша: Свияжск, Болгар, Биләр, Әстерхан өлкәсенең “Сарай-Бату” шәһәрлеге, Алтын Урда башкаласы һәм башка археологик һәйкәлләре, Татарстанда булган өйрәнүләр.

Фәнни эшендә уңышлар телик аңа!

**Үзе гүзәл, исеме Гүзәл**

Сүзебез Юлбат урта мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы Кәримова Гүзәл хакында. Ул Татарстан Республикасы Саба районы Юлбат авылында 1998 елның 14 июлендә Кәримов Раил һәм Равиянең икенче кызлары булып дөньяга килә. Кечкенәдән бик актив, сәләтле, җитез, өлгер Гүзәл 4 яшендә газета укый һәм 5 яшендә, бик яхшы гына итеп, олылар белән шашка уйный иде. Шашка буенча беренче уңышлары 1 нче класста укыган вакытта, Нәүрүз бәйрәмендә була. Олыларны да җиңгән Гүзәлне күреп, ул вакытта район спорт комитетында эшләгән Кәримов Рәшит Хәбибрахман улы кабат-кабат аның туган елын сорый. Шашка уйнарга гаиләдә әти-әнисеннән, апасыннан, әбисеннән өйрәнгән. “Үземнең уңышларымда Рәшит абыйның тырышлыгын күрәм. Мин аңарга бик рәхмәтле. Ул миңа алга таба шушы өлкәдә үсәргә юнәлеш бирүче, беренче биеклекләрне яуларга ярдәм иткән җитәкчем, остазым”, – ди Гүзәл, шашка буенча үзенең уңышлары турында сөйләгәндә.

Үзенең югары нәтиҗәләре өчен Гүзәл 2013 елда районда Универсиада утын йөртү эстафетасында катнашу бәхетенә ирешә. Бу аның өчен нык дулкынландыргыч мизгелләр булгандыр, билгеле. Гүзәл шушы Универсиада уңаеннан бик зур истәлек картина әзерләде. Кулдан чигеп, зәвыклы итеп бизәлгән әлеге панно район күләмендә үткәрелгән олимпиадада II урынга лаек булды һәм күп кенә республика күргәзмәләрендә катнашты.

1 нче класстан башлап, Гүзәл кечкенәдән район, республика күләмендә үткәрелгән төрле ярышларда бик теләп катнашып килә һәм һәрвакыт уңышлы нәтиҗәләргә ирешә. Республика күләмендә беренче уңышлары 30 июнь – 5 июль көннәрендә Алабуга шәһәрендә Спорт һәм



Кәримова Гүзәл Раил кызы

сәламәт яшәү елы кысаларында үткән республиканың “Авыл яшьләре” VI җәйге спорт уеннарында була. 43 район арасында Юлбаттан Кәримовлар гаиләсе – Раил, Равия һәм 10 яшьлек Гүзәл – ярышның 4 төрендә дә (шашка, дартс, җиңел атлетика һәм өстәл теннисы) уңышлы чыгыш ясап, II урынга лаек булалар.

2012 нче елда Казанның Р.Нәҗметдинов исемендәге шахмат-шашка мәктәбендә үсмерләр арасында үткәрелгән республика беренчелегендә катнашып, үз яшь төркемендә 1 нче урынны алды. Шулай итеп 13 яшьлек Гүзәл шашкада I разряд нормасын үтәде. 7 нче сыйныфта 16 яшькә кадәрге яшүсмерләр арасында үткәрелгән халыкара шашкада җиңү яулап, Гүзәл Татарстан чемпионы булды. Шуннан соң ул Мәскәүдә узачак тагы да җаваплырак бәйгегә әзерләнә. Аны Бөтенроссия күләмендәге ярышлар көтә. Гүзәл, Казан җыелма командасы составында, республика күләмендә генә түгел, Россия, ил буйлап – Мәскәү, Башкортстан (Ишимбай), Санкт-Петербург, Самара, Туапсе, Сочи шәһәрләрендә үткәрелгән ярышларда уңышлы гына катнашып кайтты. Хоккей җыелма командасы составында Краснодар өлкәсенең Ейск шәһәрендә А.В.Тарасов “Золотая шайба” клубында үткәрелгән Бөтенроссия финал ярышларында районның “Тимерхан” хоккей командасы составы уңышлы гына чыгыш ясады. Самара өлкәсендә, А.Я.Рябинович истәлегенә үткәрелгән рус шашкасы (классика) төрендә – II урын, тиз уйнау (молниеносная программа) төрендә III урынга лаек булды. Республика районнарында – Саба, Арча, Балтач, Кукмара, Актаныш, Биектау, Тәкәнеш районнарында, Алабуга шәһәрендә үткәрелгән ярышларда, сабантуйларда актив катнашып, шахмат-шашка буенча һәр елны хатын-кызлар арасында призлы урыннар яулап килә. Биектау районында үткәрелгән двоеборье (шахмат, шашка) ярышында хатын-кызлар арасында I урынга ирешә. Һәр ай ахырында ял көне үткәрелгән Гран-прида даими катнаша, үзенең көчен сыный. Яшь кенә булса да, Гүзәлнең 25ләп медале, кубоклары бар, диплом һәм грамоталары бихисап.

Хәзерге вакытта Гүзәл апасы Сиринә җитәкчелегендә дөньякүләм ярышларга йөри һәм уңай нәтиҗәләргә ирешә.

Үзенең активлыгы, тырышлыгы нәтиҗәсендә 2 ел рәттән “Орленок” Бөтенроссия балалар үзәге лагеренда булып кайтты. Лагерьлар арасында үткәрелгән шашка ярышында, шулай ук шахмат ярышында I урыннарга иреште.

Хәзерге вакытта 9 нчы сыйныфта гел “5”ле билгеләренә генә укый. Гүзәл – бик сәләтле кыз: бию, гитара, шахмат түгәрәкләренә йөри. Гүзәл өч ел рәттән КДУ оештырган “Серле каләм” иҗат бәйгесе призёры булды һәм “Каһарманлык гасырларны кичәр, яңа буыннарны уятыр” дигән темага республиканың фәнни практик конференциясендә катнашып III дәрәҗә диплом белән бүләкләнде. Г.Тукайга 125 ел тулу уңаеннан “Сабантуй” газетасы һәм Арча балалар сарае оештырган конкурс дипломанты. ТР Яшьләр эшләре үзәге оештырган XI, XII “Иделем акчарлагы” бәйгесенең йомгаклау турында катнашып, яхшы нәтиҗәләргә һәм уңышларга иреште. Аның фотосы һәм иҗат иткән шигыре әдәби җыентыкка кертелде. Афәрин, Гүзәл! Уңышлар сиңа!

Аның турында районыбызның “Саба таңнары” газетасында һәм “Ялкын” журналында мәкаләләр, язмалар шактый урын ала. Кәримова Гүзәл – мәктәпнең иң сәләтле укучысы, горурлыгы.

## Җиңүләрең белән, Райнур!

Табигать тарафыннан бирелгән сәләт һәр кешедә бер төсле булмый. Ә менә безнең Райнурыбыз чын мәгънәсендә сәләтле бала. Җырга-моңга гашыйк ул. Өздереп җырлап җибәрсә, барлык кошлар тын каладыр кебек. Кечкенәдән сәхнәдә чыгыш ясап, халык ихтирамын яулады. Әле 5 нче сыйныфны гына тәмамласа да, Райнурның район, республика күләмендә уңышлары шактый. 2011 нче ел аның өчен зур җиңүләр елы булды. Яшь башкаручыларның Сара Садыйкова исемендәге VI төбәкара "Калфаклы сандугач" конкурс фестивале үтте. Анда нәни җырчыбыз 1 нче урынны яулады һәм "Мәгърифәт" газетасының махсус призына лаек булды. V Республика яшьләр фестивале "Ватан" конкурсының район этабында 1нче призлы урын алып, финалга үтте. Анда да уңышлы чыгыш ясады Райнур, 2нче дәрәҗәдәге диплом алып кайтты. Татарстан Республикасы "Содружество сердец" балалар фестиваленең районда үткән "Халык җырлары" конкурсында ул 2 нче урынга лаек булды. Әлеге уңышлары Райнурны һәм аның җитәкчесе Фәрит Мәҗитовичны бик сөендерде. Алар тагын да ныклабрак шөгыльләнә башладылар. 2012 нче елның уңышлары да озак көттермәде. "Сандугач керде күңелгә" – республика конкурсында Диплом һәм Өмет бүләген, күренекле татар композиторы Мансур Мозаффаровның тууына 110 ел тулуга багышланган VII Республикакүләм "Дулкыннар" конкурсында 3нче дәрәҗәдәге лауреат дипломын, XIII Бөтенроссия конкурсы " Я люблю тебя, Россия!" патриотик җырлар конкурсының Республика этабында "Родина, мои родные края" 3 нче дәрәҗәдәге дипломын яулады. Җыр сәнгате белән беррәттән, Райнур бик оста бии дә. Чаллы шәһәрендә хореография сәнгате буенча үткән III ачык республикакүләм фетивалендә Райнурыбыз биегән "Модерн" төркеме (җитәкчеләре Дәүләтшина Альмира Фоатовна) 3нче дәрәҗәдәге лауреат дипломына лаек булды. 2013 нче елда "Созвездие – Йолдызлык" республикакүләмачык телевизион яшьләр фестивалендә диплом яуладылар. 2013-2014 нче уку елында Райнур "Ватан", Фәрит Яруллинның тууына 100 ел тулуга багышланган IX Республикакүләм "Дулкыннар" конкурсларының сертификат һәм дипломнарына ия булды. 2014 нче



"Созвездие – Йолдызлык 2014" фестиваленең Теләчедә үткән зона турында чыгыш

елда районда үткән “Сәләтле балачак, өметле киләчәк” конкурсында вокал-соло номинациясендә 3 урынны яулады.

Райнур Мансуров мәктәптә узган бер генә чарадан да читтә калмый. Сөйкемле малаебызның сәхнәдә үзен чын артистлар кебек тотуы,өздереп җырлавы һәркемнең күңеленә хуш килә. Киләчәктә дә моң чишмәң саекмасын, Райнур! Афәрин! Без синең белән горурланабыз!

*Габделхаева Гөлсинә Раяновна,*
*Юлбат урта мәктәбенең балалар коллективын оештыручысы.*

***Юлбат авылыннан чыккан беренче укытучылар***

**Якупова Хәбирә Якуп кызы**



Якупова Хәбирә Якуп кызы

1919 елда Юлбат авылында туа. Юлбат башлангыч, Сатыш җидееллык, Саба урта мәктәпләрендә белем ала. 1941 елда Югары Симет мәктәбендә хезмәт юлын башлый.

Сугыштан соң Кызыл Мишә башлангыч мәктәбенә укытырга килә һәм лаеклы ялга чыкканчы шул мәктәптә укыта. 1965 елда мәктәп мөдире итеп билгеләнә. Күп тапкырлар район мәгариф бүлегенең Мактау грамоталары белән бүләкләнә.

**Якупова Оркыя Якуп кызы**



Якупова Оркыя Якуп кызы

Минем әнием, Якупова Оркыя, 40 ел гомерен балаларга белем һәм тәрбия бирүгә багышлады. Ул 1924 елда Юлбат авылында туган. 1932-1935 елларда – Юлбат башлангыч мәктәбендә, 1936-1939 елларда Сатыш җидееллык мәктәбендә белем ала. 1940-1942 елда Саба урта мәктәбендә укый. Аны тәмамлаганнан соң, 1942 елда, хезмәт юлын Сатыш җидееллык мәктәбендә тарих укытучысы буларак башлый. 1943-1945 елларда Килдебәк, 1946-1947 елларда Тимершык җидееллык мәктәпләрендә укыта. 1949 елда читтән торып Казан педагогия училищесын тәмамлый. 1948 елдан лаеклы ялга киткәнче (1981 ел) Тенеки башлангыч мәктәбендә укытучы һәм мәктәп мөдире булып эшли. 1947 елда “1941-1945 елларда тылдагы фидакарь хезмәт өчен” медале белән бүләкләнә. Хезмәт ветераны. 1992 елда вафат булды.

**Хаҗиева Рәшидә Хаҗиәхмәт кызы**



Хаҗиева Рәшидә
Хужиәхмәт кызы

1923 елның 15 маенда Юлбат авылында туа. 1940 елда Казанда немец теле укытучылары хәзерли торган курсларны тәмамлый. Әгерҗе районы Көек авылында укыта, сугыш башлангач, үз ягына – Саба районына кайта. “Балаларның өсләре кырык ямаулы, ачлы-туклы, әмма дәресләр бара. Ни дәфтәр, ни дәреслек, ни язу карасы юк. Ни туры килсә, шунда язабыз, бер карандашны 3-4 кә бүләбез”, – дип сөйли торган булган ул. 1951 елның 18 мартында кияүгә чыга. Озак еллар Сатыш мәктәбендә татар теле һәм немец теле укыта. 1974 елда пенсиягә чыга. 1993 елның 18 гыйнварында вафат була.

**Юлбатның хәтер мәгарәсе**

Мин музейларны кеше күңеленә нык тәэсир итә торган тәрбия чарасы дип саныйм. Аларның экспонатлары әби-бабаларыбызның үткәнен күз алдына китереп бастыра: авыр елларны, сугыш мәхшәрләрен, аннан соңгы төзекләндерү чорларын яшь буынга түкми-чәчми җиткерә.



Укучылар музейда

Юлбат урта мәктәбенең туган якны өйрәнү музее 1995 елның 9 маенда – Бөек Җиңүнең 50 еллыгын билгеләп үткән көнне ачылды. Аның беренче кунаклары сугыш һәм хезмәт ветераннары булды. Ишектәге кызыл тасманы сугыш ветераны, ветеран укытучы Саҗидә апа Ракова кисте.



Тенеки байларының шәхси мөһерләре

Музейның беренче бүлеге шушы төбәктә яшәүчеләрнең көнкүреше турында сөйли. Авыл өе. Агач сәке. Йорт эче борынгыча бизәлгән. Шунда ук кабыктан эшләнгән бала бишеге, агач савыт-сабалар, чүпләмле сөлгеләр, чиккән әйберләр. Бу бүлекнең иң кадерле экспонатларының берсе – XIX гасырда төзелгән авыл мәчетенең ае. Мәчет манарасы 1939 елны киселгән, ае исә, авыл кешеләрендә сакланып, музейга тапшырылды. Кыйммәтле экспонатларның икенчесе – революциягә кадәр Юлбат авылында булган шәхси кибетнең афишасы. Шушы ук бүлектә Тенеки авылында яшәгән Дәүли байның шәхси мөһере. Ул таштан ясалган, аңа әлеге сәүдәгәрнең исеме гарәп хәрефләре белән уеп язылган. Куллану өчен уңайлы, формасы белән хәзерге мөһерләрне хәтерләтә.



Валес – беләзек ясалачак көмеш материалны тигезләү өчен инструмент

Икенче бүлек тулысынча Тенеки көмешчеләренә багышланган. Авылы белән көмешчеләр булган алар. Шунлыктан музей төзегәндә көмешчеләрне өйрәнү төп юнәлеш булды. Көмеш осталарының соңгы буын вәкиле, сугыш ветераны Хәбибрахман ага Ганиев исән чагында, гүзәллек тудыру серләрен видеоязмага төшереп барган идек. Бу язмаларны укучылар белән кабат-кабат кайтып карыйбыз, гади авыл кешесенең өй шартларында кабатланмас матурлык тудыра алуына сокланабыз, авылдашыбыз белән горурланабыз. Музейда көмешчеләрнең эш коралларының бер өлеше, Хәбибрахман ага эшләгән беләзек-йөзекләрнең фоторәсемнәре саклана. Бу һөнәр ияләре турында фотоальбом да төзелде.



Сугышта һәлак булган Якупов Файзрахманның күлмәге

Өченче бүлек сугыш һәм хезмәт ветераннарына багышлана. Бу бүлектә орден-медальләр, аларның таныклыклары, сугышчыларга бирелгән Рәхмәт хатлары кадерләп саклана. Йосыф-Алан авылыннан Каюм Гәрәев һәм Юлбаттан Тимерхуҗа Исламовның фронттан җибәргән өчпочмаклы хатлары укучыларны аеруча кызыксындыра. Алар икесе дә сугышта батырларча һәлак була.

1993 елның октябреннән сугыш һәм тыл ветераннары, өлкән буын кешеләре белән булган очрашулар, әңгәмәләр видеоязмага төшереп барылды. Шул язмаларга нигезләнеп, Бөек Җиңүнең 60 еллыгы уңаеннан "Беркем дә, берни дә онытылмый" дигән видеофильм эшләнде. Кызганыч, безнең авыл җирлегендә сугыш ветераннарының берсе дә безнең арада юк инде. Хәзер аларның язмаларын видеотасмадан DVD дискка күчерәбез. Димәк, аларның сөйләгәннәре югалмас, киләчәк буыннар да Бөек Ватан сугышын үзе күргән кешеләрнең кичерешләре аша бу вакыйгалар белән таныша алыр.

Әлеге бүлектә тагын бер кыйммәтле экспонат – 1943 елда сугыш кырларында ятып калган беренче тракторчы Якупов Фәйзрахманның җитен җебеннән сугылган чигүле күлмәге музей түрендә урын алган. Ул кершәндәй ап-ак, әйтерсең, өйләнергә дә өлгермичә сугышка китеп, яу кырында ятып калган хуҗасының күнел сафлыгын саклый.

Дүртенче бүлек колхоз оешуның беренче елларын һәм сугыш алды чорын колачлый. Биредә колхоз оешуның беренче көннәреннән алып хәзерге чорга кадәр тарихы, колхозчыларның фидакяр хезмәте турында материал тупланган. Алар нигездә истәлекләр, фотографияләр, документлардан тора. Шунда ук сәяси репрессия корбаннарыннан авылыбыз мулласы Мөхәммәтшакир Мөхәммәтшин һәм авылдашларыбыз Сәйфулла Фәтхуллин, Нотфулла Фәтхуллин, Гайфулла Фәтхуллинның КГБ архивыннан алынган "Гаепләү эше" материалларының күчермәләре саклана.

Бишенче бүлек  мәктәп тарихына багышлана. Билгеле булганча, авыл мәгарифенә мәчетләрдә нигез салынган. Музейда, истәлекләрдән тыш, авылның соңгы указлы мулласы Мөхәммәтшакир хәзрәтнең бердәнбер фотосурәтенең күчермәсе саклана. Ул 1880 елда туган, 1924 елда Балык Бистәсе районының Котлы Бөкәш авылыннан Юлбатка килеп, гомеренең соңгы көннәренә – 1961 елга кадәр имам вазифасын намус белән башкара. Аның бу изге эшенә бары тик репрессияләнеп 8 ел төрмәдә булу гына киртә була алган. Авыл халкына дини белем һәм тәрбия бирүдә аның өлеше бик зур. Халык күңелендә аңа карата бүген дә зур ихтирам хисләре саклана.

Бу бүлектә шулай ук Юлбат авылында беренче мәктәп бинасы төзелү, сугыш чорында укытучылар, балаларның белемгә, эшкә булган омтылышына  кагылышлы истәлекләр саклана.

Алтынчы бүлек – безнең җирлектән чыккан танылган шәхесләр турында. Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Гали Ильясовның концерт костюмы, “Оныттың бугай...” дигән җырлар китабы, грампластинкадагы җырлары, телевидение фондыннан видеоязмалар, Юлбатта үткәрелгән 60 яшьлек юбилееның видеоязмасы, күп санлы фотографияләре һәм башка истәлекләре музей фондларында урын алган. (Аның әтисе Гани абый тумышы белән Юлбат авылыннан.).

Музейда танылган якташларыбыз – әдип Мәгъсүм Хуҗин, рәссам Тавил Хуҗиәхмәтов турында  материаллар туплана. Ә райондашыбыз, дөньякүләм танылган китап белгече, академик Әбрар Кәримуллин турында “Китапка багышланган гомер” дигән видеофильм эшләдек. Аның тормыш һәм иҗат юлы турындагы эзләнүләребезне чагылдырган бу фильмны галимнең үзе исән вакытта төшерелгән видеоязмалар тагын да тулыландырды.

Тенекидә яшәгән Гамбәр апа Галәвиеваның якын туганы, мәшһүр шагыйр Шәехзадә Бабич турында истәлекләре видеоязмада саклана. Ул анда әнисе белән бертуган абыйсы Ш.Бабичның искиткеч зыялы, талантлы шәхес булуы турында сөйли.

Соңгы вакытта музей фондлары 1834 елда үткәрелгән 8 нче “Ревизская сказка”, 1850 елгы 9 нчы  “Ревизия сказка” (халык санын алу мәгълүматлары) күчермәсе белән тулыландырылды. Бу материалларга таянып, без шул елларда авылда ничә хуҗалык булуын, күпме халык яшәвен, һәр хуҗалыктагы гаилә әгъзаларын, аларның туган елларын белә алдык. Бу материаллар авылдашларга үзләренең нәсел шәҗәрәсен ачыклауда зур ярдәм булачак.

1883 елда үткәрелгән статистик экспедиция материалларының күчермәсен булдырып,  ул вакытта Мамадыш өязе Сатыш волостена кергән Ямбулат авылы (Юлбат) халкының матди хәле, яшәеше турында күп мәгълүматлар белә алдык.

Кыскасы,  мәктәпнең туган якны өйрәнү музее яшьләрне халкыбызның данлы традицияләрендә, өлкәннәр үрнәгендә тәрбияләүгә үзеннән өлеш кертә, ә укучылар музейның эчтәлеген баета торган кыйммәтле һәм кадерле экспонатлар белән аны тагын да тулыландыра тора.

*“Мәдәни җомга” газетасы, №17, 11 май, 2012 ел*

# *Тенеки мәктәбе тарихы*

Тенеки башлангыч мәктәбе Сабага бара торган тау өстендә урнашкан була. Бу мәктәпне 1924 елда Саттаров Хәниф салдырган. Беренче укытучы Саттарова Мәймүнә гарәп алфавиты белән җәдитчә укыткан.

1926-1927 елларда Шәмсия Әбелхаятова укыта. 1927 елда мәктәп 4 класслы, ике комплектлы булып эшли башлый, Мотыйгуллина Гафифә апа укытырга килә.

1936-1937 елларда Бариев Мәсгуть абый һәм аның тормыш иптәше Шәмсенур апалар укыта (артист Шамил Бариевның әти-әниләре).

1941-1942 елларда Мотыйгуллина Миңнегөл, Вәлиева Хәдичә укыталар.

1944 елда Федорова Прасковья укытырга килә.

1948-1981 елларда Якупова Оркыя укыта. 1954-1974 елларда алар Рәшидә апа Сәгыйтова белән бергә эшлиләр.

1981-1982 уку елы – Шакирҗанова (Галимуллина) Дания Гайфетдиновна.

1982 елда, Мәртен сигезьеллык мәктәбе Юлбатка күчкәч, аңа кадәр Мәртендә эшләгән Фалиянур апа Садыйкова килә һәм 1989 елда пенсиягә чыкканчы эшли. Ул ялга киткәч, 1989 елда Сабирова Гөлсинә килә һәм 2004 елга кадәр эшли. Сабирова Гөлсинә киткәннән соң, аның урынында Фәтхриева Райхана, Галимҗанова (Кәримова) Гөлия, Әмирова Гөлүсәләр эшләп ала.



Якупова Оркыя (уңда), Сәгыйтова Рәшидә (сулда) укучылары белән. 1967 ел



Тенеки башлангыч мәктәбендә бергә эшләгән Сабирова Гөлсинә (сулда),
Гомәрова Рузия (уңда) укучылары белән. Уртада техник хезмәткәр Гамбәр апа.
1992-1993 уку елы

1986-2008 елларда Гомәрова Рузия укыта һәм мәктәп мөдире була. Соңгы елларда ул иң озак эшләгән укытучы. Тенеки мәктәбе ул эшләгән елларда район күләмендә алдынгылар рәтендә булды. Мәктәптә классларны зәвык белән җиһазлауда, алдынгы укыту алымнарын куллануда, класстан тыш тәрбия чаралары үткәрүдә Гомәрова Рузия һәм Сабирова Гөлсинәләрнең хезмәте зур булды. Алар белән янәшә эшләгән укытучылар Тенеки мәктәбе традицияләрен лаеклы дәвам иттеләр.

2008 елда, бинасы искерү сәбәпле, Тенеки башлангыч мәктәбе ябылды һәм оптимизациянең шәфкатьле куллары биргән мәктәп автобусында балалар беренче класстан Юлбат урта мәктәбенә йөреп укый башладылар.

**Йосыф-Алан мәктәбе тарихы**

Йосыф-Аланда коммуна вакытында (1927-1928 еллар) типовой проект белән эшләнгән, ашханәсе, кинозалы булган зур агач мәктәп эшләнгән. Бу мәктәпне Комрау урыслары төзегән. Анда Мәдинә исемле (фамилиясен белүче юк) укытучы укыткан. Ләкин бу мәктәпне район җитәкчеләре законсыз рәвештә Сабага күчереп салдыралар. Ул Сабаның хәзерге М. Җәлил урамында терәк мәктәп булып торган. Сугыш елларында кабат сүтеп, урманга күчереп, балалар интернаты корырга уйлыйлар. Ләкин бу гамәлгә ашмый кала, шунда таралып бетә. Балалар Тенеки мәктәбендә укыганнар.

Мәктәп өчен аерым бина булмаган. 1938 еллардагы мәктәп Сөнгать йортында булган. Ул йорт Тенекидән менгәндәге беренче тыкрыкның чатында булган. Бер бүлмә булганлыктан, укыту ике сменада барган. Ул елларга кадәр Керәнне авылыннан Бикмуллин Касыйм дигән укытучы эшләгән.

1939 елларда мәктәп ролен бер карчык өенең бер ягы үтәгән. Икенче укытучы колхоз идарәсенең бер бүлмәсендә укыткан. Тик 1963 елда гына, кечерәк бура буратып, икенче ягына шул идарә бүлмәсен оештырып, урман кырыена бик матур урынга мәктәп итеп күчереп салалар. Кызганыч, 1993 елның 11 ноябрендә, янгын чыгып, бу мәктәп тулысынча янып бетте. Аннан соң ферманың терлекчеләр йорты мәктәп итеп үзгәртелеп, балалар шунда укытылды. Янкорма эшләнеп, ашханә, котельный булдырылды.

2006 елда типовой проект белән яңа мәктәп салынды.

**Йосыф-Алан башлангыч мәктәбендә эшләгән укытучылар:**



Хөсәенова Халисә

Ногманов Әхмәт 1938-1940 уку елларында мәктәп мөдире һәм укытучы булып эшли.

Хөсәенова Халисә – 1942 елдан лаеклы ялга чыкканчы 35 ел укыта. Ул Буа районының Әлки авылында туган, балалар йортында тәрбияләнгән. Казанга килеп укырга кергәч, укытучы Йосыф белән очраша. Йосыф үзе Актаныш районының Аккүз авылында туган, яшьли ятим калып, ул да балалар йортында үскән, югары белем алып, физика, математика укыткан. Халисә укуын тәмамлагач, алар өйләнешкәннәр һәм Мөслимгә эшкә билгеләнәләр. Бер елдан соң аларны безнең районга укытучы итеп күчергәннәр. Тагын бер елдан Йосыфны Төбәк мәктәбенә директор итеп билгелиләр. 1938 елны аларны кабаттан Сабага чакырып, Йосыфны мәктәп директоры итеп билгелиләр. Бер ел эшләгәч, район мәгариф бүлеге мөдире итеп билгелиләр. 1941 елда, сугыш башланып ике ай узгач, аны Арча эчке эшләр бүлеге начальнигы итеп куялар. Шунда әйбәт кенә эшләп йөргәндә, кисәк кенә авырып китеп, ул Арча хастаханәсендә вафат була.



Хөсәенов Ленц



Гыйльметдинова Рауза 1958 елдан башлангыч мәктәп директоры һәм 1979 елдан укытучы булып эшли

Ире үлгәч, Халисә апа, ике баласын алып, Сабага кайтып төпләнә. 1942 елның мартында аны Йосыф-Аланга укытучы итеп җибәрәләр. Шул килүдән Халисә апа пенсиягә чыкканчы шушы мәктәптә эшли.

Халисә апаның улы Ленц 1937 елның 28 апрелендә Төбәк авылында туа. Ленц Йосыф-Аланда дүрт сыйныф укыганнан соң, Сатыш җидееллык мәктәбен тәмамлый һәм Саба киночелтәренә моторист булып урнаша, ягъни авылларда кино куеп йөри. Ул бу хезмәтенә гомере буе тугры калып, 45 ел эшләп пенсиягә чыга. Халыкка кино хезмәте күрсәтү белән беррәттән, шул вакыт өчен сирәк һәм бик кирәкле һөнәр үзләштереп, күрше-тирә авыллар халкын фоторәсемгә төшерде.

Хаева Шафига – 1962 елдан 1983 елга кадәр укыта.

1980 елдан 1990 елга кадәр Сафина (Габделхаева) Гөлсинә Раяновна балаларга белем бирә. Мәктәпне ремонтлату, җиләк-җимеш бакчасы булдыру өстендә эшли.

1990 елдан 2013 елның августына кадәр Гасыймова Илгизә Зиннәтулловна – төп укытучы. Ул укучыларга белем бирү, аларда тәрбиялелек сыйфатларын үстерү юнәлешендә эшкә зур көч куйды. Укучыларда кызыксынучанлык, аралашу культурасы, сәнгатькә, табигатькә мәхәббәт тәрбияләү өлкәсендә төрле



Сафина (Габделхаева) Гөлсинә Раяновна үзенең укучылары белән



Гасыймова Илгизә Зиннәтулловна
укучылары белән

отышлы алымнар кулланды. Авыл тарихын өйрәнү буенча күп эш башкарды. Районда “Ел укытучысы” конкурсының финал этабында чыгыш ясап, лауреат исеме алды. Укучыларга экологик тәрбия бирүгә юнәлтелгән “Гүзәл җиребезне саклыйк!” дип исемләнгән программасы республикада II дәрәҗә диплом белән бүләкләнде.

2013 елда, балалар саны аз булу сәбәпле, башлангыч мәктәп ябылды. Аның бинасында балалар бакчасы ачылды. Укучылар беренче сыйныфтан ук Юлбат урта мәктәбенә йөреп укый башладылар.

# Мәчетләр

## Юлбат мәчете тарихы

Авылның өлкән яшьтәге кешеләре сөйләве буенча, мәчет Галиев Фәнисләр тирәсендә була. Кызганычка каршы, ул 1867 елда яна. Архив материаллары буенча, янган мәчет урынына яңасын төзергә дәүләт тарафыннан рөхсәт 1880 елның 15 маенда бирелгән (Ф2, ОП2, Т1, 144 бит).

Хәзер инде мәчет төзергә ничек рөхсәт алынуын карап китик.

1880 елның февралендә авыл җыены була. Староста Хәмидулла Гыйбадуллин катнашында хөкүмәткә үтенеч кәгазе языла: 1867 елда янган мәчет урынына, мәхәллә хисабына агачтан манаралы җәмигъ мәчет төзергә язмача рөхсәт сорала. Авылда 216 ир заты (ревизских душ) яшәве, җәмәгать намазлары укырга урын булмавы аңлатыла. Мәчетне авылның үзәгендә, Бәшир Таһиров йорты урынында төзиячәкләрен, ә Бәшир каралтыларын җәмәгатьчелек хисабына план нигезендә (плановое место) күчерәчәкләрен язалар. Бинаның размерлары тәгаенләнә: алты почмаклы (пятистенную), буе 7 сажень (1 сажень – якынча 2 метр), иңе 3 сажень да 1 аршын зурлыгында, аңа өстәп тактадан янкорма – өйалды төзиячәкләр. Төзелеш барышын күзәтү өчен тәртипле, суд җаваплылыгына тартылмаган крестьян Гайнетдин Сәлимҗановны билгелиләр. Мәчетнең әйләнә-тирәсендә 20 саженьнан да ким булмаган җир мәйданы булдырылачагы, аның өчен, кирәк була калса, башка хуҗалыклар да күчереләчәге әйтелә. Яңа төзелгән мәчетне һәм анда эшләүче дин әһелләрен үз хисапларына тәэмин итеп торачаклары искәртелә. Авылда керәшеннәр булмавы ассызыклана. Җыелешта катнашкан тавыш бирү хокукы булган 80 кешенең исеме, фамилиясе языла, куллар куела, староста печать суга. Үзе дә җыенда катнашкан Сатыш волосте старшинасы карарның (приговор) дөреслеген тикшереп, Ямбулат җыены документларының волость идарәсендә саклана торган икенче нөсхәсен язарга күрсәтмә бирә. Волость старшинасы печате һәм волость идарәсе печате куела.





### Җыелышта катнашучыларның исемлеге


1. Нурмухамет Бикмухаметов. 2. Залялетдин Мухаметрахимов. 3. Сиразетдин Мухаметрахимов. 4. Валиулла Калимуллин. 5. Мустафа Биктимиров. 6. Гиззатулла Губайдуллин. 7. Хамидулла Губайдуллин. 8. Бикчентэй Мухаметгалиев. 9. Калимулла Фаткуллин. 10. Мухаметзян Салимжанов. 11. Гатиатулла Фат-

куллин. 12. Набиулла Фатхуллин. 13. АхметшаГабитов. 14. Зиганша Габитов. 15. Зайнулла Гибадуллин. 16. Вилъдан Ишмухаметов. 17. Денмухаметъ Биккулов. 18. Хайбулла Биктимеров. 19. Ибрагим Мухаметгалиев. 20. Шагиахмет Искандеров. 21. Ахтям Искандеров. 22. Багаутдин Тазетдинов. 23. ДавлетшаМукменовъ. 24. Сафа Бикмухаметовъ. 25. Багман Исхаков. 26. Шамсутдин Дяминев. 27. Тойга Хамитов. 28. Ахмадей Ахтямов. 29. Габбасъ Бикташевъ. 30. Валиахметъ Усмановъ. 31. Ильяс Габбасовъ. 32. Гимадутдинь Халилов. 33. Баширъ Тагиров. 34. Валей Абдулзяппаровъ. 35. Мухаметгарифъ Загировъ. 36. Кагиръ Мухаметгалиев. 37. Иркабай Губайдуллин. 38. Абдрахманъ Абдюшевъ. 39. Абдулгаллям Абдюшевъ. 40. Ахметзянъ Хамзин. 41. Гилазетдин Назмутдинов. 42. Хусаин Бикмухаметевъ. 43. Хабибулла Гайфуллин. 44. Исхакъ Бикмухаметевъ. 45. Ярулла Гайфуллин. 46. Саетбаттал Мухаметгалиев. 47. Сиразетдинъ Бикчентиев. 48. Денъмухаметъ Ахметевъ. 49. Мухаметъюсупъ Габяссовъ. 50. Мухаметша Ахтямов. 51. Тохбатулла Тазетдинов. 52. Насыбулла Мухамедияровъ. 53. Тимербай Курбангалиев. 54. Кагарманъ Галиакберовъ. 55. Гимадутдинъ Махмутовъ. 56. Абдулганей Ахмадеев. 57. Илъясъ Ишниязов. 58. Сагадутдинъ Зайнагутдиновъ. 59. Тохбатулла Сайфутдиновъ. 60. Хайрулла Фахрутдиновъ. 61. Фаттахутдинъ Мифтахутдиновъ. 62. Мухутдинъ Хуснутдиновъ. 63. Тазетдинъ Абдрахимовъ. 64. Калимулла Хисамутдиновъ. 65. Шамсутдинъ Халитовъ. 66. Залялетдин Зайнетдиновъ. 67. Халитъ Сабитовъ. 68. Хафизулла Хамитовъ. 69. Абдулъгафуръ Мухаметгалиевъ. 70. Нурмухаметъ Бикмухаметовъ. 71. (Укып булмады). 72. Рахимулла Гайфуллин. 73. Деньмухаметъ Бикмухаметовъ. 74. Исмагилъ Габбясовъ. 75. Хабибулла Абдюшевъ. 76. Хасанъ Бикмухаметовъ. 77. Гайса Усманов. 78. Гайса Бикимеровъ. 79. Муса Биктимеровъ. 80. Бадрутдинъ Тазетдиновъ.

Казан губерна идарәсе рөхсәт биргәннән соң, Оренбург Диния нәзарәте, үзенең каршы булмавын белдереп, Казан губерна идарәсенә рапорт җибәрә. “Дело” шуның белән ябыла, төзелешнең башлану, төгәлләнүе турында язма мәгълүмат юк. Рәхмәтуллин Камил абыйга Мифтахетдин бабай әйтеп калдырганнар буенча, бу мәчет 18 рәт агачтан 1881 елда төзелгән булырга тиеш. 1880 елда рөхсәт алынгач, бер ел эчендә мәчет төзелгәндер дип уйларга һәм халык күңелендә яшәүче истәлекләрнең төгәллегенә гаҗәпләнергә генә кала.

1900 елда туган Исламгали улы Ихсан һәм 1907 елда туган Дәүләтша улы Мансур сөйләгәннәрдән Ибраһимова Алсу белән Мифтахова Рәмзия язып алган истәлекләргә караганда, яңа төзелгән мәчетнең манарасын ясаучы рус кешесе Семен һәм балта остасы Сәләхетдин углы Гыйззетдин була. Ә ай куелганда бик зур бәйрәм үткәргәннәр. Айга кызыл башлы сөлге бәйләп менгерәләр. Айдагы сөлгене менеп азан әйтеп алырга тиеш булалар. Рус кешесе, баш төзүче булганлыктан, сөлгене үзе менеп алырга тели (кызыл башлы сөлге бик кыйммәт булган). Ләкин ул азан әйтә белми. Гыйззетдин азан әйтә, ә Семен сөлгене менеп ала.

Еллар узгач, манараны төзүче булган Гыйззетдингә манараны кисәргә кушалар. Ул авылның укымышлы кешесе Мифтахетдин Фәхретдит улына елап килә. “Аккан суга каршы барып булмый, кис, Гыйззетдин”, – дип киңәш бирә Мифта-


1880 года Февраля 3го дня, мы, ниже подписавшіеся,
Казанской губерніи, Мамадышскаго уѣзда, Сатышев-
кой волости, Ямбулатовскаго сельскаго общества,
/ деревни Ямбулатовой/ состоящаго изъ 216ти ревиз-
скихъ мужескаго пола душъ / Магометанскаго вѣ-
роисповѣданія/ и изъ „82х“ домовъ, домохозяева
всего „80ти“ человѣкъ, будучи сего числа на сельскомъ
сходѣ въ присутствіи сельскаго старосты Матигул-
лы Габбдуллина, гдѣ имѣли между собою сужде-
ніе и постановили сей приговоръ въ томъ, что сос-
тоящая въ нашей деревнѣ соборная мечеть въ
пожарѣ бывшемъ въ 1867 году сгорѣла, и таковой для
совершенія богослуженій, вновь не построено; а
потому ОПРЕДѢЛИЛИ: ходатайствовать предъ
Правительствомъ, о разрѣшеніи постройки въ на-
шей деревнѣ новой деревянной мечети, на благотво-
рительныя средства отъ прихожанъ и посторон-
нихъ лицъ. – Мечеть предположили построить по
среди деревни на дворичномъ мѣстѣ изъ среды
насъ Башира Тагирова, для чего домъ его снес-
ти на нашъ счетъ на другое плановое мѣсто, а
для образованія площади не меньше двадцати
саженъ кругомъ, если понадобится снести и дру-
гіе дома. Мечеть построить съ минарой, пяти
стенную, съ пристройкою дощаныхъ сѣней, размѣромъ
длиною 7 саженъ, шириною 3 саженъ и 1 аршинъ.
При этомъ обязываемся доставлять средст-
ва на содержаніе мечети и состоящаго при ней
духовенства. Къ тому присовокупляемъ, что въ
обществѣ нашемъ крещенныхъ татаръ нѣтъ.
Для наблюденія за правильной постройкой ме-
чети и ходатайства объ оной, избрали изъ
среды себя въ повѣренные крестьянина Гай-
нутдина Салимзянова, человѣка поведенія хо-
рошаго, не бывшаго подъ судомъ и слѣдствіемъ.
Въ этомъ составя приговоръ сей представляемъ

Ямбулатта мәчет төзергә рөхсәт сорау үтенече бите күчермәсе. 1880 ел

хетдин. Кисмәсә, төрмә булачагын аңлый ул. Манараның төп кисүчесе Шәриф исемле була.

Интернет мәгълүматлары буенча, Ямбулаттагы кебек манаралы җәмигъ мәчет төзергә 200 ир заты булган авылларда гына рөхсәт ителгән. Җомга намазлары бары тик җәмигъ мәчетләрдә генә укылган. 200 дән ким ир заты булган авылларда мәчетләр манарасыз төзелгән һәм биш вакыт намаз уку өчен генә хезмәт иткән.

1880 елда төзергә рөхсәт алынган мәчетнең манарасы 1939 елның көзендә киселә. Шул уңайдан Юлбат халкы бәет чыгара:

И, манара, син киселгәч,
Барча кошлар таралды.
И, манара, син булмагач,
Ислам дине таркалды.
Манараны кисәләр, дип
Бала-чага чабышты.
И, манара, син булмагач,
Бетте азан тавышы...



1939 елда Юлбат мәчетеннән төшерелгән ярымай

Манара киселсә дә, диннән язмый авыл халкы, киресенчә, күңел түренә, эчкәрерәк сеңә бара иман нуры. Киселгән манараның аен да кайбер авыллардагы кебек юкка чыгармаган халкым, ә бәлки, яшереп, хуҗалыкларда саклаган. 1939 елдагы кладовщик Хуҗин Зиннур аны алып кайтып, келәтендә чит күзләрдән яшереп куя. Ул үлгәннән соң хатыны Фатиха иреннән калган ядкарь итеп кадерләп саклый. Фатиха әби вафатыннан соң, мәчетнең ае Мөбәрәкҗанов Рәфискә күчә. 1995 елда, мәктәптә туган якны өйрәнү музее ачылгач, ул аны музейга тапшырды. Шулай итеп, Ярымай 56 елдан соң музей түрендә урын алды. Хәзерге көндә ул иң кадерле экспонат булып саклана.

Манарасы киселгән мәчет бинасы авыл халкына озак хезмәт итә әле. 1961 елда сүтеп үзгәртелеп, ремотланып, 1986 елга кадәр клуб, мәдәният йорты хезмәтен үтәде. Шул елның декабрь аенда мәдәният йорты яңа төзелгән бинага күчерелде. Мәчет бинасында 1987 елның ноябрендә колхозның балалар бакчасы ачылды. Күпне күргән мәчет бинасы 1993 елда сүтеп алынып, башка урынга күчерелеп, ике гаиләлек фатир итеп төзелде.

Туксанынчы еллар башында, үзгәреш җилләре исә башлагач, авыл халкы мәчет төзү турында уйлана башлый. 1993 елның кышында авылыбызда мәчет төзү мәсьәләсе буенча авыл җыены үткәрелә. Карар бертавыштан кабул ителә. Шушы җыенда булачак изге йортның мөтәвәллияте сайлана. Мәчетне төзетүне

авыл халкы күмәк предприятие рәисе Габдрахманов Наил Афзал улына йөкли. Саваплы, изге эш әнә шулай башлана. Башланган эшкә Ходай үзе ярдәмен дә бирә. Мәчет 1996 елның 31 декабрендә ачыла да инде. Аны "Международная исламская организация спасения" дигән оешма төзетә. Габделвәли абзый әйтүенчә, бу оешма Татарстанда 37 мәчет төзеткән. Безнең мәчет – иң соңгысы. Нигезе 1993 елда әзәрбайҗаннар тарафыннан салына. Стенасын 1994 елда Кукмара осталары өя. Түбә, түшәмнәрен тагын әзәрбайҗаннар эшли. Газ, электр кертү, эчке эшләре күмәк предприятие көче белән башкарыла.

Мәчет ачылу тантанасы изге Рамазан ае башланган көнгә туры килде. Тантанада "Международная исламская организация спасения"дән вәкилләр, Казаннан, район мәчетеннән дин әһелләре катнашты. Тантананы ул вакыттагы җирле үзидарәнең Юлбат авыл Советы рәисе Кәримов Раил Рифкатович ачты.

Хәзер шушы мәчетләрдә хезмәт куйган дин әһелләрен барлап китик. Авылның халык хәтерендә сакланып калган иң беренче мулласы – Баһманов Мөхәммәтшакир. Архив материалларыннан күренгәнчә, Мөхәммәтшакир – Ямбулат (Юлбат) авылында туып-үскән дәүләт крестьяны. Аңа кадәр булган мулла Ибәтулла Ваһапов, өлкәнәеп 73 яшькә җиткәч, үзе олы яшьтә булу сәбәпле, мәхәллә эшләрен, дини йолаларны башкару, балаларны укыту өчен үзенә ярдәмче сорый. 1875 елда Мөхәммәтшакир үз гаризасы нигезендә икенче мулла итеп куела. Указлы мулла Ибәтулла Ваһапов аңа рекомендация бирә. Белгәнебезчә, муллалар авылда төп документ эшләрен алып барганнар (кеше туу, үлү, аерылышу һ.б.) һәм, дәүләт чиновниклары кебек, бөтен төр документлар буенча дәүләткә отчет бирергә тиеш булганнар. Муллаларны билгеләүдә дәүләт органнары турыдын-туры катнашкан. Бик күп сынаулар үткәннән соң (алар турында соңрак язып үтәрбез), 28 яшьлек Баһманов Мөхәммәтшакир (1848 елның 15 январенда туган) Ямбулат авылына икенче мулла итеп сайлана. Авыл җыенында мәхәллә халкы Ибәтулла мулланы да үлгәнче тәэмин итеп торырга йөкләмә ала, аның вафатыннан соң Мөхәммәтшакирның төп мулла булып калачагы турында карар чыгара.

Ул гомеренең соңгы көннәренә кадәр безнең авылда мулла булып тора. Хатыны Әнвәрә абыстай – Айдар авылы мулласы кызы. Юлбатта Әнвәрәне "юан абыстай" дип йөрткәннәр. Ул тирә-юньдә дан тоткан үлән белән дәвалаучы булган, бик күп авыруларга ярдәм иткән. Кыз балалаларга дин сабагы бирергә дә вакыт тапкан.

Мөхәммәтшакир хәзрәт малайларга дин белеме биргән. Аларның нигезендә бүгенге көндә укытучы Фәләхов Замирлар яши. Күршеләрендә яшәүче 1906 елда туган Гыйлаҗиев Габделхай (1993 елда вафат булды) хәзрәтнең кучеры була. Мулланың улы Каюм, килене Тәскирә исемле. "Тәскирә һәм Тәскирәнең сеңлесе Әминә укымышлы иделәр. Алар кыз балаларга дин сабагы бирделәр". (Юлбатта яшәүче 1910 елда туган Мансурова Газамбану истәлегеннән)".

Мөхәммәтшакир мулланың улы Каюм да муллалыкка укып кайта. Ләкин илдә барган үзгәрешләр – Октябрь революциясе нәтиҗәсендә Каюм муллалык эшен ташларга мәҗбүр була. Улы Каюм диннән тайпылган кайгыны күтәрә алмыйча, Мөхәммәтшакир хәзрәт акылдан яза һәм 1921 елда вафат була. Юлбат авылы зиратында җирләнә.

Каюм (мулла) сәүдәгәрлек белән шөгыльләнгән, шул ук вакытта яшертен генә балаларга белем биргән. Бераздан ул Сатыш мәдрәсәсендә укыта башлый. Ул шулай ук Саба район мәгариф бүлеге инспекторы, Мамадыш кантонының мәгариф бүлеге мөдире булып эшли". (Гыйләҗиев Габделхай истәлегеннән). Муллалык вазифасыннан баш тартуга карамастан, Каюм кулга алына, төрмәдән кире кайтмый.

Баһманов Шәймәрдән (ул Мөхәммәтшакир хәзрәтнең бертуган энесе) бик укымышлы була. Алар нигезендә бүгенге көндә Хәмитов Раушан гаиләсе яши. Хатыны Шәрифә, әниләре Фәхри абыстай балаларга дин сабагы бирә". (Юлбат авылында яшәүче 1911 елда туган Мөхәммәтҗанова Газизә истәлегеннән). Авылда укымышлы кешеләр шактый булган, алар үзләренең белемнәрен балаларга биргәннәр, шулардан: Мәрдәнова Минзифа, Сабира абыстай, Мифтахетдин абый.

1924 елда Юлбат авылына Балык Бистәсе районы Котлы Бөкәш авылыннан 1879 нчы елгы Мөхәммәдша угылы Мөхәммәтшакир хәзрәтне китерәләр. 1937-1938 нче елларда аны кулга алалар. 10 ел төрмәдә утырып, авылга әйләнеп кайта. 1961 елда 81 яшендә вафат була. Юлбат зиратында җирләнгән (хәзрәт турында тулырак итеп аерым язылды).

Мөхәммәтшакир мулланың кабере Баһманов Мөхәммәтшакир хәзрәтнеке белән янәшә. Алар икесе дә халык хәтерендә яши.

Мөхәммәтшакир төрмәдә вакытта аның эшен Фәтхуллин Нотфулла, Фәтхуллин Гайфулла, Фәтхуллин Сәйфуллалар дәвам итә. Аннан соң хәзрәт үзе кайтып авылга игелекле хезмәтен башкара. 1961 елда, ул үлгәч, бер ел Галиәскәр муллалык эшен алып бара. Аның эшен Исламов Ихсан дәвам итә. 1992 елда Ихсан бабай да вафат була. Шул көннән башлап бүгенгәчә (22 ел) бу изге эшне Фәтхуллин Габделвәли абый алып бара. 1996 елда мәчет ачылганнан бирле биш вакыт намазның берсендә генә дә, һава торышының нинди булуына карамастан, мәчетнең ачылмый калганы юк. Күңелләргә иман нуры иңдереп, авылны хәвеф-хәтәрләрдән саклап һәр көнне биш вакыт азан яңгырый.

Җомга намазларын иманлы халкыбыз мәчетләр эшләмәгән елларда да аерым хуҗалыклар өендә укырга тырышкан. Җәмәгать намазлары Фәхриев Кашап абый өендә (хәзер ул урын буш тора, Кадыйров Хәйдәрләр янында), Мәрдәнов Фәйзрахман абыйларда (хәзер Фәләхов Наилләр гаиләсе яши), 1953 еллардан 1996 елга кадәр Фәтхуллин Габделвәли абыйлар өендә укылган.

Габделвәли абый 1995 елда мәчетне төзеткән оешмада дин белемен камилләштереп документ ала, бер үк вакытта 1995 елның 1 мартында авылның 538 нче мәхәллә буларак теркәлүенә ирешә. 1995 елдан Габделвәли абзый имам-хатыйп вазифасында.


Ә хәзер авылга мулла булып билгеләнү өчен нинди сынаулар үтәргә кирәклеген Баһманов Мөхәммәтшакир мисалында карап үтик.

1875 елның 28 сентябрендә авыл җыены була. Анда Баһманов Мөхәммәтшакирның икенче мулла булырга сораган үтенече карала. 77 кеше кул куйган беркетмә төзелә. Беркетмәгә өч печать: авыл старостасы Шәрәфетдинов Зәйнетдиннең, Сатыш волосте старшинасының, Сатыш волосте идарәсенең –

печатьләре куела. Мамадыш өязе Сатыш волосте идарәсенә справка җибәрелә. 31 октябрьдә Мамадыш өяз полиция идарәсеннән Казан губерна идарәсенә рапорт җибәрелә. Бу документта авыл мәхәлләсе тарафыннан икенче мулла итеп күрсәтелгән Мөхәммәтшакир Баһмановның суд җаваплылыгына тартылмган кеше булуы, мәхәллә карарының урынга барып тикшерелүе, документларның дөрес төзелүе әйтелгән. Шулай ук Ямбулатта һәм якын-тирәдә керәшеннәр булмавы ассызыкланган.

Мөхәммәтшакир мулланың “Дело”сына 1875 елның 28 сентябрендә бирелгән Метрическая справка теркәлгән. Справканы Сатыш волосте старшинасы раслап печать суккан. Гайнетдин исемле, фамилиясен укып булмады. Справка өчен 40 тиен көмеш белән түләнгән.

15 октябрьдә Мөхәммәтшакирның дини белемнәре тикшерелә. Бу имтихан Император Александр Николаевич указы белән Оренбург Диния нәзарәте тарафыннан үткәрелә. 16 октябрьдә Оренбург мөфтие кул куйган таныклык бирелә. Таныклыкта дәүләт крестьяны Баһманов Мөхәммәтшакирның сынау нәтиҗәсендә имам-җәмигъ, хатыйб, мөгаллим булырлык белемнәрен күрсәтүе, ләкин Губерна идарәсендә расланып, мәхәллә тарафыннан сайлангач кына бу вазыйфаларны башкарырга хокук алачагы әйтелә. 40 тиен көмеш түләнә. Таныклык күчермәсе язып бирелә. (Искәрмә: муллаларның дини белемнәрен генә түгел, рус телен белүләре дә тикшерелгән. Мөхәммәтшакир “Дело”сында ул турыда таныклык теркәлмәгән, чөнки ул тәртип 1890 елда кертелгән. Ә менә Теләчә районы Ямбулат авылына 1895 елда билгеләнгән мулла “Эш”ендә рус теленнән сынау үтүе турында таныклык саклана. Безнең авылга 1924 елда килгән мулла да ул сынауны үткән булган.)


№261.

ДѢЛО

НАЧАЛОСЬ 1875 ГОДА.

КОНЧИЛОСЬ 1875 ГОДА.

Фонд № 2
Опись № 2
Дело № 664

Отдѣленіе
Столъ

НА ЛИСТАХЪ.

Ямбулат авылына мулла билгеләү “Дело”сы тышы. 1875 ел

24 декабрьдә кабат мәхәллә җыены үткәрелә. Баһманов Мөхәммәтшакир икенче мулла итеп сайлана.73 катнашкан кешенең исемнәре язылып кул куйган документ Губерна идарәсенә җибәрелә.

27 декабрьдә Казан Губерна идарәсендә Мамадыш өязе Сатыш волосте Ямбулат авылы мулласын раслау эше карала. Анда Ямбулат авылында туып-үскән дәүләт крестьяны Баһманов Мөхәммәтшакир имам, җәмигъ, хатыйб, мөгаллим вазыйфаларына билгеләнә.

30 декабрьдә Мамадыш өязе полиция идарәсе Казан Губерна идарәсенә Ямбулат авылы мәхәлләсе халкының үз авылдашларын җәмигъ мәчеткә икенче мулла итеп сайлауда закон бозмыйча дөрес эш итүләрен раслап кабат рапорт яза. Мәгълуматлар Татарстан республикасы Милли архивыннан алынды (фонд 2, опись 2, том 1, Дело №664).

Шул билгеләнүдән Мөхәммәтшакир Баһманов 1921 елга кадәр (46 ел) мулла вазыйфаларын башкара. 73 яшендә вафат була.

1890 елдан соң муллаларның “Дело”ларында гарәп шрифты һәм кириллицада басылган ант тексты да теркәлгән. Шулардан берсен китерәбез:

Клятвенное обещание

Я, нижепоименованный, обещаюсь и клянусь Всемогущим богом, Перед святым его Алкораном, в том, что хочу и должен ЕГО ИМПЕРАТОРСКОМУ ВЕЛИЧЕСТВУ, своему истинному и природному ВСЕМИЛОСТИВЕЙШЕМУ ВЕЛИКОМУ ГОСУДАРЮ ИМПЕРАТОРУ НИКОЛАЮ АЛЕКСАНДРОВИЧУ, САМОДЕРЖЦУ ВСЕРОССИЙСКОМУ и законному ЕГО ИМПЕРАТОРСКОГО ВЕЛИЧЕСТВА, Всероссийского Престола Наследнику, Цесаревичу и Великому Князю Георгию Александровичу, верно и нелицемерно служить и во всем повиноваться, не щадя живота своего до последней капли крови, и все к высокому ЕГО ИМПЕРАТОРСКОГО ВЕЛИЧЕСТВА Самодержавству, силе и власти принадлежащия права и преимущества, узаконенная и впредь узаконяемыя, по крайнему разумению, силе и возможности, предостерегать и оборонять, и притом, по крайней мере старатися спосопшествовать все, что к ЕГО ИМПЕРАТОРСКОГО ВЕЛИЧЕСТВА верной службе и пользе государственной во всяких случаях касаться может; о ущербе – же ЕГО ВЕЛИЧЕСТВА интереса, впредь и убытке, как скоро о том уведаю, не токмо благовременно объявлять, но и всякими мерами отвращать и не допущать тщатися, и всякую вверенную тайность крепко хранить буду, и поверенный и положенный на мне чин, как по сей (генеральный) так и по особливой, определенной и от времени до времени ЕГО ИМПЕРАТОРСКОГО ВЕЛИЧЕСТВА Именем от представленных надо мною начальников определяемым инструкциям и регламентам и указам, надлежащим образом по совести своей исправлять и для своей корысти, свойства, дружбы и вражды противно должности своей и присяги не поступать, и таким образом себя весть и поступать как верному ЕГО ИМПЕРАТОРСКОГО ВЕЛИЧЕСТВА подданному благопристойно есть и надлежить; и как я пред Богом и судом Его страшным в том всегда ответ дать могу, как суще мне Господь Бог душевно и телесно да поможет. В заключение же сей моей клятвы целую слова Святого Алкорана. Аминь.

1896 года января 29 дня.

Искәрмә: Ант тексты шул вакыттагы стильдә үзгәртмичә бирелде.

**Метрикәләр турында өстәмә мәгълүмат.**

Россиядәге муллаларга 1829 елда өстәмә бер вазыйфа – үз мәхәлләсендә һәр елда туган, үлгән, никахлашкан һәм аерылышкан кешеләрне махсус дәфтәргә язып бару йөкләнгән.

Мөселман мәхәлләләрендә метрикә дәфтәрләрен язуны гамәлгә кертү турында Россия хөкүмәте (Сенат) 1828 елның 21 сентябрендә махсус фәрман чыгарган. Шуның нигезендә Оренбург Мәхкәмәи шәргыясе (Диния нәзарәте) мәхәлләләргә 1829 елга метрикә дәфтәрләрен җибәреп, һәр дәфтәр өчен имамнардан акча алу каралган. Имамнар метрикәне икешәр нөсхәдә язып барып, бер нөсхәсен үзләрендә калдырырга, ә икенчесен, ел беткәч тә, Нәзарәткә тапшыру өчен, өяз земство судына бирергә тиеш була. Метрикә язмаларын алып бару буенча бердәм таләпләр куелган, үзгәрешләр кергән очракта, вакытында күрсәтмәләр бирелгән. Мәсәлән, Нәзарәтнең метрикә дәфтәрләрен алып бару буенча 1893 елның 15 октябрь кагыйдәләрендә яңа туган балаларга күркәм һәм шәригать рөхсәт иткән исемнәрне генә кушарга, үле туган балаларны метрикаларга язмаска күрсәтмә бирелгән. Шулай ук яңа туган балага куелган исемнең дөрес итеп язылуы таләп ителгән.

Дәүләт кануны буенча да никах уку өчен кызга 16, ә егеткә 18 яшь тулган булуы таләп ителгән. Россиянең җинаять һәм җәза турындагы 1885 елгы законнары нигезендә, әгәр дә кызның ризалыгыннан башка, аны урлап никах кылынса, гаепле кешене Себергә сөрергә яисә 1-4 елга төрмәгә ябу, ә кызны куркытып никахлашучыларга тагын да кырысрак җәза каралган. Кияүгә чыгучы кыз риза булмаган килеш, аны риза булды дип ялган шаһитлек кылучылар, бөтен хокукларыннан мәхрүм ителеп, Себергә сөрелергә яисә ел ярымга төрмәгә хөкем ителергә тиеш булган.

Шулай итеп, татар авылларында Метрикәләр 1829-1930 еллар аралыгында алып барылган һәм Казанга архивка җибәрелгән. Милли архивта безнең авылның 1865-1901 еллардагы метрикәләре саклана. (Фонд №204, опись №117, том 1). Архивта булмаганнары Казанда булган янгыннар вакытында янган яки 1917 елгы революция чорында юк ителгән булырга мөмкин. Тарихи чыганаклардан билгеле булганча, Казан шәһәрендәге янгыннардан 1595, 1672, 1749, 1754, 1815, 1842 елгылары иң зурлары булган. 1815 елгы янгында элеккеге Казан губерна канцеляриясенең архивы янып юкка чыккан.

## Халыкка багышланган гомер

1924 елда авылга Мөхәммәдша улы Мөхәммәтшакирны хәзрәт итеп китерәләр. Ул 1880 елда Балык Бистәсе районы Котлы Бөкәш авылында туган. Әтисе авылларында мулла була, ике мәртәбә хаҗга барып кайта. Ә өченче баруында, ваба чире белән йогышланып, фани дөньядан китеп бара. Бу вакытта Шакирга нибары 3 яшь була, ул әтисенең абыйсы гаиләсендә тәрбияләнеп белем ала. Аннары шул районның Түбән Тегермәнлек авылында үзенең дини хезмәтен башлап җибәрә, өченче мәхәлләгә мулла булып килә. Хезмәтен 1924 елга кадәр,

ягъни 20 еллап дәвам итә, ә 1924 елдан ул, 6 җаннан торган гаиләсе белән Юлбатка күченеп килеп, мулла вазыйфасын үз өстенә ала. Шакир 10 олау белән яңа урынга күченеп килә һәм мәчет янында авылдашларының ярдәме белән хуҗалык җиткерә, эш башлый.

Аны беренче тапкыр 1929 елды кулга алалар, үлем җәзасына хөкем итәләр. Әлбәттә, Котлы Бөкәштәге туганнары бу хәлгә битараф калмый. Мөхәммәтшакирның гаепсез икәнлеген, ятимлектә интегеп үсүен дәлилләп, 300гә якын имза җыеп, аны төрмәдән азат итүгә ирешәләр. Әмма куаныч озакка бармый, 1937-1938 елларда аны, советка каршы пропаганда алып баруда гаепләп, кабат кулга алалар һәм 10 елга хөкем итәләр. Шакир, үзенең срогын Архангельск өлкәсендә урман эшендә тутырып, Юлбатка кайта.

"Мулла абзый, авылга кайткач, мәет озату, балага исем кушу, никах уку, яшереп кенә булса да җомга намазы уку кебек йолаларны намус белән башкарып килде, кешеләргә изгелек кылды.

Төрмәдән кайткач та беренче елларны бик авыр булды күршебезгә. Алар башта мунчаларында тордылар. Йорт-җир, каралты-кура конфискацияләнеп, сүтеп алынган иде. Мулла абзыйның олы улы Хәлим абый да, шушы кыенлыкларны җиңеп чыга алмыйча, 1937 елда, 21 яшендә, авырып китте, шуннан терелә алмады. Ә Рәшит исемлесе 1938 елда хәрби комиссариат аша укырга китеп, сугышны башыннан ахырынача диярлек кичте. Ул 1945 ел башларында авыр яраланып кайтты һәм II группа сугыш инвалиды буларак зур кадер-хөрмәттә яшәде. Үзенең васыяте буенча Юлбатка алып кайтып, әтисе янәшәсендә җирләнде.

Мулла абзый сугыштан соң үзенең җыйнак кына йортын шул Рәшит улы булышлыгы белән әмәлләгән иде. Анда абыстай белән 1961 елга кадәр гомер иттеләр. Мулла абзый шул елны 81 яшендә кинәт вафат булды. Җәмилә абыстай исә тагын 13 ел яшәде. Казандагы кече кызы Сәлимә тәрбиясендә булды. Абыстай гаҗәеп киң күңелле, ярдәмчел, шәфкатьле кеше иде. Аш-су ризыклары пешергәч, аның безне, ач күрше малайларын, чакырып авыз иттерүе, кешеләрдән аштан (кунактан) кайткач, күчтәнәчтән өлеш чыгарулары бүгенгедәй хәтеремдә. Мөхәммәтшакир хәзрәтнең хатыны Җәмилә абыстай Чәбки-Саба (Чәүкә) авылының Вәли бай кызы була. Алар Хәлим (1916), Рәшит (1918), Суфия (1922), Сәлимә (1924) исемле балалар үстерәләр". (Бу юллар Мөхәммәтшакир мулланың күршесе Сәйфуллин Сәлимнең "Бер үк язмыш каккан" дигән мәкаләсенә нигезләнеп язылды. "Саба таңнары", №70, 1 июль, 1995 ел. Ул Юлбат авылының соңгы указлы мулласы турында аның малае Рәшит һәм кызы Сәлимә сөйләгәннәрдән һәм үзенең яшьлек хәтерендә калганнарга нигезләнеп язуын әйтә.)


Мөхәммәтшакир хәзрәт

Мөхәммәтшакир хәзрәтнең улы Рәшит, әтисе үлгәч, йорт-нигезен Бәдәр исемле апага сата. Бәдәр

апа үлгәч, бу нигездә медпункт төзелә. Хәзерге көндә, медпункт мәдәният йорты бинасына күчерелгәннән соң, ул бинада почта бүлекчәсе урнашкан. Ә почтаның тирә-ягында хәзрәт утырткан алмагачлардан чыккан үсентеләр бүген дә алма биреп утыралар.

Бүгенге көндә Мөхәммәтшакир мулланың бер баласы да исән түгел инде. Алда әйтелгәнчә, улы Рәшит әтисе янәшәсендә, иң соңыннан вафат булган кызы Сәлимә шулай ук Юлбат зиратында җирләнгән.

Хәзерге вакытта хәзрәтнең оныгы Габдрахманов Рафыйк Фәизович белән элемтәбез бар. Ул – Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институтында фәнни хезмәткәр. Мөхәммәтшакир мулланың бердәнбер фоторәсемен дә ул бирде. Муллаларга рус телен мәҗбүри өйрәнү таләбе куелгач, имтихан бирергә фото белән килү тәртибе кертелгән, чөнки кайбер муллаларның үзе урынына башка кешене җибәрү очраклары булган. Шул сәбәпле Мөхәммәтшакир хәзрәт тә фотога төшәргә мәҗбүр булган. Фоторәсем мәктәп музеенда кадерләп саклана.

## Тенеки мәчете тарихы

*(Тенеки мәчетенең төзелү, ремонтлану вакыты турында башка төрле истәлекләр дә бар, әмма без 1904 елда Тенекидә туган Хәмидулла Хуҗиәхмәтов язмаларыннан өзек кенә китерәбез.)*

1890 елларда Казанда торучы сатучы (күмәчче) Исмәгыйль хаҗи Тенекидә агачтан мәчет салдыра. Ул үзе Килдебәк кешесе, хатыны Тенекинең мулла кызы була. Бу мәчетне 1907 елда ремонтлыйлар: түбәсен калай белән ябып, стена-



Тенеки мәчете бинасының мәктәп хезмәтен үтәгән вакыттагы күренеше. 2008 ел

сын такта белән төрәләр. Аны Комар Саурышы дигән авылның Мөхәммәтшин Галиәхмәт, Шәмсетдинов Шиһабилар эшли. Манарага менеп, мөнбәрнең аен кыйблага борып куярга Галиәхмәт үзе менә, аңа шуның өчен бер ситсы күлмәклек бирәләр. Күлмәклекне манарага тагып менгерәләр, манарада эшне үтәгәч, Галиәхмәт үзе чишеп алып төшә. “Бөтен авыл куркышып карап торды, малайлар белән мин дә шунда идем”, – дип яза Хәмидулла Хуҗиәхмәтов.

Тенеки мәчете бинасы 2008 елга кадәр башлангыч мәктәп өчен хезмәт итте. 2009 елда, авыл халкы көче белән ремонтланып, дин тотучыларга кайтарылды. Манарада кабат ай балкыды.

Мифтахов Хәнәфия үзенең Мифтахетдин бабасы белән Тенекигә менгәч, Тенеки мәчетенә беркетелгән калайдагы язуны күрүен яхшы хәтерли. Ул вакытта Хәнәфия абый мәктәп яшендәге укый-яза белүче бала була. “Алты кырлы итеп киселгән калайга “1887, Госстрах” дигән сүзләр язылып, мәчет стенасына югарыга беркетелгән иде”, – ди. Белгәнебезчә, мәчетләрне Дәүләт страхованиесы оешмасы иминиятләштергән. Сатыш мәдрәсәсенә кагылышлы шундый документ Казан Милли архивында саклана. Тенеки мәчете, төзелгән елны ук иминиятләштерелгән булса, 1887 елда, бәлки, аннан да алданрак төзелгәндер.

Тенеки мәчетенә кагылышлы материаллар Казан архивларында табылмады. Бары тик Габдулла мулланы билгеләү турында документлар белән генә таныша алдык.

### Габдулла Габделнасыйровны Тенекигә мулла итеп билгеләү турында “Эш”тән

1876 елда указлы мулла Габделнасыйр Ногманов үлә. 1978 елның 30 октябрендә аның улы Габдулла Габделнасыйровның әтисе урынына мулла итеп куюны сораган үтенече По речке Уръ (Тенеки) авылы җыенында карала. Габдулланың шушы авыл кешесе булуы, 22 яшьтә икәнлеге әйтелгән. Габдулла бу җыенга Уфа губернасы, Стәрлетамак өязе, Маркитман волосте Уршакбаш Ямгурчина авылыннан килгән, үзенең әлеге авыл общинасыннан 1877 елның 11 мартында авыл җыены рөхсәте белән чыгуы турында карар да алып килгән. Бу карарда аның тәртипле булуы, суд җаваплылыгына тартылмавы язылган. Габдулла Тенеки һәм Уфа губернасы авылы җыены документларының икесендә дә шул авыл кешесе дип күрсәтелә. Мөгаен, Тенеки халкы хәтерендә сакланганча, әтисе Габделнасыйр мулла Уфа губернасыннан килгән булгандыр, улы Габдулланы, үскәч, үзенең туган ягына җибәргәндер.

1879 елның 17 гыйнварында Казан губерна идарәсенә Мамадыш өязе полиция идарәсеннән Габдулла Габделнасыйровның По речке Уръ авылы җыенында җәмигъ мәчеткә мулла итеп сайлануы турында рапорт китә. Унынчы халык саны алу нәтиҗәләре буенча авылда 307 ир (душ мужского пола) булуы, шуларның 86сы тавыш бирү хокукына ия булуы әйтелә. Авыл җыены карарында 86 фамилия язылган. (Татарстан Республикасы Милли архивы, фонд 2, опись 2, том 1, дело №1401)

Тарихи мәгълүмат. 22 яшькә җиткән кешене генә мулла итеп куярга, мөмкинлектән чыгып, мулла малайларын әтисе урынына билгеләргә, дигән тәртип кертелгән еллар да булган. Әтисе үлеп, ике ел үткәннән соң мулла булып кайтуының сәбәбе, бәлки, Габдуллага 22 яшь тулганны көтү булгандыр.

## Репрессияләнгән якташларыбыз


*Мәгълүматлар "Сәяси репрессия корбаннарының Хәтер китабы"ның икенче томы ("Б"), өченче томыннан ("В", "Г") китерелә*

Баһманов Ширияздан Шаһимәрдән улы, 1888 елда Саба районы Юлбат авылында туган, Кукмара поселогында яшәгән. Татар, пункт мөдире, "Татсоюзпушнина". 27.10.37 кулга алынган. ҖК 58-10 (1 бүл) м. буенча гаепләү белдерелгән. 23.2.38, дәлилләр расланмау сәбәпле, эш туктатылган.

Вилданов Төхвәт, 1885 елда Саба районы Юлбат авылында туган. Татар, крестьян. 17.10.37 кулга алынган. 10.11.37 ҖК 58-10 м. буенча хөкем карары: 10 елга хезмәт белән төзәтү лагерена җибәрү. 17.5.90 акланган.

Гайнетдинов Дәүләтша Гайнетдин улы, 1889 елда Саба районы Юлбат авылында туган, шунда яшәгән. Татар, 3 баласы булган, колхозда ат караучы. 1931 елда раскулачивать ителгән. 7.11.37 кулга алынган, 29.11.37 ҖК 58-10м. буенча хөкем карары: 10 елга хезмәт белән төзәтү лагерена җибәрү. 15.4.42 Коми АССР-да, Емва ш., 243 нче лагерьда вафат булган. 31.5.89 акланган.

Гайнетдинов Минһаҗетдин Гайнетдин улы, 1876 елда Саба районы Юлбат авылында туган, Мәртен авылында яшәгән. Татар, таза тормышлы крестьян, арендачы. 25.2.30 кулга алынган, 12.4.30 ҖК 59-10 м.буенча хөкем карары: алдан тоткынлыкта булу вакыты. 28.7.89 акланган.



Фәтхуллин Сәйфулла Фатхулла улы. Төрмәдә төшерелгән фото. 1937 ел

Ганиев Җәмил, 1891 елда Саба районы Тенеки авылында туган, Йосыф Алан авылында яшәгән. Татар, 2 баласы булган, колхозчы, "Магнит" колхозы. 11.9.45 ҖК 58-10 (2 бүл) м. буенча хөкем карары: 10 елга хезмәт белән төзәтү лагерена җибәрү. 16.12.92 акланган.

Гайнанов Әбҗәлил, 1888 елда Саба районы Тенеки авылында туган, Мамадыш районы Баскан авылында яшәгән. Татар, 5 баласы булган, мулла. 4.4.31 кулга алынган, 31.10.31 ҖК 58-10 (2 бүл), 58-11 м. буенча хөкем карары: 10 елга концлагерьга җибәрү. 28.7.89 акланган.

Шул ук "Хәтер китабы"ның ундүртенче томына кергән авылдашлар.

Фәтхуллин Нотфулла Фатхулла улы, 1885 елда Саба районы Юлбат авылында туган, шунда яшәгән, аерым хуҗалыклы крестьян. 58-10 м., 1937 елда ирегеннән мәхрүм ителгән, төрмәдә үлгән.

Фәтхуллин Сәйфулла Фатхулла улы, 1891 елда Саба районы Юлбат авылында туган, шунда яшәгән, аерым хуҗалыклы крестьян. 58-10 м., 1937 елда ирегеннән мәхрүм ителгән, төрмәдә үлгән.

## Кулак буларак милектән мәхрүм ителгәнәр

*(Мәгълүматлар "Сәяси репрессия корбаннарының Хәтер китабы"ның 25 нче томыннан алынды. Казан, 2011.)*

**Әхмәдиев Әхмәт**, 1918 елда Саба р-ны, Тенеки авылында туган, шунда яшәгән. Татар, крестьян.

10.06.1931 Саба РБК тарафыннан йорт-җиреннән, мөлкәтеннән мәхрүм ителгән һәм Чиләбе өлкәсенә сөргенгә җибәрелгән. 21.12.1992 акланган.

**Әхмәдиев Мөхәммәди**, 1906 елда Саба р-ны, Тенеки авылында туган, шунда яшәгән. Татар, крестьян.

Гаиләсе: әнисе Мәгъүзә (1886), кыз туганы Мәрьям (1911), кыз туганы Мәфтуха (1922), кыз туганы Шәмсеруй (1925, 1928). Гаилә 10.06.1931 Саба РБК тарафыннан йорт-җиреннән, мөлкәтеннән мәхрүм ителгән һәм Чиләбе өлкәсенә сөргенгә җибәрелгән. 21.12.1992 акланган.

**Баһавиев Зыятдин Баһави улы,** Саба р-ны, Юлбат авылында туган, шунда яшәгән. Татар, крестьян. 1934 елда Саба районы җирле башкарма органнары тарафыннан йорт-җиреннән, мөлкәтеннән мәхрүм ителгән. 20.5.1998 акланган.

**Гарипов Фатыйх Гариф улы,** 1902 елда Саба р-ны, Юлбат авылында туган, шунда яшәгән. Татар, крестьян. 1931 елда Саба районы җирле башкарма органнары тарафыннан йорт-җиреннән, мөлкәтеннән мәхрүм ителгән. 4.11.1997 акланган.

**Динмөхәммәтов Кадыйр,** 1867 елда Саба р-ны, Юлбат авылында туган, шунда яшәгән. Татар, крестьян. 2 кешедән торган гаиләсе 1932 елда Татарстан ҮБК тарафыннан йорт-җиреннән, мөлкәтеннән мәхрүм ителгән. 9.8.2011 аклаганнар.

**Кадыйров Насыйр Кадыйр улы,** 1883 елда Саба р-ны, Тенеки авылында туган, шунда яшәгән. Татар, крестьян. 1930 елда Саба районы җирле башкарма органнары тарафыннан йорт-җиреннән, мөлкәтеннән мәхрүм ителгән. 23.11.1998 акланган.

**Сабирҗанов Рәхим,** 1898 елда Саба р-ны, Тенеки авылында туган, шунда яшәгән. Татар, крестьян. Гаиләсе: хатыны Мәсрүрә (1900), улы Габделкарип (1926), кызы Мөнәвәрә (1930). Гаилә 1933 елда Саба РБК тарафыннан йорт-җиреннән, мөлкәтеннән мәхрүм ителгән һәм Архангельск өлкәсенә сөргенгә җибәрелгән. 11.4.1997 акланган.

**Сәләхетдинов Гыйльметдин Гыйззетдин улы,** Саба р-ны, Юлбат авылында туган, шунда яшәгән. Татар, крестьян. 1932 елда Саба районы җирле башкарма органнары тарафыннан йорт-җиреннән, мөлкәтеннән мәхрүм ителгән. 25.11.1998 акланган.

**Сәләхетдинов Кәрим Сәләхетдин улы,** 1896 елда Саба р-ны, Юлбат авылында туган, шунда яшәгән. Татар, крестьян. 1933 елда Саба районы җирле башкарма органнары тарафыннан йорт-җиреннән, мөлкәтеннән мәхрүм ителгән. 19.5.2003 акланган.

**Фәтхуллин Гайфулла Фатхулла улы,** 1888 елда Саба р-ны, Юлбат авылында туган, шунда яшәгән. 1934 елда Саба районы җирле башкарма органнары тарафыннан йорт-җиреннән, мөлкәтеннән мәхрүм ителгән. 1.7.2005 акланган.

**Шәфигуллин Нәбиулла Рәхмәтулла улы,** 1892 елда Саба р-ны, Тенеки авылында туган, шунда яшәгән. Татар, крестьян. 1930 елда Саба районы җирле башкарма органнары тарафыннан йорт-җиреннән, мөлкәтеннән мәхрүм ителгән. 15.9.1999 акланган.

**Шәфигуллин Сабир Шәфигулла улы,** 1894 елда Саба р-ны, Тенеки авылында туган, шунда яшәгән. Татар, крестьян. 1930 елда Саба РБК тарафыннан йорт-җиреннән, мөлкәтеннән мәхрүм ителгән. 26.3.1998 акланган.

**Җамалетдин улы Шиһабетдин** әлеге китапка кертелмәгән, ләкин аның турында түбәндәге мәгълумат билгеле. Хәтер китаплары тулыландырылып басылганда, бәлки, урын алыр. Аның турында Халикова М.Г. язып биргәннәрдән:

Әнием Асиянең бабасы Шиһабетдиннең өч кызына (Хәйрелхисал, Уйсал, Хәбибә, Шамил соңрак туган) имана җире тимәгән. Бик яхшы тегүче булган, өязгә чыгып акча эшләгән, шул акчага арендага җир алып, иген иккән, шәп алма бакчасы үстергән, хәлле тормышта яшәгән. Кулак дип, нахакка гаепләнеп, Магнитогорскига җибәрелә. Юлда эзсез югала. Хатыны – әнинең әбисе – Хәмиделхисал исемле була.



Ильясов Якуп (1870 елда туган) үзенең гаиләсе белән. Аның төпчек кызы Якупова Оркыя (минем әни) беренче рәттә сулдан өченче. Туганнар сөйләве буенча, өч буын – бабасы, әтисе, Якуп үзе авылның старостасы булганнар. 1930 елларда Якупның мөлкәте өлешчә тартып алына

**Гаепсездән рәнҗетелеп һәлак булган Кадыйр бай турында бәян-хатирә**

Кадыйр бай. Кем булган соң ул?

Юлбат авылында (авылның элеккеге исеме Ямбулат булган) кеше хезмәтен файдаланып байлык туплаган зур байлар, алпавытлар булмаган. Хәлле кешеләр, бары хезмәт куеп, тырышып кына көн күргәннәр.

Хәзерге көндә Билалов Рифкать яшәгән хуҗалык нигезендә Вилдан исемле кеше яшәгән. Аның Газанбану исемле хатыны, Төхбәтулла исемле малае булган. Ул шактый таза тормышта яшәгән. Күп итеп умарта асраган.

Вилданның төньяк күршесе Динмөхәммәт исемле, аның Кадыйр, Кәрим, Биктаһир исемле уллары һәм Фәизә исемле кызы булган. Алар шулай ук таза хәлле крестьян булганнар. Алар нәселеннән бу йорт-җир ихатада бүген яшәүче юк, буш тора.

Кадыйр үсеп егет булгач, Вилданга батрак булып яллана, чөнки җир чәчеп, икмәк үстереп кенә тормыш алып бару авыр була. Җир дә аз була. Авыру сәбәплеме яки башка сәбәп беләнме, Вилдан үлеп китә. Шуннан тол калган Газанбану батрагы Кадыйрны йортка кертә. Кадыйр – аның ире һәм хуҗалык башлыгы булып кала. Динмөхәммәтнең калган балалары язмышы:

Кызы Фәизә – авылның Зәйнулла исемле кешесенә кияүгә чыга. Зәйнуллин Тәфкил – аларның оныгы.

Кәрим 20 ел патша армиясендә солдат хезмәтендә була, кайткач туганы Кадыйрның умарта чүннигендә каравылда тора. Алга таба язмышы билгесез. Биктаһир төп йортта кала, Җөри авылыннан Бибиҗамал исемле кызга өйләнә. Биктаһир арендага Мәртен авылы кешеләреннән җир алып чәчә торган була. Мәртендә җиргә иркенлек була. Аларның алты баласы була: беренчесе – Сабирҗан (1906-1969), аның балалары – Сәлимә, Миңтаһирә, Роза; икенчесе – Галим (1910-1942), аның кызы – Мәдинә; өченчесе – Маһирә (1914-1977), аның балалары – Наил, Мәшүдә, Рафаил, Хаҗинур; дүртенчесе – Мөбәрәкҗан (1921-1965), аның балалары – Миңнислам, Дания, Илдус, Сания, Сәрия, Зәмфәрия; бишенчесе – Галимҗан (1924-1944); алтынчысы – Нәкыйпҗан (1928-1989), балалары – кызы Резеда.

Кадыйрның үги малае – Вилданнан туган Төхбәтулла да үсеп җитә. Бергәләп эшләгәч, аларның эшләре тагын да алга китә. Умарта асрауны тагын да арттыралар. Хәзерге Йосыф-Алан урманында Кадыйрның умарта чүнниге була. Хәзерге көндә дә Йосыф-Аланның өлкән буын кешеләре бу урынны “Кадыйр чүнниге” дип йөртәләр.

1930 елларда кулакларны, тазарак хәлле крестьян хуҗалыкларын Себергә сөрү башлангач, Кадыйрның да бар мөлкәтен тартып алалар, үзен сөргенгә сөрәләр. Кайда, ничә елга сөрелгәнлеге хәзер мәгълүм түгел. Аны белгән өлкәннәр бу дөньядан китеп барды, язып калдыручы да юк, чөнки алар нәселе куркытылып, тузгытылып бетерелә.

Кадыйрның энесе, күршедә яшәгән Биктаһир бабайны да раскулачивать итеп, алты баласы белән аскы урамдагы Салихның ташландык, иске өенә куып чыгаралар. Ләкин ул, нинди юл беләндер, аклана, 3 айдан үз хуҗалыгына кайту-

га ирешә. Аның йорт-җире кара-каршы, уртада өйалды калдырып эшләнгән, 5 кә 5 метрлы ике өй, абзар, баз, мунчадан гыйбарәт иде. Әле ул өйнең урам ягындагысы үз урынында хәзер дә исән. Аны 1954 елда Мөбәрәкҗан абый сүтеп яңадан эшләде, материаллары элеккечә. Ул хәзер авылда борынгыдан калган бердәнбер йорт (Хәлилова Зәмфәрия Мөбәрәкҗан кызының туган йорты).

Кадыйрны сөргенгә сөргәч, барлык йорт-җирен тартып алалар, семьясына ат сарае калдыралар. Шул сарайны өй итеп, мич чыгарып, хатыны Газәнбану, үги улы Төхбәтулла, аның хатыны Шәмсенаһар шунда яшиләр. Төхбәтулланың Оркыя исемле кызы да була, үскәч, Арташ авылына кияүгә чыгып, шунда гомер итә.

Кадыйрның хуҗалыгын талагач, 1933-1934 еллар тирәсендә аның өен башлангыч мәктәп итеп эшлиләр. Ул өйне мәктәп итеп күчереп салуда Төхбәтулла абый үзе дә катнаша. Ул оста балта остасы була. Ул ясап калдырган өстәл, терәкле урындык, агач диван, этажерка авыл Советы конторасында төп эш инвентаре булып 1960 елларга кадәр хезмәт итте. Кара буяуга буялган ул мебельләрне өлкән буын кешеләре әле дә яхшы хәтерли.

Төхбәтулла колхозда эшли. Алар 1936-1937 елларда атларга конюшня салалар. Бу төзелеш бригадасында Дәүләтша исемле кеше дә була. 1937 елның 7 ноябрендә (бәйрәм көнне!) Төхбәтулла белән Дәүләтшаны кулга алалар. Сәбәбе, янәсе, конюшняга ярыклар калдырып төзеп, корткычлык эшләгәннәр. Шул китүдән алар суга төшкән кебек юкка чыгалар.

Дәүләтша турында кыскача мәгълүмат. Ул кибет тотып сәүдә белән шөгыльләнгән, авыл халкына кирәкле товар саткан. (Нигезе хәзерге Сайфуллин Әсгать хуҗалыгы урынында.) Дәүләтшаның хуҗалыгын да тартып алалар. Өен колхоз ашханәсе итеп үзгәртәләр. Ләкин ул озак тормый, ут чыгып, янып күмергә әйләнә. Аның ике малае, үсмер егет булгач, читкә китәләр, соңыннан Казанда төпләнәләр. Хатыны Миңлебикә әби ат сараеннан үзгәртелгән өйдә ялгыз яшәп, 1958 еллар тирәсендә вафат булды. Шуннан ул нигезгә Сәйфуллин Мөхәммәт хуҗалык корды. 1985 елда, илдә үзгәртеп кору җилләре исә башлагач, Дәүләтша абзыйның Казанда яшәүче улы Хәниф КГБ архивларыннан әтисенең "Дело"сын эзләтә һәм нахакка гаепләнеп кулга алынуы, гаебе булмау сәбәпле аклануы турында прокуратурадан документ ала. Хәниф әтисенең аклануы турында карарны авылга алып кайтып безгә дә күрсәтте. Ул карарда мондый юллар бар иде: "Дәүлатша 1937 елның 7 ноябрендә кулга алына. Советка каршы контрреволюцион эшчәнлеге өчен (статья 58-2-6) 10 елга сөргенгә сөрелә. 1942 елның апрель аенда Коми АССРда Вольма шәһәрендә үлә".

Төхбәтулланың кайда, нинди шартларда вафат булуы турында бернинди хәбәр юк. Төхбәтулланы төрмәгә алып киткәннән соң, кызы үсеп кияүгә киткәч, шул ат сараенда гомер иткән Шәмсенаһар әби 1955-1956 нчы еллар тирәсендә вафат булды. Шуннан соң ул урынга Гайфуллин Билал абый хуҗалык корып яши башлады.

1941 елда, сугыш башлангач, нинди юллар беләндер, үлем чигенә җиткән Кадыйр тоткынлыктан кайтып төшә. Кайткач, килене Шәмсенаһар аны өенә кертми. Бу вакытта энесе Биктаһир бабай да вафат булган була инде, аның ба-

лалары гаиләсенә дә сыймый. Халык дошманын сыендырган өчен баштан сыйпамаганнар, төрмә срогы янаган. Хатыны – иреннән, малай-кызы “дошман” атасыннан ваз кичкән чорда аларны да аңларга була. Кадыйрның соңгы сыену урыны конюшняның каравыл өе була. Кеше күрмәгәндә, Бибиҗамал әбиең Кадыйр абзыйга ашарга мичкә тәгәрәткән бәрәңге илтә иде, дип сөйли иде әни. Ул атларга пешергән өшегән бәрәңге ашап (әле ул эләксә) җан асрый һәм шунда вафат була. Аны кәфенлек урынына чыптага төреп күмәләр. Шулай итеп, гаепсезгә юк ителгән миллионлаган корбаннарның ачы язмышын уртаклашып, бер йорттан ике җан (Кадыйр, аның үги малае Төхбәтулла) шулай юкка чыга.

Алда дөньялар имин булсын. Хакимияткә Сталин кебек вәхши, золым идарәчеләр килүдән Алла сакласын. Андый золымнар килсә, алар кубызына биеп, халыкны канга батыручылар табылмас дип кем гарантия бирә ала. Хәзерге буынга, безгә, үткәннәрдән сабак алып, гаепсез һәлак ителгәннәр рухына дога кылып, искә алырга гына кала.

Бу хәтер-хатирәләрне әни мәрхүмә сөйләгәннәрдән, бүгенге көндә мәрхүм булган өлкәннәрдән ишеткәннәрдән хәтерләп һәм фактик материалларга нигезләп бәян итүче Биктаһир бабайның оныгы Наил Тимергали улы Галиев, 2007 ел.

**Бер матур күлмәк белән туфлилек акча эшлим дә...**

...авылга кайтам. Шулай дип чыгып китә авылдан Мәгефүрә. Аның үзенең башкалардан ким-хур булмавын исбатлыйсы, башкалар кебек башын горур тотып йөрисе килә. Балачактан әтисез, әнисез үскән кыз өчен бу бик мөһим була.

Әнисез үсүнең сәбәбе болайрак. 1948 ел. Әтисе сугыштан кайтмаган, әнисе кырда эштә. 10 яшьлек кыз, әнисе Мәсрүрә кушып калдырган эшләрне караганнан соң, өйдә ялгызы торасы килмичә, әнисе янына кырга китә. Кайтыр вакыт җиткәч, әнисе кызының күлмәк итәгенә борчак уып сала. Юлга кузгалгач, кызчык, хатын-кызлардан алданрак йөгергәләп, кире чабып килеп, уйнап кайта. Алга йөгереп киткән мәлендә каршыга килүче авыл җитәкчеләренең берсе аны туктата. Шулчак Мәсрүрә апа, кызымны куркытырлар, чирләп калыр, дип, йөгереп килеп, бала итәгендәге борчакны җиргә чәчә. Җитәкче кызны кайтарып җибәрә, ә әнисе өчен кимсетүле юл башлана. Сорау алулар, суд, хөкем карары. Судта аңа мондый сорау бирәләр: “Сыер асрыйсың, сөтең бар, нигә урлашасың?!” Җавап кыска була: “Мин сөтемне



Мәгефүрә Вәлиулла кызы (уңда)

илтәм дә түгәм хөкүмәткә”. Кыска җавап үз эшен башкара. Аны 10 елга хөкем итәләр. Бергә эшләп, азмы-күпме бөртек алып кайткан 7 хатын-кызның икесе генә төрмәгә озатыла. Өйдә авыру каенана, 15 һәм 10 яшьлек ике бала кала. Ул балаларга авыл халкы (күбрәк җитәкче хатыннары) тарафыннан күрсәтелгән кимсетүле караш кала. Өйдә карарга сыер, сарыклар кала. “Ятим булсак та, бер тапкыр да хәер сорашмадык, – дип горурланып сөйли ул елларны Мәгефүрә апа. – Кечкенәдән эшләдек, Якуп бабай белән печән әзерләдек, сыер-сарыкларны бетермәдек”.

1951 елда, абыйсы Миңлебайның солдат хезмәтенә китәр вакыты җиткәч, бар хуҗалык 14 яшьлек Мәгефүрә җилкәсенә кала. Бу вакытка әбиләре Сәрби инде үлгән була. Абыйсы киткәч, кыз әбисенең энесе гаиләсенә – күршедә генә яшәүче Якуп бабайларга күченә, мал-туарны кереп карап йөри.

Әниләре төрмәдән 5 елдан соң, 1953 елда, Сталин үлгәч кайта. Шулай да кечкенәдән колакка кереп калган кимсетү сүзләре һич тынгы бирми. Чая, чибәр кыз булып җиткән Мәгефүрәгә сүз катарга теләүче егетләр дә күп була, ләкин яралы күңел инде кешеләргә ышана алмый. Үзенең күңел сафлыгын матур кием белән бизисе килә аның. Шундый уйлар белән Әлмәт шәһәрендә яшәүче абыйсы Миңлебай янына китеп, баракта яши башлый. Ләкин паспорты булмау эшкә урнашуны тоткарлый. Яхшы кешеләр ярдәмендә паспорт алуга ирешә, эшкә урнаша. Барактагы туганнары янына килгән мәһабәт гәүдәле, уңган, булган егет Мәхмүт белән таныша. Бераз вакыт дуслашып йөргәч, Балык Бистәсе районы Таулар авылы егетенә кияүгә чыгып тормыш итә башлый. Җитеш тормышта яши кечкенәдән эшләп үскән Мәгефүрә. Колхоз эшеннән кайткач шәлен бәйли, ике ул, бер кыз тәрбияләп үстерә, олыгайган каената, каенанасын карап соңгы юлга озата. Үз әнисенә кадер-хөрмәт күрсәтергә дә мөмкинлек таба ул. Олыгай-



Мәгефүрә апаның туган нигезендәге бердәнбер истәлек – пар юкә

ган көнендә әнисе, ике баласының хөрмәтен тоеп, улы Миңлебай гаиләсендә Әлмәт шәһәрендә яши, шунда вафат була.

Янәшәсендә ныклы терәге – Мәхмүте булу көч бирә аңа. Бик уңган кеше булып чыга Мәхмүт абый. Колхозда шофер булып эшли, йортта ныклы каралты торгыза, умарта тота, мал-туарга азыкны мулдан әзерли. Олыгайган көндә мохтаҗлык күрмичә яшәрлек таза тормыш коралар Мәхмүт белән Мәгефүрә.

Шулай да Юлбат урамын матур күлмәк белән туфли киеп, башын горур тотып бер әйләнәсе килә аның. Юк, карак түгел аның әнисе! Көне буе бушка эшләп, ач балаларга ашату өчен берничә уч борчакны бала итәгенә салу караклык буламыни!

Һәр җәй саен, юкә чәчәк атканда, күңел яралары кабат кузгала Мәгефүрә апаның. 1963 елда РАЙПО кибете төзү өчен аларның йортларын саттыралар. Кибет янәшәсендә, бу җирдә кайчандыр хуҗалык булганын искәртеп, пар юкә үсеп утыра. Бу юкәләр бер-берсенә сыенып, көчле җилләрдән бер-берсен сакларга теләгәндәй, ботаклары белән үзара тотынышып, авылның үзәгендә ялгыз гына утыра бирәләр. Әйтерсең, алар – сугыштан соңгы авыр елларында әти-әнисез калган ике бала – ачлыкка, ялангачлыкка, авыр сүзләргә, әнине өзелеп сагынуга бирешмичә кочаклашканнар да яшәүгә хаклары барлыгын исбатлыйлар.

Һәр җәй саен юкәләр чәчәк ата...

## *Хәрбиләр*

### Хаҗиев Баймөхәммәт Хаҗиәхмәт улы (1901-1975)



Хаҗиев Баймөхәммәт
Хаҗиәхмәт улы

1901 елның декабрь аенда Юлбат авылында крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Баймөхәммәт беренче белемне авыл мәдрәсәсендә ала. 7 яшендә аны әтисе үзе белән өязгә көмеш эшен өйрәтү өчен алып китә. Алар эшләгән авылда рус мәктәбе дә була. Ике ел шул мәктәптә русча укый. 1910-1912 елларда Завод-Нырты авылында Русско-Церьков, приход мәктәбендә укый.

1917 елга кадәр һөнәрчелек белән шөгыльләнә. 1918 елның октябрь аенда Иске Җөри авылында китапханә ачу өчен җибәрелә һәм шунда эшләп кала. 1920 елда Кызыл Армиягә язылып китә. Аны Казанда татар бригадасына командирлар хәзерләү өчен тизләтелгән хәрби курста укырга калдыралар. 6 ай укыганнан соң, хәрби чин биреп, шунда взвод белән җитәкчелек итү өчен билгелиләр.

Белемен күтәрү өчен 1925-1928 елларда Саратов шәһәренә хәрби училищега укырга җибәрелә. Аны капитан чинында тәмамлый һәм шунда хезмәткә калдырыла. Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә үк фронтка китә, ә Җиңү таңын Чехословакиядә каршылый.

Сугыштан 1946 елда Казанга гарнизонга кайта, шунда штабта эшли. 1955 елда подполковник дәрәҗәсендә отставкага китә.

1975 елның 24 маенда вафат була. Юлбат авылы зиратына алып кайтып җирләнә.

**Абдуллин Тәлгать Гыйният улы**


Абдуллин Тәлгать Гыйният улы

1948 елның 1 маенда Гыйният абый һәм Шәмсия апалар гаиләсендә беренче бала булып дөньяга килә. Юлбат башлангыч мәктәбендә Сәлимә апа классында башлангыч белем ала. 1963 елда Сатыш сигезьеллык мәктәбен тәмамлагач, Саба урта мәктәбендә урта белем ала.

Урта мәктәпне тәмамлагач, документларын Саратов хәрби химия училищесына тапшыра. 1966-1969 елларда бу уку йортында белем ала. Лейтенант званиесе бирелеп, ике елга Монголиягә хезмәт итәргә җибәрелә.

1971-1975 елларда Мәскәүдә хәрби академиядә укый. Академияне тәмамлагач, Свердловск шәһәрендә Оборона министрлыгына караган фәнни-тикшеренү институтында эшли.

1985 елда Йошкар-Ола шәһәренә кайтып, хәрби заводта хәрби представитель булып хезмәт итә. 1993 елга кадәр шунда хезмәт итеп, подполковник дәрәҗәсендә отставкага китә.

Нурсанә ханым белән ике ул, бер кыз тәрбияләп үстерәләр. Хәзерге көндә Йошкар-Ола шәһәрендә яши.

**Низамиев Равил Газиз улы**


Низамиев Равил Газиз улы

1952 елның 2 гыйнварында Газиз абый һәм Ракыя апа гаиләсендә икенче бала булып Юлбат авылында дөньяга килә. Башлангыч белемне Шекше мәктәбендә ала. 1966 елда аларның семьясы Юлбатка кайта һәм ул Сатыш сигезьеллык мәктәбен, 1969 елда Саба урта мәктәбен тәмамлый.

Казан химия-технология институтына (КХТИ) укырга керә. Беренче курсны уңышлы тәмамлый һәм, үзен башка өлкәдә сынап карыйсы килеп, документларын Саратов югары хәрби химик командирлар әзерләүче уку йортына тапшыра. 1971-1975 елларда шунда укый. Уку йортын лейтенант званиесе алып тәмамлый. 1975-1980 елларда Чехословакиядә хезмәт итә. 1980-1985 елларда Ерак Көнчыгышта


Хабаровск шәһәрендә хәрби бурычын үти. 1985-1987 елларда Мәскәү шәһәрендә хәрби академиядә (военная академия им.Тимошенко) белем ала. Академияне тәмамлагач, 1987 елның апрель аенда Чернобыль атом станциясендә булган афәтне бетерүдә катнаша. Шул ук елны Кабардино-Балкариягә Гадәттән тыш хәлләр министрлыгына радиационно-химическо – биологическая защита (РХБЗ) бүлегенә начальник итеп билгеләнә. 1998 елга кадәр шул вазифаны башкара.

1998 елга Казан шәһәренә кайта һәм Гадәттән тыш хәлләр министрлыгында (МЧС) 2003 елга кадәр хезмәт итеп, 51 яшьтә полковник званиесендә отставкага китә.

Тормыш иптәше Рәхилә ханым белән өч ул тәрбияләп үстерәләр. Бүгенге көндә туган авылы Юлбатта йорт җиткереп, шунда гомер кичерә.

## *Туган ягым, хезмәтемне сиңа багышладым!*

### Шаһиәхмәтов Мифтәхетдин Фәхретдин улы (1882-1953)



Шаһиәхмәтов Мифтахетдин Фәхретдин улы

Шаһиәхмәтов Мифтахетдин Фәхретдин улы 1882 елда Юлбат авылында Урта Саба кызы Мәхмүзә һәм Искәндәр улы Фәхретдин никахында дөньяга килә.

Балачактан ук ул авыр хезмәт күреп, сука сукалап, иген игеп үсә. Аларның иң борынгы бабалары Морадым чирмеш булган. Хәзерге Вазыйх абыйлар янындагы җирне "чирмеш чокыры" дип атаганнар, чөнки анда беренче булып чирмеш нәселеннән булган кешеләр килеп урнашкан. Морадым бабайның да беренче нигезе чишмә янында булган. Хәзерге нигезгә Мифтахетдиннең улы Садретдин 1962 елда күченә.

Морадым бабай яргыч белән ярма яру эше белән шөгыльләнә, тула баса. Зур бакыр казан белән эшли торган була. Шул казан безнең чишмә буендагы бакчада булырга тиеш, дигән сүз йөри. Аны казып карыйлар, ләкин таба алмыйлар.

Ә Мифтахетдин бабай авылның иң укымышлы кешеләреннән санала. 12 ел солдат хезмәтендә була. Яхшы итеп русча сөйләшергә, язарга өйрәнеп кайта. Солдаттан кайткач, Зәйнулла кызы Сәгъдәт белән тормыш корып җибәрә. 1915 елда уллары Садретдин, 1918 елда кызлары Мәйсәрә дөньяга килә.

Мифтахетдин бабай абыйсы Мотыйгулла белән тегүгә чыгып йөргән. Күбесенчә Башкортка барганнар. Авыл тарихын язу белән шөгыльләнеп киткән. Чәй карасы белән язып барган китабы булган, дип сөйлиләр, ләкин хәзерге вакытта ул югалган дип исәпләнелә.

Мифтахетдин бабай 1952 елда Шәһри Болгарны зиярәт кылган. Шушы баруы турында аның язып калдырган кулъязмасы хәзер дә саклана.

“1952 елда җәй көне Шәһри Болгарга зиярәт иттем. Манарага менеп азан әйттем, җомга намазы укыдык. Бер таш хаҗәрәнең эчендә адәм сөякләре куелган, өстенә ябылган. Мәчет бик зур, таш булган. Мәчет алдында зур гына чиркәү төзелгән, чиркәүнең нигезенә гарәп хәрефләре белән язылган кабер ташлары салынган. Чиркәү ишек төбендә артып калган унлап таш ята, алар да язулы. Мәчет манарасы мәчеттән 100 м чамасы ераклыкта”.

Мифтахетдин бабай Шәһри Болгарга тагын барырга җыена, ләкин 1953 елда дөнья куя. Аның хәләл җефете Сәгъдәт 1947 елның 16 февралендә дөньядан китә.

Мин бу язмамны әбием, ягъни Мифтахетдин бабайның килене Гыйлемсара ярдәмендә язып алдым. Хәзерге көндә ул да якты дөньяда юк. Мифтахетдин бабайның икенче тапкыр Болгарга бару турында үтәлмәгән хыялын мин тормышка ашырдым. Без, тарих түгәрәге әгъзалары, 1994 елның җәендә Шәһри Болгарга сәяхәт кылдык. Моның өчен без укытучыбыз Илдар абый Фатхулловичка зур рәхмәтле.

*Бу язманы Мифтахова (Рәхимуллина) Рәмзия Хәнәфия кызы әзерләде.*
*1995 ел, 19 апрель, 11 сыйныф.*

Мифтахетдин бабай алдынгы карашлы, үз заманы өчен белемле кеше була. Татар халкының үткәнен ул “тоталитаризм” ярлыгы тагылган чорда ук өйрәнергә тырышкан. Шәһри Болгар турында үз фикерләрен язып калдырган. Ә без, хәзерге буын кешеләре, үткәнебез белән элемтәләр өзелүдә режимны гаеплибез, вакыт юклыкны, мөмкинлекләр чикләнгән булуны сәбәп итәбез...Киләчәк буыннарның авыл тарихы белән кызыксыначагын да ул ничә дистә еллар алдан күргән: авыл тарихын күп еллар буе язып барып, калын дәфтәр туплаган. Үзеннән соң килгән авылдашларының шундый олы хезмәтне югалтуын белсә, ни әйтер иде икән бу әүлиягә тиң кеше? Битарафлыкмы, хөсетлекме, нәрсә бу? Бәлки, кемнәргәдер авылның үткәненнән сәхифәләрне югалтырга кирәк булгандыр? Хәзер инде, авылның үткәненнән күп нәрсәләрне белә алмый калган кебек, бу сорауга да җавап таба алмабыз. Бары тик сакланган хатирәләрне туплау, саклау гына безнең кулдан килер. Ә Мифтахетдин абзый турындагы истәлекләр мәңге сакланырга лаеклы. (*С.И.*)

Аның турында район газетасында укытучы Саҗидә апа Ракова түбәндәге юлларны язган: “Хат яздыру өчен Маһинур Ханнановага ялына идек, – ди Габделхәй абый Гыйлаҗиев. – Адрес яза алучы Мифтахетдин иң белемле кешегә саналды”. Мифтахетдин исә бала чактан бик зиһенле була. Башына кияргә бүреге булмагач, ашъяулык урап, абыстайга сабакка йөри. Үзлегеннән укып белем ала. Солдаттан кайткач, үзе дә белемгә сусаган балаларны укыткан.

*Саҗидә Ракова, “Җиңү байрагы”, 23 январь, 1968 ел.*

## Ногмановлар гаиләсе



Нурислам Ногман улы Ногманов

Нурислам Ногман улы Ногманов Саба районы Тенеки авылында дөньяга килгән. Ул утызынчы еллар башында ук тракторчылар курсында укып, 1936-1938 елларда Чиләбе шәһәрендә механиклар мәктәбен тәмамлый һәм 1941 елдан, ягъни егерме ике ел буе МТС, РТС директорлары, “Сельхозтехника” район берләшмәсе управляющие вазифаларын алып бара. Аңа 1962 елда “Татарстанның атказанган механизаторы” дигән мактаулы исем бирелеп, республикада беренче номерлы таныклык тапшырылган. РСФСР күләмендәге персональ пенсионер.

Аның әтисе Ногман Шәрәфиев Тенеки авылында гомер итеп, тимерчелек эше белән шөгыльләнгән. Аның тимерче алачыгында күмер уты ел тәүлеге сүнеп тормаган. Урып-җыю эшләре башланыр алдыннан кул уракларын тешәтергә (сүз кул уракларын үткенләү, тешле итү турында бара) күрше-тирә авыллардан да киләләр. Уллары Нурислам, Хәмит, Әхмәт, Хәләф ярдәме белән меңләгән урак тешәгән еллары да була.



Ногман Шәрәфиев хатыны белән

Тимердән чәчәк коя торган ир-ат җәмәгать эшләрендә дә катнаша. Мәсәлән, 1939 елда хезмәт ияләре депутатларының беренче чакырылыш район Советы депутаты итеп сайлана. Аларның гаилә архивында саклангандан бер рәсми кәгазь кызыклы гына өстәмә мәгълүмат бирә: “Бу белешмә Саба районы Юлбат авылы Ворошилов исемендәге колхоз идарәсеннән шул ук районның “Яңа юл” колхозы (Тенеки авылы) әгъзасы һәм район Советы депутаты Ногман Шәрәфиевка бирелә. Дөрестән дә, иптәш Шәрәфиев, Ворошилов исемендәге колхозга (Юлбат авылы) килеп, 1940 елның язгы чәчүенә әзерлекнең торышын карады. Тикшерү вакытында табылган кимчелекләрне бетерергә күрсәтмәләр бирде. Югарыда язылганнарны раслап: колхоз председателе Гайнетдинов, секретарь Галимуллин”.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Ногмановлар гаиләсеннән иң беренче Хәмит сугышка китә. Ул яшьтән үк киң эрудицияле булып үсә, русчага өйрәнә, бик яхшы рәсем ясый, гармунда уйный. 1935 елда ук Ключище авыл хуҗалыгы

техникумын тәмамлап, башта Татарстан җир эшләре комиссариатына караган умартачылык конторасында бүлек начальнигы булып эшли, ә инде 1939 елда бөтен Россиядә бармак белән генә санарлык дәрәҗәдә аз булган совхозларның берсенә – үзебезнең район җирлегендәге “Нариман” тәҗрибә-житештерү хуҗалыгына җибәрелә һәм шуннан Совет Армиясенә алына. Красноярск краендагы Ачинск полк мәктәбен тәмамлагач, Ленинград өлкәсенә озатыла һәм сугыш вакытында Ленинград камалышына эләгә. 1943 елның гыйнварында блоканы өзү өчен барган сугышларда штурмгруппаның командиры Хәмит немец автоматыннан һәлак була.



Әхмәт Ногманов

Ногмановлар гаиләсендә үскән Әхмәт тә сугыш вакытында камалыштагы Тула шәһәрендә була. Районыбызның Алан-Елга, Йосыф-Алан мәктәпләрендә мөгаллимлек иткән, Арча педагогия училищесында төпле белем алган егет Мәскәү астындагы Завидово шәһәрендә полк мәктәбен тәмамлый. СССР башкаласын саклауда катнаша. Шунда беренче тапкыр “катюша”лар залпын күрә.

Тула шәһәре камалышыннан да исән калып, туган ягына кайта Әхмәт ага. Фронтта батальонның комсомол оешмасын җитәкләгән Ә.Ногмановны ВЛКСМның Саба район комитетының беренче секретаре итеп сайлыйлар.

1958 елда Ә.Ногмановны – инде Чистай техникумында көндез укып “кызыл диплом”га тәмамлаган механикны – укытучы белеменә дә ия икәнен белеп, район мәгариф бүлеге мөдире Гасыйм Йосыпов үзенә чакырып ала һәм Саба урта мәктәбендә укучыларны производство нигезләрен өйрәтү эшенә алынырга тәкъдим итә. Шушы уңайдан район партия комитетында да җитди сөйләшү була. Һәм Әхмәт абый, ризалыгын биреп, җаваплы эшкә күчә. Мәктәптә производство нигезләрен өйрәтү буенча үрнәк кабинет җиһазлый, укучыларны хезмәткә әзерләү буенча зур эш башкара. Ә.Ногманов яшь буынны производствога өйрәтүгә ун ел гомерен багышлый.

1971 елда аны кабат район җитәкчеләре чакырып алалар һәм, “Сельхозтехника” район берләшмәсендә терлекчелек фермаларын механикалаштыру цехы оештырылу сәбәпле, Әхмәт Ногман улына управляющий урынбасары вазифасын йөклиләр.


Моннан тыш Әхмәт Ногман улына районда шофер һөнәрен үзләштергән бик күп ир-атлар да бурычлы әле. Бу эшне аңа ДОСААФ линиясе буенча тәкъдим итәләр. Авылларда, балачагы сугыш елларына туры килеп, бернинди һөнәр алмаган ир-егетләр байтак була. Аларны һөнәрле итү кебек изге эшне башкара. Укытулар мәктәптә, “Сельхозтехника” район берләшмәсендә кичләрен оештырыла. Түләүле курслар була ул. Ел саен утыз кешегә транспорт йөртү таныклыгы бирелә.

Ул пенсиягә чыккач та 104 нче һөнәр училищесында укучыларны юл йөрү кагыйдәләренә өйрәтү дәресләрен алып бара әле. Гомуми хезмәт стажы, сугыш вакытында армиядә хезмәт итүне, район партия һәм комсомол комитетларында эшләүләрне кертеп, кырык сигез елга тула.

Ногмановлар гаиләсендә дүртенче малай – Хәләф – яшьтән очучы булырга хыяллана, әмма хезмәт юлын барыбер, абыйлары кебек, плугарьдан, тракторчыдан башлый. Унҗиде яше тулгач, 1944 елда армиягә алына һәм Чиләбе өлкәсенең Троицк шәһәренең авиация училищесында укый. Япон сугышында очучы-укчы, соңыннан Байконур төзелеше елларында хәрби төзүчеләр рәтендә булып, бөтен гомерен данлы Кораллы Көчләргә багышлый. Башта экстерн тәртиптә училище, аннары Алма-Атадагы Хәрби академияне тәмамлый. Соңгы елларда Хмельницк шәһәрендә хезмәт итә һәм фәнни эш белән шөгыльләнә.

Әхмәт ага тормыш иптәше Саба кызы Гөлбикә апа белән ике ул һәм ике кыз үстерә. Уллары бабалары юлыннан китә. Миннислам, хезмәт юлын тракторчыдан башлап, партия-комсомол органнарында эшли, әтисе кебек, ВЛКСМның беренче секретаре итеп сайлана, озак еллар Саба автотранспорт предприятиесен җитәкли, КПСС райкомының авыл хуҗалыгы мәсьәләләре буенча секретаре була. Икенче улы Лирик та инженер һөнәрен сайлый. Кызлары Зилә белән Фәридә үзләрен медицинага – халык сәламәтлеген саклауга багышладылар.

**Җирдә икмәк булсын дип**



Нургалиев Һашим
Нургали улы

Нургалиев Һашим Нургалиевич 1928 елда Саба районы Юлбат авылында туа.

1954 елда – Татарстан авыл хуҗалыгы мәктәбен, 1970 елда Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлый.

Хезмәт юлын Бөек Ватан сугышы башлангач 13 яшьтә Папанин исемендәге (Калатау авылы) колхозда башлый. Колхозчы, бригадир була, 1948-1953 елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. 1955 елда – “Авангард” колхозында агроном, председатель, 1956-1971 елларда –“Искра” колхозында агроном. Ул эшләгән чорда “Искра” колхозы игенчелектә артта калган колхоздан иң алдынгылар рәтенә күтәрелә. 1971 елда КПСС өлкә комитеты бюросы, ТАССР Министрлар Советы карары белән “Игенчелектә югары культуралы хуҗалык” исеме бирелә һәм Диплом белән бүләкләнә. Түбән уңдырышлы көлсу туфракта мондый уңышка агрономның эшне фәнни нигездә оештыруы, озак еллар тынгысыз хезмәте, принципиальлеге, эшне тиешенчә оештыруы, колхозчыларны үз көченә ышандыра алуы, алар белән уртак тел табып эшләве нәтиҗәсендә генә ирешеп була. Фидакарь игенченең хезмәте турында саннар тагын да ачыграк сөйли. Мәсәлән, ул эшли

башлаган 1956 елда бөртеклеләрнең һәр гектарыннан 5,8 центнер уңыш алынса, 1971 елда ул 16,7 центнер, 1974 елда 20,8 центнер тәшкил итә. Шулай итеп, Һ.Н. Нургалиевның максатчан хезмәте озак еллар үзенең уңай нәтиҗәләрен бирде. Хуҗалык 1972, 1973, 1974 елларда "Игенчелектә югары культура өчен" дигән конкурста призлы урыннар яулады, ә 1976 елда бәрәңгедән югары уңыш алган өчен Татарстан АССР Халык казанышлары күргәзмәсенең дипломы белән бүләкләнде.

1972 елда Һашим Нургалиевичны район авыл хуҗалыгы идарәсенә эшкә алалар. 1976 елда тагын "авыр" участокка – "Икшермә" совхозына баш агроном итеп күчерелә. 1979 елда кабат район авыл хуҗалыгы идарәсенә кайта һәм персональ пенсионер дәрәҗәсендә лаеклы ялга киткәнче районда игенчелек буенча җаваплы эшләрдә эшли.

Аның хезмәте хөкүмәтебез тарафыннан югары бәяләнә. 1971 елда "Хезмәт Кызыл Байрагы ордены", күп санда медальләр, Мактау грамоталары белән бүләкләнә. Ләкин шушы бүләкләр арасында иң олысы, мөгаен, халык ихтирамы булгандыр. "Искра" колхозы хезмәтчәннәре Һашим Нургалиевичның хезмәтен бәяләп, ул колхоздан киткәч тә аңа карата ихтирам хисләре саклап яшәделәр һәм ул өйрәткәнчә эшләргә тырыштылар. Әлеге җирлектә хәзер дә (2012 елда) югары уңыш алына, димәк, аның хезмәтен үзеннән соң килгән буыннар дәвам итә. Башта "Искра" колхозын икмәкле, терлек азыклы иткән, соңрак искралыларның эш тәҗрибәсен бөтен район күләмендә куллануга ирешкән Нургалиев Һашим Нургалиевичның якты истәлеге Юлбат, Тенеки, Йосыф-Алан, Калатау халкы күңелендә бүген дә яши.

**Сафин Тимерҗан Галәветдин улы**


Сафин Тимерҗан Галәветдин улы

Сафин Тимерҗан Галәветдин улы 1928 елның 22 мартында Йосыф-Алан авылында туа, матур урман буендагы авылда уйнап үсә. Беренче һәм икенче классларда үз авылларында укып белем ала, авылда өченче классны укыту булмаганлыктан, Тенеки авылына йөреп өченчене, Юлбат башлангыч мәктәбендә дүртенче классны укый. Юлбатта Шәмсия, Газизә, Вәрихан апалар белем бирә. 5-7 классларны Сатышка сигез километр араны көн саен йөреп укырга туры килә. Кыш көннәрендә мәктәпнең тулай торагында яшәп, ял көннәрендә генә авылга кайтып йөри.

1941 елда сугыш башлангач, укырга йөрү авырая, күп иптәшләре укуны ташларга мәҗбүр була.

Тимерҗан хезмәт юлын 15 яшендә башлый. Трактористлар курсын тәмамлагач, Саба МТСына килә. Юлбат трактор бригадасына билгеләнеп, Юлбат егете Кәбиров Кашаф белән эшли. Трактор бригадасы бригадиры шулай ук Юлбаттан Якупов Фәйзрахман була, 1942 елда ул сугышка алын-

гач, Тенеки авылыннан сугышта бер аягын югалтып кайткан Сабирҗанов Әһли бригадир итеп билгеләнә. Ул вакытта ХТЗ тракторларының кабиналары булмый, ачык тимер утыргычка утырып, көннәр буе басуда йөрергә туры килә.

Тимерҗан абый икенче елны Икшермә бригадасына билгеләнеп, шунда китә. Бригадада, Икшермә егете Хатиптан башка, тракторчылар гел хатын-кызлар була. Тракторист булып 1947 елга кадәр эшләгәннән соң, 1948 елда райвоенкомат аркылы шахта төзелешенә җибәрелә. 1949 елда кайтып, Мамадыш автошколасында шофер һөнәре үзләштерә. 1950 елда Совет Армиясе сафларына чакырылганчы, Шәмәрдәндә шофер булып эшли. Биш елга якын армиядә хезмәт итеп, өлкән сержант дәрәҗәсендә туган якка кайта. Саба МТСында автомеханик, мастерской мөдире, участок механигы, торфотряд җитәкчесе булып эшли, бер үк вакытта партия оешмасы белән җитәкчелек итә. 1966 елдан 67 яшендә лаеклы ялга киткәнче, Саба коммуналь хуҗалыгы белән 26 ел җитәкчелек итә.

Ул эшләгән елларда Саба коммуналь хуҗалыгы республика буенча алдынгылар рәтенә күтәрелә. 1973 елның дүртенче кварталында Министрлар Советының Татоблпрофның Күчмә Кызыл байрагы тапшырыла. 1975 елда төзекләндерү һәм санитария таләпләренең үтәлеше буенча РСФСР һәм ВЦСПСның Күчмә Кызыл байрагына лаек була. Елдан-ел планнарны үтәп, уңышлы эш алып бара.

Тимерҗан Галәветдин улы үзе тугызынчы һәм унынчы бишьеллыклар ударнигы исеменә лаек була, күп кенә медальләр белән бүләкләнә. Аның җитәкчелек сәләтен исәпкә алып, халык депутатларының район Советы Саба җирле үзидарә каршындагы ветераннар советы белән җитәкчелек эшен тәкъдим итә. Эш чорында ветераннарның гозерләрен игътибар белән тыңлап, уңай хәл итәргә тырыша, өйләренә барып хәлләрен белә, соңгы юлга озатуда башлап йөри. Үзе өлкән яшьтә булуга карамастан, тапшырылган эшне җиренә җиткереп башкара. Шушы эшендә 78 яшькә кадәр хезмәт итә.


Яшьлеге авыр сугыш елларына туры килгән Тимерҗан Сафин гомер буе үзенең белемен күтәрү өстендә эшли. Кичке мәктәптә укып урта белем ала, 1961 елда Казан автошколасында укып таныклыкка ия була, 1974 елда читтән торып Чистай авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлап, техник-механик белгечлеге буенча диплом алуга ирешә.

Тормыш иптәше Әминә белән өч бала тәрбияләп үстереп, өчесенә дә югары белем алырга ярдәм итәләр. Кызлары юрист һөнәрен үзләштерә, Яр Чаллы шәһәрендә судья, олы уллары, Казан авиация институтын тәмамлап, “Сабагаз оешмасында цех җитәкчесе булып эшли, кече уллары Казан төзелеш институтын тәмамлый. Әминә үзе сайлаган һөнәр буенча бер урында – Саба ясле-бакчасында 37 ел эшләп, лаеклы ялга чыга.

### Сәйфуллин Сәлим Сәйфулла улы

1927 елның 31 мартында Татарстан Республикасы Саба районы Юлбат авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. 1939 елда, Юлбат башлангыч мәктәбен тәмамлагач, Сәлимне әнисе белән бергә колхоз канцеляриясен җыештырырга эшкә куялар. Әнисенә – 1,25, ә йомышчы малай Сәлимгә (телефоннар булмаган

ул вакытта колхоз идарәсендә даими йомышчылар тота торган булганнар) 0,75 хезмәт көне язып баралар. Менә шулай ул 12 яшьтән даими эшче булып китә. Күп вакытын идарә бинасында уздырганлыктан, хисапчы һәм табельщик тирәсендә чуалып һәм бригадирларга булышып, счет салырга, хисапларга өйрәнә, газеталар укып, аз-маз русча үзләштерә. Аның сәләтен күреп, 1943 елда табельщик итеп куялар. 1944-1945 елларда Ворошилов исемендәге колхозда – хисапчы, 1946-1947 елларда кырчылык бригадасы бригадиры булып эшли.



Сәйфуллин Сәлим
Сәйфулла улы

1947-1949 елларда элеккеге Тәмте (соңрак ул район Кама Тамагы районына кушыла) районында икееллык бакчачылар мәктәбендә укый. Рус телендә белем бирелгән мәктәпне бары тик “4”ле һәм “5”ле билгеләренә генә тәмамлап, 1949 елның көзендә Саба районының авыл хуҗалыгы идарәсенә агроном булып кайта. 1954-1962 елларда – район план комиссиясендә экономист. 1961 елда читтән торып Мәскәү статистика техникумын тәмамлый. 1963 елдан 1993 елга кадәр район авыл хуҗалыгы идарәсендә – экономист, шуның 25 елын – план һәм экономика бүлеге мөдире.

1985 елда “Татарстанның атказанган экономисты” дигән мактаулы исем бирелә, Обком, Совмин, Татарстан Югары Советының Мактау грамоталары белән бүләкләнә.

67 яшендә үзе теләп лаеклы ялга киткәч, бакчачылык белән ныклап шөгыльләнә башлый. Бакчасында 24 төрле алма, груша агачлары, җиләк-җимеш куаклары һәм башка агачлар үсә. Агачларны бер-берсенә ялгап, бер агачта берничә төрле сорт үстерә. Аның кайбер алмагачлары төбендә 4-5 төрле сорт алма үсә. Питомнигында җиләк-җимеш агачлары үсентеләре үстереп, дус-ишләренә, туган-тумачаларына, авылдашларына бүләк итә.

Җәмәгать эшләрендә актив катнаша. 2 ел район инвалидлар оешмасы рәисе, район ветераннар советы рәисе урынбасары, 1999 елдан сәяси репрессия корбаннары иҗтимагый район оешмасы рәисе вазыйфаларын башкара. Район газетасының актив хәбәрчесе буларак, соңгы елларда: “Юлбатның указлы һәм указсыз муллалары”, “58 нче маддә – 58 елдан соң”, “Юлбат мәчете ачылганда туган уйлар” дигән мәкаләләре белән авылдашларын сөендерде ул.

**Низамиев Габделхай Низами улы**

1930 елның 10 маенда Юлбат авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туган.

Аңа унбер яшь тулганда Бөек Ватан сугышы башлана. Ике бертуган абыйсы сугышка китә. Өлкәне – Барый абыйсы – 1942 елда Сталинград сугышында һәлак була. Кечесе – Газиз абыйсы – сугышның башыннан ахырына кадәр көрәшеп, Берлинны алу сугышларында катнашып, күп тапкырлар яраланып (ба-

шына кадәр ярчык кереп) кайта. Әтисе, олы яшьтә булу сәбәпле, сугышка китми кала. Эш яшендәге кешеләр сугышка киткәч, тылдагы хезмәт Низами абзый кебек өлкәннәр һәм яшүсмерләр җилкәсенә төшә. Шунлыктан әтисенә һәр эштә икеләтә норма үтәргә туры килә. Берүзенә 50 баш ат карау кыен булганлыктан, Габделхай аңа булышырга алына. Ат җигеп бочкалы арба белән су, терлек азыгы ташу, ат белән колхоз басуында җир тырмалау кебек эшләрне башкарырга туры килә буыннары да ныгып бетмәгән үсмер малайга.

1947 елда Саба авыл хуҗалыгының берьеллык мәктәбен тәмамлаганнан соң, РайЗО (район җир бүлеге) кушуы буенча, 1948 елда үзенең туган колхозында хисапчы булып эшли башлый. 1951-1955 елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. Ватан алдындагы хәрби бурычын үтәп кайтуга, армиягә кадәр үзен бары тик яхшы яктан гына күрсәткән өметле белгечне Ворошилов исемендәге (соңыннан “Искра”) колхозга баш бухгалтер итеп билгелиләр. Бу эшне 1974 елның август аена кадәр башкара ул. Колхозда эшләү чоры (армия сафларында хезмәт итүне дә кертеп) барлыгы 26 ел тәшкил итә. Төп вазифасы белән беррәттән, күп еллар өстәмә җәмәгать эшләрен, аерым алганда, партия оешмасы секретаре вазифаларын башкара. Эштән аерылмыйча, читтән торып зоотехниклар хәзерли торган Минзәлә техникумында укып белем ала. Ул эшләгән чорда “Искра” колхозы экономик яктан зур уңышларга ирешә. Игенчелектә югары уңыш алу һәм терлекчелек тармагыннан мул продукция җитештерү буенча колхоз район хуҗалыклары арасында гына түгел, республика хуҗалыклары арасында да иң алдынгылар рәтенә чыга. Республика күләмендә зур күрсәткечләргә ирешкән өчен 1972 елда колхозга КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы һәм ВЦСПСның Почет билгесе тапшырыла. Бу зур бүләккә республика буенча бары тик 3 хуҗалык кына лаек булганын да искәртеп китсәк, ул елларда җитәкчелек һәм колхозчыларның тырыш хезмәтен тагын бер кат ассызыклау булыр.



Габделхай абый әтисе Низами, әнисе һәм кыз туганы белән


Габделхай Низамиев дусты Сәлим Сәйфуллин белән

1974 елда республикадагы кайбер җитәкчеләрнең тәкъдиме белән Габделхай Низамиевичка Мәскәү карамагында булган “Ремстройдормаш” заводына Казанга эшкә күчәргә туры килдә. Завод дирекциясе, эшкә чакырганда ышандырганча, бер ел эчендә 3 бүлмәле фатир бирә. Бу заводта башта финанс бүлеге мөдире, аннан заводның баш бухгалтеры булып 1985 елга кадәр 11 ел эшли. Әлеге завод, юл төзү машиналары һәм техникалары эшләп, Промышленность министрлыгы разнарядкасы аша Союз республикаларына тарата.

Шулай уңышлы гына эшләгәндә, хезмәт урынын тагын алыштырырга туры килә аңа. Бу юлы Авыл хуҗалыгы азык-төлек министрлыгы тәкъдиме белән 1986 елның гыйнварыннан министрлыкның әйдәп баручы экономисты вазифасына эшкә күчерәләр. Бу эштә пенсиягә киткәнче – 1990 елның май аена кадәр эшли. Эш дәверендә министр тарафыннан Мактау грамоталары белән бүләкләнә.

Пенсиягә чыккач та 15 ел дәвамында Казанның төрле төзелеш оешмаларында баш бухгалтер булып эшли әле тынгысыз хезмәт ветераны. Аның хезмәт кенәгәсендә, 5 ел Совет Армиясендә хезмәт итүне дә кертеп, 60 ел эш стажы бар. Хезмәт кенәгәсендә бер эштән икенче эшкә күчү үз теләге белән эштән китү сәбәпле түгел, ә эштән эшкә күчерелү сәбәпле генә языла.

Низамиев Габделхай – тыл ветераны, Хезмәт ветераны, Авыл хуҗалыгы министрлыгы аппараты ветераны. Лаеклы ялга киткәч тә, берничә ел Казанның Яңа Савин районында ветераннар советы председателе вазифасын башкара.

Нинди генә югары үрләр яуласа да, Габделхай Низами улы туган җирен, үзен дөньяга таныткан, зур эшләргә фатиха биргән колхозын онытмый, Казанда эшләү дәверендә ничек тә ярдәм итәргә тырыша. Бер генә мисал язып үтәсе килә. “Теneки һәм Йосыф-Алан авылларын газлаштыру чорында колхоз идарәсе председателе булып эшләгән Габдрахманов Наил, безнең оешмага килеп, колхозның акчасы булмаганлыктан, газ плитәләре алу кыенлыклары буенча мөрәҗәгать иткәч, колхозга үзебезнең оешма аша күп кенә санда газ плитәләре җибәрү мөмкинлеген таптык”, – дип искә ала ул.

Габделхай абый көнделендә авылдашлары турында матур хатирәләр саклап яши. Шуларның берничәсен үзе язганча китереп үтәбез: “*Миндә Мөхәммәтшакир мулла турында бик якты истәлекләр саклана. Ул авыл халкына карата бик ярдәмчел һәм ихтирамлы кеше иде. Бөек Ватан сугышы елларында ул без яшәгән өйне ремонтлауда бик зур ярдәм итте.*



Габделхай Низамиев хатыны Әкълимә белән

*1958 елда Әкълимә белән өйләнешкәч, әтиләр-әниләр белән бергәлектә, яшерен рәвештә хәзрәтне чакырып, никах укыткан хәзер дә хәтердә. Ул заманда диннең бик каты тыелган чагы иде.*


*Итне саклау өчен суыткычлар булмаган вакытларда күршем Сәйфуллин Мөхәммәт белән, сарыкларны алмашлап суеп, итләрне уртаклап бүлә идек. Бер айны ул суйса, икенче айны мин суя идем. Мин суйган ай Корбан бәйрәме көннәренә туры килгән. Динне сөймәгән кайбер кешеләр мине, корбан чалды дип, Райкомга хәбәр иткән. Минем "эшне", партия вәкиле буларак, Райкомның пропаганда бүлеге мөдиренә җибәреп, миннән һәм күршем Сәйфуллин Мөхәммәттән аңлатмалар яздырып алдылар".*

**Үзе тыйнак, үзе гади**



Галиев Наил Тимергали улы. Сиксәненче еллар фотосы

Галиев Наил Тимергали улы 1942 елның 15 февралендә, сугышның иң кискен чорында туган. Әтисе бу вакытта фронтта, әнисе атлы эштә эшләгән. "14 февраль көнне басудан ат белән көлтә-салам төяп алып кайтканнар, 15е көнне таң атканда мин дөньяга килгәнмен", – дип искә ала ул. Наил туып 40 көн үткәч, әнисен урман кисәргә җибәргәннәр. Шулай итеп, сугыш вакытының бөтен ачлык, юклыкларын сабый чактан ук татырга туры килгән аңа. Сугыштан соңгы еллар шулай ук бик авыр булды, дип искә ала ул. "Сугыштан исән кайткан әти һәм әни бер көн калмый колхозда эшләсәләр дә, тамак туйдырырлык кына түгел, хәтта ашка умачлык та икмәк бирмиләр иде. Иң үзәккә үткәне – дәүләткә ит, сөт, йон, йомырка, бәрәңге тапшыру, налог һәм заем түләү булды. Сугыштан исән кайткан дип, әтигә заемны, гаилә башлыгы фронтта һәлак булган семьяларга караганда, өчләтә артык яздырталар иде. Бер җирдән керем юк, ә түләргә кирәк. Бер елны әти соңгы сыерны сатып түләде. Өйдә авыру әби, без, дүрт бала, сыерсыз да калдык. Шушы авыр шартларда Юлбат башлангыч мәктәбен, 1956 елда Сатыш җидееллык мәктәбен тәмамладым. Саба урта мәктәбенә барып булмады. Уку түләүле – түләргә акча юк. Әтисе сугышта үлгәннәргә генә уку бушка иде".




Галиев Н.Т.ның Ревизия сказкаларына нигезләнеп төзегән шәҗәрәсе

1957-1961 елларда колхозда атлы эштә, тракторда плугарь (прицепщик) булып эшли, шофер һөнәре ала. 1962-1964 елларда армия сафларында хезмәт итә. Армиядән кайткач, 1965-1967 елларда колхозда шофер булып эшли, бер үк вакытта Сатыш кичке урта мәктәбендә 3 ел укып, урта белем ала. Һәр эштә тырыш, уңган коммунист Юлбатка бригадир итеп билгеләнә. 1969 елда райком күрсәтмәсе буенча Казан авыл хуҗалыгы институтында обкомның кадрлар хәзерләү факультетында 1 ел укып, "Социалистик авыл хуҗалыгы оештыручыҗитәкләүче" дипломы ала.

1970-1972 елларда, Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумында читтән торып укып, агроном белгечлеге ала. Ул комплекслы бригада бригадиры булып эшләгән 1967-1973 елларда колхоз районда гына түгел, Татарстан күләмендә алдынгылар рәтенә чыга. Игенчелек тармагы алга китә, кырларның уңыш бирүчәнлеге үсә. Терлекчелек, аеруча кошчылык тармагы үсеп, колхозга зур файда китерә. Хуҗалыкның рентабельлек дәрәҗәсе 40-46% ка җитә. Ул елларга бәя биргәндә, Наил Тимергалиевич болай дип искә ала: "Председатель Миңлехан Галихановичның һәм агроном Һашим Нургалиевичның килешеп, уртак эш өчен янып-көеп, фәнни яңалыкларны кулланып намус белән эшләве хуҗалыкның үсешенә этәргеч бирде. Шулай ук коллективка, кадрларга таләпчәнлек, җитәкчелектә кешелекле мөгамәлә, коллективны аңлау эшкә омтылыш уятты. Без, яшь кадрлар, шулар үрнәгендә тәрбия алдык". Аны тыңлаганда, ирексездән уйлап куясың: никадәр тыйнаклык, никадәр гадилек! Чынлыкта, комплекслы бригада бригадиры әлеге җитәкчеләр белән бер үк йөкне тарткан бит! Гади колхозчының көндәлек мәшәкатьләрен ул күбрәк күргән, тойган, һәркемнең күңеленә ачкыч табып, эшкә рухландырган. Шулай булмаса, җитәкчелек аның хезмәтен күреп, дәүләт бүләкләренә тәкъдим итәр идемени! Ул 1970 елда – "Хезмәттәге батырлык өчен" медале, 1972 елда "Почет билгесе" ордены белән бүләкләнә.

Колхозларда аерым партия оешмасы секретарьларын сайлау башлангач, 1974 елда аны партбюро секретаре итеп сайлыйлар. Бу вазифаны 17 ел башкара. 1992-1994 елларда терлек азыгы хәзерләү буенча председатель урынбасары, болгавыр 1995-2002 елларда яңадан бригадир булып эшләп лаеклы ялга чыга.



Галиев Н.Т. Карачтауда элекке атлы юл булган урында

Күптән түгел 70 яшен билгеләп үткән Наил Тимергалиевич гомер буе җаваплы тармакларда эшли. Бүген дә авыл халкы, киләчәк буыннар өчен әһәмиятле эш белән шөгыльләнә: авыл тарихы белән кызыксынучыларга беренче ярдәмче ул. Соңгы вакытта репрессияләнгән кешеләр язмышы турында эзләнә, авыл халкының нәсел шәҗәрәләрен барлый.

Авылыбызның киләчәк буыннары аның хезмәтенә үз бәясен бирер әле.

*Сафин Илдарның 2012 елда "Саба таңнары"нда чыккан мәкаләсеннән.*

## Җитмеш төрле һөнәр иясе



Назыйф Галимҗанов техника паркында

Галимҗанов Назыйф Хәниф улы 1956 елда Юлбат авылында туа. Саба урта мәктәбен тәмамлаганнан соң Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. Аннан соң читтән торып Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлый. Колхозда шофер, орлыкчылык буенча агроном, бригадир, комбайнчы. Соңгы 22 елда ремонт мастерское мөдире булып эшли. Һәм ул бу вазыйфага очраклы килгән кеше түгел: эшне нәтиҗәле итеп оештыра, механизаторларның һәркайсы белән уртак тел таба белә. Тимерче, эретеп ябыштыручы, слесарь, наладчик, аккумуляторчы, токарь бүлмәләренең һәркайсына кереп, бу эшләрне үзе генә дә башкарып, техникага ашыгыч ярдәм күрсәтә ала ул. Менә шундый җитмеш төрле һөнәр иясе ул классташым Назыйф!



Билалов Рифкать "К-700" тракторын 27 ел иярли. Гомуми механизаторлык стажы 40 елдан артык



Мәҗитов Зөфәр Йофар улы
30 елдан артык хуҗалыкның
алдынгы механизаторы

## Юлбатлылар кайда да сынатмый

**Низамиев Васил Габделхаевич**

1962 елның 8 мартында Юлбат авылында туган. Туган авылында башлангыч мәктәпне бетереп, Сатыш сигезьеллык мәктәбендә тагын дүрт ел укыгач, семьялары белән Казан шәһәренә күчеп китә. Шулай итеп, урта мәктәпне Казанда бетерә һәм шуннан ук армиягә китә. Ватанга тиешле хезмәтен үтәгәч, Казан төзүче инженерлык институтының (КИСИ) төзелеш факультетына укырга керә. 1988 елда институтны гел “бишле”гә генә бетереп, материаллар каршылыгы кафедрасында эшкә кала. 1994 елда “Күп катлы бөтерелгеч кабырчыкларның күтәрүчәнлек сәләте” темасына кандидатлык диссертациясен яклый. 2000 елдан бүгенге көнгә кадәр ул шул ук кафедрада доцент булып эшли.



Низамиев Васил
Габделхай улы

Аның 30 дан артык фәнни мәкаләсе бар. Ул – студентлар өчен 10 лап методик һәм уку кулланмаларының авторы. Алар арасында татар телендә бастырылган кулланмалар да бар.

Васил Габделхаевичның фәнни кызыксынулары композит материалларның механикасы һәм төзелеш конструкцияләрен хисаплау ысулларына бәйле.

Ул кафедраның алдынгы доценты, институтның төп белгечлекләре буенча лекцияләр укый, практика һәм лаборатор дәресләр алып бара. Аның бүгенге көндә берничә аспиранты бар. Бер аспиранты 2010 елда кандидатлык диссертациясен яклады.

Васил Габделхаевич – фәнни грантларда катнашучы (Халыкара фәнни грантлар, РФФИ, НИОКР), биналар һәм корылмаларның төзелеш конструкцияләренә экспертиза ясый торган группаның фәнни җитәкчесе. Ул җитәкли торган галимнәр группасы төзелеш материалларына һәм конструкцияләренә сынаулар үткәрә; яңа чыгарылган хисаплау комплексларыннан һәм шулай ук үзләре язган санча программалардан файдаланып, төзелеш конструкцияләренең ныклыгын, катылыгын һәм тотрыклылыгын тикшерә; аларның төзелеш конструкцияләрен ныгыту өчен үзләре уйлап чыгарган оригинал техник ысуллары бар.

**Гайфуллин Хәйдәр Вәли улы**

1956 елда Юлбат авылында туа. Юлбат башлангыч, Сатыш сигезьеллык, Саба урта мәктәпләрендә белем ала. 1992 елда Казан төзүче инженерлык институтын тәмамлый.

1979-1990 елларда Казан шәһәрендәге “Союзхимпромпроект” институтында техник һөнәреннән архитектура-төзелеш бүлеге начальнигына кадәр вазифаларны башкара. Аның җитәкчелегендә СССР Оборона министрлыгының 100 бинасы һәм 25 объектта корылмалары проектлана һәм төзелә.

1991-1998 елларда – Симферополь шәһәрендә ООО “Крымтур” җәмгыятендә әйдәп баручы белгеч. Бу җәмгыять Германиянең “Газанлаген инженеринг” BAU фирмасы белән берлектә туризм объектлары төзү белән шөгыльләнә.

1998-2002 елларда – “Яссон” төзелеш фирмасында баш инженер, әйдәп баручы белгеч.



Мөбәрәкҗанов Расим Раиф улы

**Мөбәрәкҗанов Расим Раиф улы**

1957 елда Юлбат авылында туа, башлангыч белем ала, Сатыш сигезьеллык, Саба урта мәктәпләрен тәмамлый. 1974-1975 елларда Казан төзелеш училищесында укый. 1975-1979 елларда колхозда мастер булып эшли. 1979-1984 елларда Казан төзүче инженерлык институтында белем ала. 1984-1989 елларда “Искра” колхозында прораб булып, 1989 елдан Казан йортлар төзү комбинатында өлкән прораб булып эшли.

**Сафин Рафис Фатхулла улы**


Сафин Рәфис Фатхулла улы 1958 елның 20 мартында Саба районының Юлбат авылында туган. 1965-1969 елларда Юлбат башлангыч мәктәбендә белем ала. 1969-1975 елларда Саба урта мәктәбендә укый, аннан соң үзенең туган авылында колхозчы булып эшли.

1976-1978 елларда Совет Армиясендә хезмәт итә.

1979 елда Казан дәүләт ветеринария институтына укырга керә, 1984 елда аны тәмамлап, үзенең туган авылында ветеринария табибы булып өч ел эшли.

1987 елдан бүгенге көнгә кадәр – “Казан” кошчылык фабрикасында цех начальнигы. Үзенең хезмәт чорында ул күп кенә мактау кәгазьләре һәм кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнеп килә.

Тормыш иптәше сәүдә өлкәсендә эшли. Ике кыз тәрбияләп үстерделәр. Олы кызы, югары белем алып, хәзерге көндә банк хезмәткәре. Кече кызы Казан дәүләт медицина университетында белем ала.



Сафин Рафис Фатхулла улы



Хәбибуллина (Сафина) Раилә Фатхулла кызы

**Хәбибуллина (Сафина) Раилә Фатхулла кызы**

1960 елның 18 ноябрендә Юлбат авылында туа. Саба урта мәктәбен тәмамлаганнан соң Казан ветеринария институтына укырга керә. 1979-1984 елларда зооинженерлык факультетында белем ала. 1985-1994 елларда Казанда Госплемобъединениеда эшли. 1994 елдан “Казан” кошчылык фабрикасында үз белгечлеге буенча хезмәт юлын дәвам итә. Тормыш иптәше Гомәр белән ике бала үстерделәр. Икесе дә югары белем алып үз белгечлекләре буенча эшлиләр.

**Галиев Рәис Нургали улы**

1958 елның 29 маенда Юлбат авылында туа. Юлбат башлангыч, Саба урта мәктәпләрендә белем ала. 1982 елда Казан дәүләт медицина институтын тәмамлап, Яр Чаллы шәһәренә эшкә юллама ала. 1982-1992 елларда – шәһәрнең ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү больницасында терапия бүлеге җитәкчесе, 1992-2008 елларда – 6 нчы шәһәр больницасында терапия бүлеге җитәкчесе, 2008 елдан бүгенге көнгә кадәр Эчке эшләр бүлеге хезмәткәрләре госпиталендә терапия бүлеген җитәкли. Югары категорияле врач, Татарстан Республикасының мактаулы сәламәтлек саклау хезмәткәре.



Галиев Рәис Нургали улы

### Низамиев Рамил Газиз улы


Низамиев Рамил Газиз улы

1967 елның 7 январендә Юлбат авылында дөньяга килә. 1974 елда Юлбат башлангыч мәктәбенә укырга керә. 5-10 сыйныфларны Сатыш урта мәктәбенә йөреп укый. 1984 елда Казан дәүләт төзелеш институтына (КИСИ) укырга керә. Икенче курс студенты, Ленин стипендиаты Рамил Газиз улын 1986 елда армия сафларына алалар. Ул ике ел хәрби хезмәтен Смоленск өлкәсе Десногорск поселогында үти. Хәрби хезмәттән соң укуын шул ук уку йортында дәвам итә. 1989 елда авылдашы, классташы Фирая Фарук кызы белән тормыш кора. Уллары Замир һәм кызлары Гөлнараны үстерәләр. 2001 елга кадәр Рамил Газиз улы туган колхозы "Искра"да прораб булып эшли. 2001-2006 елларда Саба һәм Теләче районнарының төзелеш инспекторы вазифасын алып бара. 2006 елдан – Саба муниципаль районының баш архитекторы. 2013 елдан – Теләче муниципаль районының баш архитекторы.

### Ибәтуллин Рамазан Мөдәрис улы


Ибәтуллин Рамазан Мөдәрис улы (1989)

Ибәтуллин Рамазан Юлбат авылында туа. 1990 елда Казан дәүләт медицина институтын тәмамлап, Саба үзәк шифаханәсенә эшкә кайта. Тирән белеме, үз эшенә җаваплы каравы белән авыруларның ихтирамын казанды. Авылдашлары аны һәрберсенең гозерен игътибар белән тыңлавы, үз итеп биргән киңәшләре өчен яраталар һәм хөрмәт итәләр. Медицина белеме булмаган авыл кешесе өчен үз вакытында бирелгән киңәш, ягымлы сүз кайчак иң файдалы дәва булганы һәркемгә билгеле. Рамазан Мөдәрисович та бу хакыйкатьне беркайчан да исеннән чыгармый.

Үзе кебек үк чын мәгънәсендә шәфкать иясе булган балалар табибәсе Эльвира Нурисламовна белән ныклы гаилә корып, 2 бала үстерәләр. Әти-әнисенең игелекле улы, ике кыз туганының ныклы терәге дә ул Рамазан Мөдәрисович. Гаиләсендә иминлек, эшендә уңышлар телибез аңа.

### Бадиков Айдар Дәүли улы

Аңа теш дәвалату өчен бер ай алдан язылырга кирәк. Мин теш авырулары буенча бары тик Айдарга гына йөрим. Булса да булыр икән авыруларга шулкадәр



Бадиков Айдар Дәүли улы

игътибарлы табиб... Халык арасында йөргән бу сүзләрнең барысы да Бадиков Айдар Дәүли улы турында. Аны чын мәгънәсендә “Халык табибы” дип атап була.

Айдар Юлбат сигезьеллык, Сатыш урта мәктәпләрен тәмамлый. Медицина белеме алгач, районда беренчеләрдән булып, 1994 елда үзенең теш дәвалау кабинетын ача. Озак еллар дәвамында райондашларга игелекле хезмәт күрсәтә.

**Әхмәтшина (Нигъмәтҗанова) Чулпан Рөстәм кызы**



Әхмәтшина (Нигъмәтҗанова) Чулпан Рөстәм кызы (1996 ел, чыгарылыш класс альбомыннан )

Игелекле һөнәр ияләреарасындада“иң-иң”нәре була. Шундый һөнәрләрнең берсе – балага бу дөньяга килергә булышучы табибтыр, мөгаен. Чулпан Рөстәмовна – нык ихтыяр көче, шәфкатьлелек, кешеләрне ярату аеруча сорала торган шундый профессияне һич икеләнмичә сайлады. Мәктәптә уку елларында ук ул табиб булырга хыялланды. Алай гына да түгел, ул үзен бу профессияне үзләштерүгә максатчан әзерләде: фән нигезләрен бик тырышып үзләштерде. Унберенче сыйныфта укыганда район олимпиадаларында 6 призлы урын алганы хәтердә. Бу рекордны “яңарта” алган укучы безнең мәктәптә әлегә юк. Мәктәпне алтын медальгә тәмамлаган беренче укучы да ул. Юлбат урта мәктәбеннән чыккан укучылар арасында медицина университетына алар ике классташ беренче булып укырга керделәр. Хәзер аның һәр хезмәт көне яңа туган сабыйның беренче сулышын тоюдан, аңа яшәүгә фатиха бирүдән башлана, чөнки Чулпан Рөстәмовна – Республика клиник хастаханәсенең Перинаталь үзәгендә эшләүче тәҗрибәле, абруйлы табиб-гинеколог.

**Рәхимуллин Тәлгать Миннегали улы**

Рәхимуллин Тәлгать Миннегали улы 1974 елның 21 ноябрендә Юлбат авылында колхозчы гаиләсендә туа. 1991 елда Юлбат урта мәктәбен тәмамлап, Мәскәү энергетика институтының Казан филиалына укырга керә. Аны 1997 елда “Электроэнергетические системы и сети” белгечлеге, инженер-электрик һөнәре буенча тәмамлый. Хезмәт юлын 1997 елның мартында “Искра” колхозында электрик булып башлап җибәрә. 1997 елның 26 сентябреннән хезмәтен, ОАО



Рәхимуллин Тәлгать
Миннегали улы

“Татэнерго”ның Алабуга электр челтәренең Саба бүлегендә подстанцияләргә хезмәт күрсәтү электромонтеры булып дәвам итә. 1998 елның 5 гынварыннан Татарстан Республикасының энергия куллануны күзәтү дәүләт инспекциясенең Алабуга филиалына кабул ителә. 2004 елдан бүгенге көнгә кадәр “Приволжское управление Федеральной службы по экологическому, технологическому и атомному надзору Ростехнадзора”да Саба һәм Теләче районнары буенча дәүләт инспекторы вазифасын башкара.

**Шәмсиева Ләйлә Тимергазиз кызы**



Шәмсиева Ләйлә

1996-2002 елларда Казан дәүләт медицина университетының стоматология факультетында укый. Аны уңышлы тәмамлап, Казан шәһәрендәге икенче номерлы балалар теш поликлиникасына эшкә урнаша. 2010 елдан Саба Үзәк больницасының стоматология бүлегендә эшли. Ләйлә Тимергазизовна – Юлбат урта мәктәбен тәмамлап иң беренчеләрдән булып Медицина институтына кергән ике классташның берсе. Кечкенәдән тәрбияләнгән ихтыяр көче, хезмәтне яратуы аңа теш дәвалау кебек катлаулы эшнең остасы булырга ярдәм иткәндер. Үз эшенең остасы дип язарга җирлек тә бар: Казанда һәм Сабада Ләйлә Тимергазизовнада тешләрен дәвалатучылардан уңай фикерләр бик еш ишетергә туры килә.

**Сафин Руслан Илдар улы**



Сафин Руслан

1984 елда Юлбат авылында туа. 2002 елда Юлбат урта мәктәбен алтын медальгә тәмамлап, Казан финанс-икътисад институтына укырга керә. 2006 елда менеджмент бакалавры, 2007 елда менеджмент специалисты дипломнары ала. “Россия почтасы”нда бухгалтер, Таттелекомның Саба районы идарәсендә экономист, 2009 елның 1 июненнән шул ук идарәдә сату һәм хезмәт күрсәтү бүлеге начальнигы булып эшли. Хәзер Дәүләт статистикасының Саба территориаль бүлекчәсе җитәкчесе.


## Сафин Радик Илдар улы



Сафин Радик

1987 елда Юлбат авылында туа. 2004 елда Юлбат урта мәктәбен тәмамлап, Казан энергетика унивеситетына укырга керә. Промышленность предприятиеләрен һәм шәһәрләрне электр белән тәэмин итү факультетында укып, 2008 елда техника һәм технология бакалавры, 2010 елда техника һәм технология магистры дипломнары ала. Хәзерге вакытта Казан шәһәрендә шәхси эшмәкәр.

## Хафизов Нурмый



Хафизов Нурмый Садыйк улы

Юлбат авылыннан Нурмый Хафизов Чернобыль АЭСындагы радиация нәтиҗәләрен бетерүдә катнаша. Ул 1986 елның 14 сентябрендә китә. Бу вакытта инде 40 яшьтән узган була.

– Комбайнда эшләгән вакыт. Комиссариаттан чакыру килде, – дип искә ала Нурмый абый. – Карышып тормадык, киттек. Без 6 айга алынган идек. Барысы 82 көн булдык. Станциягә баргач, андагы хәрабәләрне күреп шаккаттык. Тирә-юньдә тереклек юк, кошлар очмый. Безнең яшәү урыны Чернобыльдән 65 километр читтә, Иванково дигән шәһәрдә иде. Мин аварияне бетерүдә катнашучы техниканы туплап тордым. Станциягә кертер алдыннан саклагыч киемнәр бирәләр, авыз-борынны исә марлядан ясалган повязка белән генә каплыйсың. Нурланышның дозасы аның алсулана башлавыннан да күренә. Артык тоткарлансаң, рация аша, срогың тулды, чык, дип шундук хәбәр итәләр.

## Ганиев Альберт



Ганиев Альберт Абуталип улы

Чернобыль фаҗигасе Альбертның хәрби хезмәте чорына туры килә. 1986 елның 12 сентябреннән 20 ноябрьгә кадәр катастрофа нәтиҗәләрен бетерүдә катнаша. Аларның часте ЧАЭСка бик якын урнашкан Припять елгасы аша салынган понтон күпердә торып, транспорт хәрәкәтен тәэмин итә. Альберт Ганиев “Чернобыль атом электр станциясе катастрофасы нәтиҗәләрен бетерүдә катнашкан өчен” медале белән бүләкләнә.

# *Юлбат авылында медпункт тарихы*

*(Медпункт тарихын бүгенге көндә фельдшер булып эшләүче Гайфуллина Венера Галимулла кызы язып бирде)*

1950 елда Юлбат авылында Факия апа өендә (хәзерге Халиков Илшатлар урыны) беренче медпункт ачыла. Аның беренче фельдшеры булып Казан кызы Хәсәнова Зәйнәп эшли, ә Факия апа санитарка булып тора. Медпункт дүрт авылга: Юлбат, Тенеки, Йосыф-Алан, Урта Саба авылларына хезмәт күрсәтә. Хәсәнова Зәйнәп 1953 елга кадәр эшли. Шул елны Кутлина Оля исемле кызны фельдшер итеп билгелиләр. Бер елдан соң ул Мәртен егетенә кияүгә чыгып китә. 1954 елда Чистай кызы Ситнова Аня эшкә килә. Ике ел үзе генә эшли. 1956 елда аның янына үзебезнең авыл кызы – Алабуга медицина училищесын тәмамлаган Кәримова Әкълимә Кәрим кызы акушерка итеп билгеләнә. Икесе бергә алар 1958 елга кадәр эшлиләр. Бик авыр еллар була: машина-транспорт юк, авыр очракларда авыруларны район шифаханәсенә ат җигеп илтәләр, бала таптыру да өйдә башкарыла. Бар да авыл фельдшеры белән акушерка җаваплылыгында була.

1956 елда медпунктны Факия апа өеннән Билал абыйлар өенә (хәзерге Мифтахов Хәнәфия абыйлар урыны) күчерәләр. Пункт анда күчкәч, санитарка булып Кәримова Мәүгыя апа эшли.

1958 елда Казан медицина училищесын тәмамлаган Түбән Шытсу егете Байкиев Рушан Сәлимгәрәй улын Саба районына эшкә җибәрәләр һәм Юлбат медпунктына мөдир итеп билгелиләр. 1960-1962 елларда, Әкълимә апаның декрет ялы вакытында, Байкиев Рушан белән Сатышның Әхәтова Мәфрүзә Әхәт кызы эшли. 1962 елда Рушан Нырсыга китә.

Шушы елда санитаркалар да алышына. Мәктәпне генә тәмамлаган Галиева Фәния эшкә керә. Бер ел эшләгәч, ул китә, аның урынына әнисе Галиева Гыйлемхаҗирә эшләп кала.

Әкълимә апа декрет ялыннан килгәч, Ногманова Эльвира белән эшләп ала.

1964 елда яңа медпункт салына. Ул бинада хәзер эшмәкәр Кадыйрова Г.Г. кибете.

1966 елда Сатыш авылының Хуҗина Флера Ибраһим кызы эшкә җибәрелә. Бу вакытта Әкълимә апа ялда була. Бераз эшләгәч, Ногманова Эльвира китә.

1967 елның июль аенда Зеленодольскиның медицина училищесын тәмамлаган Зеленодол районы кызы Әхмәтҗанова Фәридәне юллама белән Саба районына эшкә җибәрәләр һәм Юлбат медпунктына билгелиләр. Бергә ике ай эшләгәч, Хуҗина Флера китә, Фәридә апа үзе генә эшләп кала. 1968 елның башында Әкълимә апа да эшкә килә. Алар бергә 1976 елга кадәр эшлиләр. Аннан соң Әкълимә апа семьясы белән Казанга күчеп китә. 1970 елда санитарка Галиева Хаҗирә урынына Әхтәмова Фәрәхия килә.

1976 елдан 2001 елның сентябренә кадәр Фәридә апа Юлбат фельдшер-акушерлык пункты белән идарә итә. Бөтен барлыгын шушы эшкә багышлый. 1977 елда, Фәридә апа декрет ялында вакытта, Йосыф-Алан авылында фельдшер булып Зәйнуллина Сәрирә Галим кызы килеп эшли.

1985 елда хәзер почта бүлекчәсе урнашкан бинада яңа медпункт ачыла. Шул медпунктта 1989 елдан колхоз идарәсе тарафыннан физиотерапия медицина бүлмәсе ачыла. Иң беренче булып Зеленодольск училищесын тәмамлаган Тенеки авылы кызы Мөбәрәкшина Нәзирә Юныс кызы шунда хезмәт юлын башлый. 1993 елның декабрь аенда ул Сабага китә. Аның урынына шушы авылга килен булып килгән Бадикова Лилия билгеләнә. 1994 елның гыйнварында Бадиков Айдар тарафыннан стоматология бүлмәсе ачыла һәм 1997 елга кадәр авыл халкына хезмәт күрсәтә. 1994 елны санитарка Әхтәмова Фәрәхия урынына Галимҗанова Нәсимә эшкә керә.

2001 елда Фәридә апа лаеклы ялга китә. Юлбат медпунктына фельдшер булып Алабуга медицина училищесын тәмамлаган Иләбәр кызы Хәмидуллина Алсу килә. Ике елдан соң эштән китә. 2003 елның февраль аеннан ФАП мөдире итеп Казан медицина училищесының акушерлар бүлеген тәмамлаган Юлбат авылы кызы Гайфуллина Венераны билгелиләр.

2004 елның ноябрендә медпунктны Юлбат мәдәният йорты бинасына күчерәләр. Хәзерге көндә фельдшер булып Гайфуллина Венера эшли.



Кәримова Әкълимә
Кәрим кызы

**Кәримова Әкълимә Кәрим кызы**

1936 елның 17 январенда Юлбат авылында дөньяга килә. Шушы авылда башлангыч мәктәптә, Сатыш җидееллык мәктәбендә укый. Унынчы классны Саба урта мәктәбендә тәмамлый. 1954 елда Алабуга медицина училищесына укырга керә. 1956 елда фельдшер-акушерлык бүлеген уңышлы гына тәмамлый һәм Саба районына эшкә кайта. Юлбат медпунктына акушерка итеп билгеләнә. Ситнова Аня, Байкиев Рушан, Ногманова Эльвира, Әхмәтҗанова Фәридәләр белән эшли. 1976 елда семьясы белән Казанга күчеп китә.

**Әхмәтҗанова Фәридә Мөхәммәтхан кызы**



Әхмәтҗанова Фәридә
Мөхәммәтхан кызы

1946 елның 17 апрелендә Зеленодольск районы Караужа авылында туа. Шул авылда 1963 елда урта мәктәпне тәмамлый. 1964 елда Зеленодольск училищесына укырга керә. Медсестра булырга укый. 1967 елда училищены тәмамлый һәм аны юллама белән Саба районы шифаханәсенә җибәрәләр. Сабадан Юлбат медпунктына эшкә билгелиләр. Кәримова Әкълимә апа белән 8 ел бергә эшли, ә калган 25 елын үзе генә авыл халкына хезмәт күрсәтә. Тырыш хезмәте өчен мактау грамоталары белән бүләкләнә. Хәзерге көндә Юлбат авылында яши. Пенсиядә.

**Байкиев Рушан Сәлимгәрәй улы**

1938 елда Түбән Шытсу авылында укытучы семьясында туа. Шытсу сигезьеллык мәктәбендә белем ала. Унынчы сыйныфны Саба урта мәктәбендә бетерә. Казан медицина училищесына укырга керә. 1958 елда училищены тәмамлап, Саба район шифаханәсенә эшкә кайта. Аны Юлбат медпунктына мөдир итеп билгелиләр. 1962 елда Нырсыга китә. Хәзерге көндә Түбән Кама шәһәрендә яши һәм эшли.

**Җәмилова (Әхәтова) Мәфрүзә Әхәт кызы**



Җәмилова (Әхәтова)
Мәфрүзә Әхәт кызы

1941 елны Сатыш авылында туа. Сатыш җидееллык мәктәбен. 1958 елда Казан медицина училищесына укырга керә. Фельдшер-акушерлык бүлеген тәмамлап, 1960 елд туган якларына кайта һәм декрет ялына киткән Әкълимә апа урынына Юлбат медпунктына эшкә җибәрелә. Ике ел эшләгәч, Саба бала тудыру йортына акушерка итеп билгеләнә. Озак еллар Чаллының 1 нче номерлы бала тудыру йортында эшли. Хәзерге көндә лаеклы ялда. Гаиләсе белән Яр Чаллы шәһәрендә яши.

**Хуҗина Флера Ибраһим кызы**

1946 елда Сатыш авылында дөньяга килә. Сатыш сигезьеллык мәктәбен тәмамлап, Казан медицина училищесына укырга керә. 1966 елда Юлбат медпунктына эшкә кайта. Озак эшләми, авыл фельдшеры Әкълимә апа декрет ялыннан килгәч, китә. Хәзерге көндә Казан шәһәрендә яши.



Гайфуллина Венера
Галимулла кызы

**Ситнова Аня**

1935 нче елда Чистай районында туа. Медицина училищесын тәмамлагач Саба районына эшкә җибәрелә. Юлбат медпунктына фельдшер итеп билгеләнә. 1958 нче елда Свердловск якларына китә. Шул яклардан 1-2 хаты да килә.

**Гайфуллина Венера Галимулла кызы**

1978 елның 29 декабрендә Юлбат авылында туа. Юлбат урта мәктәбен тәмамлап, Казан медицина көллиятенең акушерлар бүлегенә укырга керә. 2000 елда акушер эше буенча диплом алып

чыга һәм Саба район шифаханәсенә эшкә кайта. Бер ел неврология бүлегендә эшләгәч, декрет ялына китә. Ялдан Юлбат медпунктына мөдир булып эшкә чыга.

**Хәмидуллина Алсу Рәшит кызы**

1981 елда Иләбәр авылында туа. Унынчы классны тәмамлап Алабуга медицина училищесына укырга керә. 2001 елда Саба район шифаханәсенә эшкә кайта һәм Юлбат медпунктына җибәрелә. 2003 елга кадәр эшли. Хәзерге көндә Теләче район шифаханәсендә эшли. Шушы авыл килене.

## *Китапханә тарихы*

*(Китапханәче Хаҗиева Кадерия Хәтмулла кызы язмаларыннан.)*



Хаҗиева Кадерия
Хәтмулла кызы

Юлбат авыл китапханәсенең тарихы Тенеки авылы белән бәйле. Тенекидә китапханә 1958 елда ачыла. Нуриев Әнәсләр каршындагы клубның сәхнәсе артында 1-2 шкафтагы китаплар була ул. 1960 елда Фәрхәнә Мөҗипова эшкә җибәрелә. "Китаплар аз, Сабадан алып төшеп, укыганын кире менгереп йөрде. Китапханәне Фәрхәнә булдырды. Китап кайтартты, ат белән китап ташыды, җәяүләп сумка белән дә ташый иде.

Фәрхәнә фермага да еш килде. Без, кызлар, шунда эшлибез, китапларны кычкырып укыйбыз, әңгәмәләр үткәрәбез, газета мәкаләләрен бергәләп укып тикшерәбез, фикерләшәбез. Концертлар, театрлар куябыз. Театр-концерт белән Мәртенгә, Туктарга, Шытсуга барганны хәтерлим", – ди замандашы Гөлчирә апа Мифтахова.

1969 елның азагында Фәләхиев Фаяз абыйлар каршында яңа клуб ачыла (хәзер дә шунда), клубка терәп, кечкенә генә китапханә эшләнә. Фәрхәнә апа 1971 елда авыл Советы председателе итеп сайлангач, китапханәдә Сатыш кызы Зарипова Корбанбикә эшләп ала. 1971 елның азагында Гомәрова (Билалова) Нәсимә эшли башлый. Авыл Советы аша китапларны бибколлектордан кайтарта. "Балалар белән әкиятләр, шигырь кичәләре, китап укучылар конференцияләре үткәрелде. Елга уртача 769 укучыга 15000 китап бирелә иде", – дип искә ала Нәсимә Билалова.

Билалова Н. 1976 елга кадәр эшли, аннан соң Йосыф-Алан авылыннан Каюмова Флера эшләп ала, аннан соң Нуриева Миңнегөлне эшкә алалар.



Мөбәрәкҗанова Сәрия Самат кызы, мәдәният йорты директоры

Юлбат яшьләре китапханәнең зур авылга күчүен колхоз идарәсеннән, авыл Советыннан сорыйлар. Комсомол җыелышларында шул хакта тәкъдимнәр әйтәләр. Ниһаять, 1978 елда китапханә Юлбатка күчерелә, башлангыч мәктәп бинасыннан бер бүлмә бирелә. Юлбат кызы Сафина Раилә китапханәче итеп куела, ләкин ул озак эшләми, Казанга укырга китә. 1979 елның сентябреннән китапханәче итеп Хаҗиева Кадерия эшкә алына. 1981 елда Хаҗиева К. декрет ялына киткәч, Бадыйкова Чулпан эшкә килә. Ул Казанга укырга киткәч, декрет ялы тулмаса да, Хаҗиева кабат эшкә чакырыла.

1982 елда сигезьеллык мәктәп ачыласы булгач, китапханә урнашкан бүлмәне бушатырга туры килә. Китапханә Садыйкова Маһирә йортына күчә, авыл Советы 30 сум акча түләп тора. Китапханә күчкәч, Сабирова Фирдәвес эшли. 1983 елның азагында эшкә кабат Хаҗиева Кадерия килә, 1985 елның октябренә кадәр эшли һәм декрет ялына китә. Аның урынында Мәҗитова Земфира эшли башлый. 1986 елның декабрендә яңа мәдәният йорты бинасы ачыла. Китапханәгә бүлмә бирелә һәм китаплар шунда күчерелә. 1987 елның ноябрендә Х.Кадерия эшкә яңадан килә һәм 2014 елның июненә кадәр, лаеклы ялга чыкканчы халыкка игелекле хезмәт күрсәтә. Анын урынында Хәмитова Нәсфия Әнәс кызы эшли башлый.

**Авыл клубында эшләгән кешеләр:**

1959-1962 еллар – Рәисә Зыятдинова (хәзер Шәмәрдәндә яши).

1962-1965 еллар – Кәримова Мәдинә Вафа кызы (хәзер Казахстанның Акмала шәһәрендә яши).

1965-1999 еллар – Кәримова Раушания Мансур кызы.

1976-1978 еллар Мөбәрәкова Илзира Зиннур кызы.

1977-1980 еллар – Гайфуллина Диләрә Мирсәй кызы.

1980 елдан бүгенге көнгә кадәр – Мөбәрәкҗанова Сәрия Самат кызы.

Ул 1980-1983 елларда читтән торып Алабуга мәдәни-агарту училищесын тәмамлый. Бары тик бер урында эшләп, озак еллар авыл халкына культура хезмәте күрсәтә.

Шәмсиев Булат Рәшит улы – 1990 елдан бүгенге көнгә кадәр мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе.



Шәмсиев Булат Рәшит улы

## Гали Ильясов



Гали Ильясов

Гали Ильясов – Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты, җырчыларның Бөтенроссия конкурсы лауреаты. Аның җырлары илебезнең зур концерт залларында яңгырады, Лондон, Лейпциг, Зальцбург шәһәрләре сәхнәләрендә, Италиядә, Төньяк һәм Үзәк Африка илләрендә кайнар алкышларга күмелде. Гали Ильясовның репертуары бик бай иде. Татар композиторлары әсәрләрен, халык җырларын башкаруы белән бергә, ул рус һәм итальян халык көйләрен дә зур осталык белән башкарды. Аның репертуарында бөтендөнья опера сәнгатенең лирик-драматик тенор тавышка язылган иң гүзәл партияләре бар иде. Алар П.И.Чайковскийның “Евгений Онегин” операсыннан Ленский, Римский-Корсаковның “Май төне” операсыннан Левко, Дж.Пуччининың “Богема” һәм “Турандот” операларыннан Калаф, Рудольф арияләре, Ж.Бизеның “Кармен” операсыннан Хозе партияләре...

Табигать бүләк иткән матур тембрлы тавышы өстенә Гали Ильясов – профессиональ белем алган җырчы. Ул Мәскәү консерваториясе каршындагы музыка училищесында танылган педагог Борис Михайлович Беркович классында укый, камера, эстрада, симфоник оркестр планында уңышлы эшли алырлык җырчы булып җитешә.

Гали Ильясов 1936 елның 24 июлендә Приморск краеның Сучан (хәзерге Партизанск) шәһәрендә шахтер гаиләсендә туа. Әтисе чыгышы белән Саба районы Юлбат авылыннан, Юлбатта 14 яшькә кадәр яшәгән.

Тын Океанның диңгез авиациясе флотында хезмәт иткәндә, Гали Ильясов, җырчы буларак киң танылып, армия смотрларында катнаша, лауреат исеме ала. Җырга гашыйк Гали укырга, музыкаль белем алырга, профессиональ җырчы булырга хыяллана. Аның бу хыялы тормышка аша. Ул 1962-1965 елларда Мәскәү консерваториясе каршындагы музыка училищесында белем ала. Училищены уңышлы тәмамлап, 1965 елда Казанга опера һәм балет академия театрына эшкә кайта.

1965-70 нче елларда Татар дәүләт филармониясендә сәнгать җитәкчесе булып эшли. Күпкырлы таланты, югары кешелек сыйфатлары белән ул коллективта хөрмәт казана.

Мәскәүнең Александров исемендәге җыр һәм бию ансамбленә солистлар кабул итү конкурсын уңышлы узып, эшкә чакыру алгач та Гали Казаннан китмәде, әти-әнисе туган туфракка тугры калды.

***Гали Ильясов турында Сафин Илдар Фатхулла улы истәлекләре***

Гали абый безгә әни ягыннан туган тиешле кеше. Минем әни белән Гали абый икенче буын туганнар, ягъни аларның әтиләре бертуган. Аның әтисе Миңнегалинең (аны Галинең сәхнәдәшләре Гани улы дип йөрттеләр) нигезе безнең нигез белән янәшәдә. Минем бабам Якуп шул нигездән, өйләнеп шактый яшәгәннән соң, хәзер мин яши торган нигезгә башка чыккан. Әтисе Ильяс үлгәннән соң, 14 яшьлек Миңнегалине әнисе Таифә, вербовкага язылып, Сучанга алып киткән. Миңнегалинең  авылдан бер дә китәсе килмәве, ындыр юлына, бакча артларына чыгып елавы турында өлкән буын туганнар еш искә алалар иде.

Шулай итеп, Миңнегали улы Гали, Юлбатта  тумаса да, әтисенең гомерлек сагынулары аркылы безнең авыл белән бәйләнгән, үзен Юлбаттан чыккан кеше дип санаган. Миңнегали абыйның 1989 елда кызы Шәмсенур белән Сабантуйга кайткач, авыл турында искиткеч җылы истәлекләре белән уртаклашканы хәтердә (ул шактый өлкән яшьтә иде, Казанга күчеп кайтып кызы һәм кияве тәрбиясендә яшәде).

Гали Ильясов белән беренче тапкыр мин башлангыч классларда укыганда, 1964 еллар тирәсендә, безнең авылга кунакка кайткач күрештем. Ул студент иде әле. Хатирәләрнең күбесе истә калмаган. Шулай да аның Тенеки башлангыч мәктәбенә (минем әни шунда укытучы булып эшләде) җырлый-җырлый плакат яза торган перо белән бик матур итеп лозунг язып бирүе истә калган.

Соңыннан, танылган артист булгач, ул безнең авылга берничә тапкыр кайтты. Ул заманда “тере” артист белән аралашу зур вакыйга санала иде. Безнең өйдә күрше-тирә, туганнар, авыл халкының җыйналып, мәҗлес ясап утырулары истә калган. Авыл кешеләреннән Вәли һәм Һарун абыйларның килүен, ә Фарук абыйның гармунын алып килеп үзе дә уйнап утырганын хәтерлим.

1972 елда, мин 9 сыйныфны тәмамлаган елны, җәй көне безгә кунакка кайткач, ул мине үзләренә алып китеп кунак итте.  Гали абыйларда бер атнадан артык тордым. Аның гаҗәеп дәрәҗәдәге кунакчыллыгы, миңа, яшүсмер малайга, карата игътибарлы һәм кече күңелле булуы бүгенге көнгә кадәр минем өчен үрнәк һәм өлге. Без аларның дачасында булдык, берничә көн складларда йөреп, ул миңа бик матур костюм сайлап бүләк итте. (1970 нче еллар – дефицит заманы, кибет киштәләрендә бер сыйфатлы әйбер алырмын димә, ә Гали абыйның танышлары кибетләрдә һәм складларда күп булып чыкты). Миңа, гади авыл баласына, аның белән йөрү күңелле дә, шул ук вакытта сәеррәк тә иде, чөнки ул кая барса да такси белән йөри, беркайчан трамвай, троллейбусларга утырмый иде.

Аш өстәле артында утырганда да миңа таныш булмаган ризыклар очраганда уңайсызланып калган вакытлар булды. Кара уылдыкны, никадәр кыстасалар да, ашый алмадым. Гали абыйның: “Син нәрсә, моны обкомдагылар гына ашый бит, ә син ашамый  утырасың”, – дип шаяртканы хәтердә.

Тагын шунысы истә калган: ул вакытта аның Жданов урамындагы квартирасында пианино тора иде. Гали абый анда үзе уйнап җырлый, көйләр дә яза, ничек, сиңа ошыймы, дип миннән дә сорый иде. Ул вакытта кызлары Ләйсән кечкенә иде әле.



Мәктәп музеенда Гали Ильясовның концерт костюмы

Гали абый белән соңыннан да еш аралашып яшәдек, Казанда укыганда аларга еш барып йөрдем.

60 яшьлек юбилеен ул Юлбат авылы сәхнәсендә үткәрергә теләде. Аның юбилей кичәсенә авыл халкы бердәм җыйналды, культура йорты шыгрым тулы иде. Юбилей көннәрендә ул безнең мәктәп музеенда булды, үзенең “Оныттың бугай” дигән җырлар китабын истәлек кулъязмасы белән музейга бүләк итте.

Гали Ильясовның тулы исеме Әхмәтгали Ильясов. Гали исеме “алуы” болайрак була. Беренче концерт алдыннан афиша ясаганда художество җитәкчесе сәхнә псевдонимы алырга тәкъдим итә. “Әхмәтгали Ильясов” афишага туры килми, ди. Әхмәт Ильясов варианты да ошап бетми, Әхмәт – киң таралган исем, дип уйлыйлар. Фикерләшкәннән соң, Әхмәтгали Ильясов үзе “Гали Ильясов” дип язарга тәкъдим итә. Худсовет членнарының барысы да бу яңгыраш белән килешә. Шулай итеп, беренче зур концертыннан соң ул танышлар, туганнар, тамашачылар өчен Гали Ильясов булып китә.

Без хәзер мәктәп музеенда Гали Ильясов турында истәлекләр туплауны дәвам итәбез. Аның нәсел шәҗәрәсен төзедек. Хатыны Сания апа концерт костюмын музейга бүләк итте. Аның турында фотографияләр, истәлекләр, җырлары язылган грампластинкалар туплауны дәвам итәбез. 60 яшьлек юбилее уңаеннан төшерелгән видеоязманы DVDга күчердек. Гали Ильясов кино төшерү белән мавыга иде. Аның төшергән тасмаларын күргән кеше буларак, язмаларның бик кызыклы булуын әйтә алам. Киләчәктә ул кинотасмаларның фрагменты күчермәсен мәктәп музеенда булдыру турында хыялланам. Әгәр бу эшне эшли алсам, 1970 нче еллар башындагы Юлбат авылы күренешләре дә музейда булачак, дигән сүз, чөнки ул Юлбатны да берничә тапкыр кинотасмага төшереп киткән иде.



Рафинат Сәләхов

**Рафинат Сәлахов**

Рафинат Сәлахов 1951 елның 13 мартында Саба районы Юлбат авылында дөньяга килә. Түбән Кама музыка училищесын, Казан кооператив техникумын,

мәдәният  һәм сәнгать университетын тәмамлый. Ә белемгә сукмак Юлбат башлангыч мәктәбеннән салына. Дүртенче классны авыл мәктәбендә тәмамлаганнан соң, бишенче, алтынчы сыйныфларны Әгерҗе районы Иж-Бубый авылында, әнисе ягыннан әби-бабайларында торып укый. Аннан соң үзебезнең якка кайтып укуын дәвам итә.

Гармунда уйнарга өченче класста өйрәнә, бер үк вакытта рәсем ясау белән дә мавыга.

Ләкин сәнгать юлына кереп киткәнче 21 нче СПТУны тәмамлап, хәрби заводта эшләп ала, шул арада музыка училищесына керер өчен баянда үзенә программа әзерли һәм Түбән Кама музыка училищесына укырга керә. Беренче курсны тәмамлагач, армиягә китә, Мәскәү янындагы музыка взводында хезмәт итә. Үзен булдыклы музыкант итеп таныта, хәрби округта баянчылар ансамбле оештыра һәм тынлы оркестрда баритонда уйный. Армиядән кайткач, укуын дәвам итә. 1975 елдан Татар дәүләт филармониясе солисты Габдулла Рәхимкулов бригадасында 4 ел эшли. Ә Илһам Шакиров белән 1981 елдан башлап 1992 елга кадәр иҗат итә. Аның төркеменең директоры һәм концертмейстеры була.  Рафинат Сәлахов – легендар җырчының 70 яшенә багышлап чыгарылган “Илһам Шакиров” дигән китапны төзүчеләрнең берсе, шушы китапка керткән хезмәте өчен аңа “Бәллүр каләм – 2006” журналистлар конкурсында лауреат дипломы тапшырылды.

Рафинат Сәлахов уйнаган көйләргә кайсы гына сәнгать йолдызы кушылып җырламады икән? Әлфия Афзалова, Габдулла Рәхимкулов, Флера Сөләйманова, Рабига Сибгатуллина, Зәһрә Сәхабиева, Хәнәви Шәйдуллин, Зиннур Нурмөхәммәтов, Хәмдүнә Тимергалиева, Римма Ибраһимова, Венера Шәрипова, Венера Ганиева... Шул ук вакытта ул композиторлык өлкәсендә дә уңышлы эшли. Аның Илдар Юзиев, Роберт Миңнуллин, Гәрәй Рәхим, Рафис Корбанов, Нияз Акмал, Асия Юнысова, Гакыйль Сәгыйров сүзләренә язган 200 гә якын җыры популярлык казанды, шулардан 50се – балалар өчен язылган җырлар.

Рафинат Ясәви улының иҗатына югары бәяне тормыш үзе бирә. Ул – Россиядәге һәвәскәр композиторларның Мәскәүдә үткәрелгән “Нәүрүз моңнары” конкурсы лауреаты, һәвәскәр композиторларның Бөек Ватан сугышында җиңүнең 60 еллыгына һәм Казанның 1000 еллыгына багышланган Икенче Бөтентатар “Барлау” музыка фестиваль-конкурсы лауреаты, Яр Чаллы шәһәрендә үтә торган балалар һәм яшүсмерләр җырлары – “Тургай-2003”, “Тургай-2004” конкурслары лауреаты, Сара Садыйкова исемендәге Беренче ачык регионара конкурс-фестиваль лауреаты  һ .б.

## Рөстәм  Зарипов

1952 елның 27 октябрендә Саба районы Түлешкә авылында туа. 1969 елда Саба урта мәктәбен, 1974 елда КИСИ (Казан төзүче инженерлар институтын) тәмамлый. Саба һәм Мөслим районнарындагы төрле оешмаларда халык хуҗалыгында мастер, өлкән инженер, юл бүлеге җитәкчесе, баш инженер вази-



Рөстәм Зарипов

фаларын башкара. 1984-1990 елларда Мөслим милиция бүлегенең сәяси эшләр буенча җитәкче урынбасары, 1990-1996 елларда Шәмәрдән газ куу идарәсе җитәкчесе урынбасары булып эшли. Хәзерге вакытта “Таттрансгаз” берләшмәсендә техник күзәтүче вазифасында.

Шигырьләрне мәктәптә укыганда яза башлый, үзлегеннән баянда уйнарга өйрәнә һәм бер ел музыка укытучысыннан сабак ала. Институтта укыганда русча “Есть, товарищ подполковник” дигән беренче җырын иҗат итә.

Эшли башлагач, республика матбугатында хикәяләре басыла башлый, ә аны автор буларак “Тамчы гөл” атлы җыр (көен һәм сүзләрен) язу таныта. Фасыйл Әхмәтов, шушы җырны күздә тотып: ”Менә бу егет бер җыр язды, шуның белән халык күңеленә керде!”– дип белдерә.

1999 һәм 2004 елларда “Тамчы гөл” дигән исем астында ике китабы дөнья күрә. “Саба шагыйрьләре” дип аталган коллектив җыентыкта да берничә шигыре урын ала. Моннан тыш Төркиядә төрек телендә чыккан коллектив җыентыкка “Солтанәхмәт” шигыре кертелә.

2005 елда ул язган “Бүре” (сүзләре һәм көе) җыры Салават башкаруында “Татар җыры” фестивалендә диплом ала һәм дипломда әлеге җыр өчен авторның “Алтын барс” премиясе белән бүләкләнүе әйтелә. 2006 елдагы шул ук фестивальдә шул ук җырчы, көен Рөстәм Зарипов, ә сүзләрен Эдуард Мостафин язган “Юлчы” җыры белән катнаша. Балалар ансамбльләре аның Кави Нәҗми шигыреннән файдаланып язган “Алфавит” җырын эфирда яңгыраталар. Моннан тыш Фердинанд Сәлахов, Г.Исхакыйга багышлап язган “Мөһаҗир җыры” һәм Зиннур Насыйбуллин шигыренә язган “Туган тел” җырлары концертларында башкарылды, әлеге әсәрләр тамашачы тарафыннан җылы кабул ителде. Асаф Вәлиев белән Лилия Муллагалиева Фәнис Яруллин шигыренә көен ул язган “Беркем сизмәде” җырын эфирда һәм концертларда яңгыраттылар.

Рөстәм Зарипов журналистлык белән дә мавыга, күп кенә фәлсәфи язмалары “Шәһри Казан”, “Татарстан яшьләре”, “Ватаным Татарстан”, “Звезда Поволжья”, башка вакытлы матбугат чараларында дөнья күрә. Бөтендөнья Татар Конгрессы игълан иткән “Татар авазы” бәйгеләрендә катнашып, ул 2003 елны дүртенче һәм 2004 елны беренче бүләкләргә лаек булды.

“Мирас”, “Идел”, “Казан утлары” журналларында әдәби әсәрләре һәм әдәби тәнкыйть жанрындагы мәкаләләре дөнья күрә. 2005 елдан – Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.



Мусина Розалинда Нуриевна

**Мусина Розалинда Нуриевна**

1947 елда Белоруссиядә туган. Әнисе Мусина-Галимҗанова Камәрия Юлбат кызы (Галимҗанов Вакыйфның әтисе белән бертуган). Розалинда Казан педагогия институтын тәмамлап, 8 ел мәктәптә укытучы булып эшли, аннары Мәскәүдә СССР Фәннәр академиясенең Н.Н.Миклухо-Маклай исемендәге этнография һәм антропология институтының аспирантурасында укый. Аны тәмамлаганнан соң Казанда Г. Ибраһимов исемдәге тарих, тел, әдәбият институтында эшли. Хәзерге вакытта Татарстан Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институтында хезмәт юлын дәвам итә. Этнология, социология белгече. Тарих фәннәре кандидаты. 200дән артык мәкалә һәм китаплар авторы.

## Һөнәрчелек

Исламов Ихсан – тегүче, балта остасы, умартачы, оныгы Галиева Хәмдия – тегүче.

Ислам (Ихсанның әтисе) тегүче булган.

Нуретдин абыйның әтисе Гыйззетдин Сәләхов Ачы урысы белән мәчет манарасын ремонтлый. Мәчетне Наласа авылы кешеләре төзегән була.

Кәримов Рифкатьнең әтисе Сәләхов Кәрим тегүче була.

Шакир мулла тәрәзә пыялалары куя.

Рамазанов Әмирҗан тәрәзә рамнары ясый, сепараторлар төзәтә, аның әтисе Рамазан – балта остасы.

Әһелев Әнәс, Кәримов Рифкать, Шәмсиев Рәшит төрле елларда колхозның төзелеш бригадасы белән җитәкчелек итәләр.

Шәмсиев Булат Рәшит улы – балта остасы, агачтан төрле эшләнмәләр, заманча йорт җиһазлары ясаучы. Оста баянчы.

Заһертдин балта остасы, аның улы Заһертдинов Гыйльметдин шулай ук балта остасы.

Шәмсетдин бакчачылык белән шөгыльләнгән, аның оныгы Шәмсетдинов Хәниф – агач эшенең остасы.

Сәләхетдин бабай итекче, умартачы, аның оныгы Ибраһимов Әмин итекче, балта остасы, Әминнең улы Айрат умартачылык белән шөгыльләнә.

Итекчеләр: Хуҗин Фәтхрахман һәм аның уллары (Рухылбаян, Габдрахман, Азат), Рахимуллин Гатау һәм аның уллары (Хәтмулла, Гыйндулла, Гыйльмулла); Рахимуллин Гариф, Мөбәрәкшин Дәүли, Гайфуллин Билал һәм аның уллары (Тәлгать, Рифкать); Әһелев Әнәс, Халиков Мехәммәтхан, Сәгыйтов Садыйк

(Хафизов Нурмыйның бабасы), Шәмсиев Рәшит, Галиев Галиәхмәт (Галиев Шамилнең бабасы);

Әхмәтҗанов Кәбир – тегүче (Кәбиров Васыйлның бабасы), Кәбирнең малае Кашаф (Кәбиров Хафизның әтисе) – тире иләүче, итекче;

Хуҗин Зиннур – тегүче. Тегүгә өязгә дә йөргән. Кызы Асиягә Югары Шытсуга кияүгә киткәндә плюштан бик матур пальто тегеп биргән. Бу һөнәрен кызы Нафига дәвам иткән.

Балта осталары: Исламов Мөбәрәкҗан, Ибраһимов Әмин, Рамазанов Әмирҗан, Гайфуллин Вәлиәхмәт, Гайнетдинов Мәүлә, Мөбәрәкҗанов Раиф, Кәримов Рифкать, Гыйззетдинов Нуретдин, Ибәтуллин Сөләйман, Хаҗиев Муллахмәт. Зыятдинов Ризаетдин – балта остасы, тәрәзә рамнары ясаучы.

Шәмсиев Һарун – тальянда оста уйнаучы, Рәхимуллин Котдус – баянчы.

1940-42 елгы хуҗалык кенәгәсендә түбәндәге эшләр белән шөгыльләнүчеләр язылган.

Төзүчеләр: Рәхимуллин Мөхлис, Мөлеков Җәлил, Шәйхетдинов Шәмсетдин, Мөлеков Хәлим, Сәләхов Кәрим, Хуҗин Зиннур, Әхмәдиев Әһели, Шәвәлиев Әскәр, Миңнеханов Хан, Вәлишин Барый, Йосыпов Хәллә, Мөлеков Хәлил, Гарипов Фатыйх, Нуриев Гайфулла, Рәкыйпов Барый, Хуҗин Нургали, Гайнетдинов Шәмси, Дәүләтшин Гани.

Итекчеләр: Сафин Хәй, Вәлиев Галиәхмәт, Ильясов Шәймәрдән, Баһавиев Зыятдин, Сәгыйтов Садыйк, Хуҗин Фәтхрахман, Гайнетдинов Шәрип, Таһиров Сабир, Сәләхов Гыйззетдин, Минһаҗев Гания, Мәрдәнов Фәйзи, Гарипов Закир, Тимерханов Вәлиулла, Рәхимуллин Гариф, Тимерханов Сабир, Даутов Баязит, Шәймәрдәнов Нуриәхмәт, Шәймәрдәнов Шаһи, Шәмсетдинов Заһертдин.

Тегүчеләр: Фәизов Фаздрый, Рәхмәтуллин Ибәт, Халиков Ислам, Әхмәтҗанов Кәбир.

## Батырлар

Сугыштан соң беренче Сабантуй 1951 елда клуб алдында (хәзерге мәчет алды) үткәрелә. “Дуамал” Гыйнияте батыр кала. Ул Шәрифуллин Нурулла абыйның хатыны Галләм апаның абыйсы, бик олы гәүдәле кеше була. (Гыйззетдинов Нуретдин абыйның хәтерендә калганнардан.)

### Галиев Фарук Галиәхмәт улы

1955-1970 елларда берничә тапкыр авыл Сабан туенда батыр кала. Бер елны дүрт авылда батыр калуы турында әйтә торган булган. (Улы Галиев Шамил хәтерләве буенча язып алынды.)

**Мифтахов Хәнәфия Садретдин улы**



1955-1956 еллар сабантуе. Алда – сөлге тоткан Фарук Галиев (унда) һәм Урта Саба авылы кешесе

1962, 1965, 1967 елда авыл Сабан туе батыры.

1967 елда Саба Сабан туенда 70 кг лы үлчәүдә икенче батыр.

1973 елның 23 февралендә үткәрелгән Кышкы спартакиадада 70 кг үлчәүдә I урын. “Искра” колхозы каршындагы ДСО “Урожай” грамотасы белән бүләкләнгән.

1973 елның 16 февралендә “Марс” колхозы (Сатыш) үткәргән Кышкы спартакиадада I урын. “Марс” колхозы каршындагы ДСО “Урожай” грамотасы белән бүләкләнгән.

1976 елгы Кышкы спартакиадада көрәш буенча I урын. “Искра” колхозы комсомол оешмасы һәм ДОСААФ оешмасы грамотасы белән бүләкләнгән.



Мифтахов Хәнәфия. 2011 ел

Совет Армиясендә хезмәт иткәндә өлкән сержант Мифтахов Х.С. 97632 номерлы часть командованиесе тарафыннан спорт, хәрби осталыгы өчен берничә тапкыр Почет грамотасы белән бүләкләнә.

Озак еллар “Искра” колхозында шофер булып эшли. 1987 елда “Колхозның иң яхшы механизаторы” дигән мактаулы исем бирелә. Намуслы хезмәте өчен күп тапкырлар Мактау грамоталары, кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнә.

**Хаҗиев Рәшит**

Аның сөйләве буенча, алтмышынчы еллар урталарында аларның Юлбат Сабан туйларындагы көрәш башлыча күрше-тирә авылларның үсеп килүче көрәшчеләре белән Пермь якларындагы шахталарда эшләгән шушы авыл егетләре арасында бара. Рәшит шунда уналты-унҗиде яшьләрендә көрәшә башлый. Кукмарадагы Яниль профтехучилищесында укып, тракторда эшли башлагач тагын да ныгый, көрәш осталыгын арттырырга омтылып, Иске Җөридә яшәгән җизнәсе Габдерәуф Хәбибуллин янына барып, аннан дәресләр алып кайткалый. Армиягә

китәсе елында авыл Сабан туенда батыр кала. Хәрби хезмәттән кайткач яңадан да тракторга утыра, аннары бригадир итеп билгеләнә.

Җитмешенче елларга ул инде шактый көчле көрәшче булып керә. 1970 елда Саба районы Сабан туенда хәрби хезмәтен диңгезче булып узган, аннары Владимир өлкәсендәге Александров каласында яшәргә калган Сабай егете Ринат Мәҗитовтан гына калышып, 2 нче урынны яулый. Көзен "Җиңү байрагы" газетасы призына бәйгедә дә икенче урынга чыккач, район данын яклап Казанга баручы командага керә. Анда беренче көндәшеннән өстен чыга, ләкин аннан соңгы очрашуларда оттырып, алгы урыннарга чыга алмаса да, сабалыларга "Социалистик Татарстан" газетасының герой-шагыйрь Муса Җәлил исемендәге призын алырга булыша.

Районның 1971 ел сабан туенда ул яңадан да 2 нче (бу юлы Нәҗметдин Җәләлиевтан гына калыша). Аннан соңгы 1972, 1973 елларда Рәшит Хаҗиев – Юлбат Сабан туйлары батыры, "Җиңү байрагы" призына бәйгедә ике ел рәттән икенче...

– Минем өчен бигрәк тә 1972 ел истәлекле булды, – дип искә ала ул. – Авыл Сабан туенда мәйдан тоттым, районда ул елларда җиңелү белмәгән Нәҗметдиннән генә калышып, икенче булдым. Яхшы әзерлекле булуымны "Җиңү байрагы" призына бәйгедә дә күрсәткәч, Казанга да бардым. Анда да әйбәт көрәштем: кемгә генә туры килсәм дә, аларны бирелдереп, тамашачылар арасына озаттым. Ахырдан Түбән Камалы Наил Зәйнуллин белән очраштык. Көрәшеп бетерергә бер минуттан аз гына артыграк вакыт калганда аны отып бара идем. Күңелгә хәтта: "Болай булса, мин батыр калам икән", – дигән уй да кереп оялады. Ләкин бу көндәшем тәҗрибәлерәк булып чыкты, соңгы минутта бар булганын күрсәтеп, матур гына эләктереп алды да аркама тәгәрәтте. Шуның белән беренчелеккә чыкты, миңа исә Әлмәт егете Миннәхмәт Мөхәмәтҗановны да алгарак үткәреп, өченче урын белән канәгатьләнергә туры килде...

Кызганыч, бу көрәшчегә үзенең спорт биографиясен Казан Сабан туенда көрәшкәндә иңбашыннан кулы чыгып, егерме сигез яшендә төгәлләргә туры килә.

Рәшит Раиф улының аннан соңгы тормышына килгәндә, ул гомере буе туган авылында яши, читтән торып авыл хуҗалыгы институтында укыган елларда һәм аны тәмамлагач, үзләренең "Искра" колхозында агроном, баш агроном булып тора, авырып киткәнче шул эшендә була. Сабантуйлары җитсә, әле дә авылда да, районга да иң алдан барып, иң җайлы урынны сайлап утыра да рәхәтләнеп көрәшчеләрнең бил алышларын карый.

*Танылган журналист Илдус Илдархановның*
*"Саба ягы көрәше" китабыннан, Казан, 2014.*

**Хуҗин Мәрүәр Зиннур улы**

Район Сабан туенда өченче батыр, авыл Сабантуйларында берничә тапкыр икенче батыр.

**Мөхәммәтҗанов Фәрит Мәүлетҗан улы**

1971 елда Мәрдәнов Хәбибрахман абыйлар янында үткәрелгән авыл Сабан туенда батыр.

**Зыятдинов Каюм**

1975 ел – авыл Сабан туе батыры, Тенеки ягында булган.

**Галиев Шамил Фарук улы**

1981, 1982, 1984 (яки 1985) авыл Сабан туе батыры.

1983 елда Сабада М.Җәлил призына үткәрелгән ярышта 90 кг га кадәр үлчәүдә I урын.

**Фәтхриев Рөстәм Рухылбаян улы**.

1983 ел. ”Татарстан яшьләре” газетасы призына үткәрелгән татарча көрәш ярышларында 60 кг лы үлчәүдә I урын.

1988 ел. Казан шәһәре беренчелегенә 65 кг лы үлчәүдә I урын.

1989 ел. Татарстан беренчелегенә 65 кг лы үлчәүдә II урын.

1988, 1989, 1990, 1992, 1998 елларда авыл Сабан туенда баш батыр.



Студент Фәтхриев Рөстәм (сулдан беренче) Муса Җәлил призына үткәрелгән республика ярышында. 1989 ел

**Гасыймов Римгел Тимерҗан улы**.

1987 елда авыл сабантуенда батыр кала. Берничә тапкыр батыр асты кала.

**Сабиров Хәлил Хәтмулла улы**.

Вузлар арасында Краснодар шәһәрендә Россия беренчелегенә җиңел атлетика буенча үткәрелгән ярышларда III урын.

Казан вузлары арасында җиңел атлетика буенча призер.

60 кг лы үлчәүдә көрәш буенча Казанның Идел буе районы Сабан туе батыры.

1980 елда, 10 классны тәмамлаганда, Сабада М.Җәлил призына үткәрелгән ярышта II урын.

Авыл Сабан туйларында II-III урыннар.

**Гомәров Ибраһим**.

1958 елда Тенеки авылында туган.

Армиягә киткәнче 1975 елда Юлбатта өченче батыр.

1982, 1983 елларда Сабада икенче-өченче батыр.

1998 елда Юлбатта икенче батыр.

**Сабиров Мәхмүт Хәтмулла улы**.

1982, 1983 елларда Сабада беренче батыр.

**Хамматов Фәннүр Габделбәр улы (Юлбат кияве)**

1980 нче – еллар башында Юлбат Сабан туе батыры

**Әмиров Дамир Рәҗәп улы**

1997 ел, 2006 ел – Юлбат Сабан туе батыры.

Юлбатта 4-5 тапкыр икенче батыр.

1994 ел – Кышкы спартакиадада Сатыш һәм Юлбат авылларында көрәштә икенче батыр.

Казанда М.Җәлил призына үткәрелгән ярышларда район командасы составында берничә тапкыр катнаша.



Ибәтуллин Вафи

**Мөбинов Илдар Вакыйф улы (Юлбат кияве)**

1993 ел – Юлбат Сабан туе батыры.

**Мөбәрәков Ришат Шаһинур улы (Тенеки кияве)**

2010, 2012, 2013, 2014 елларда Юлбат Сабан туе батыры.

**Ибәтуллин Вафи Ибәтулла улы.**

1935 елның 2 февралендә Юлбат авылында туа.

